Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 6 (1422) 17 февраль 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



2

Себердә милли үзаңны ныгыту, татарлыкны, тарихи бергәлекне саклау өчен, Татарстан белән бәйләнештәге махсус үзәк кирәк.

12

Саба районы Миңгәр авылына рәссамнар десанты төшү бу урында сәнгать учагы кабызуның көчле чаткысы булды.

14

Министрлыктагы кәгазь эшен ташлап, Гөлсинә Галимуллина дәртле испан биюе – фламенконы өйрәнүгә һәм популярлаштыруга өстенлек бирә.

Уебыз да, барыр юлыбыз да Тирә-юнебездәй ак булсын!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия Президенты Владимир Путин карары белән Г.Камал театр актеры Рамил Төхфәтуллинга Россиянең атказанган артисты дигән мактаулы исем бирде.
- Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиллегендә Дастаннар елы кысасында «Идегәй дастанда һәм тарихта» дигән темага лекция үтте.
- «Әкият» театрында IV «Әкият-LAB» курчак театры лабораториясе эшли башлады.
- Самара өлкәсе Камышлы районында яңа урамга урта гасыр төрки-татар шагыйре Сәйф Сараи исеме бирелгән.
- Татарстан Республикасының Милли музее һәм Г.Тукай әдәби музее мәктәп укучылары арасында «Ядкәрләрдә Тукай рухы» дип исемләнгән әдәби конкурс уздыра.
- Журналист, тарихчы һәм туган якны өйрәнүче Шамил Галимовның «Самара Тарихи мәчете: гасырлардан гасырларга (1891-2022)» дигән китабы дөнья күрде.
- Татар мәдәнияте көннәре кысаларында Төмән шәһәренең «Төзүче» сараенда «Себер мирасы» дип исемләнгән күргәзмә ачылды.
- Ульяновск шәһәренең Татар мәдәният үзәгендә Татарстанның атказанган артисты Бари Тарханов исемендәге VIII төбәкара татар театрлары фестивале башланды.
- 27 февральдә С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында шагыйрь, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мирзагə 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үтәчәк.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Равил ГАЙНЕТДИН, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти:

«Балаларыгызны татарча тәрбияләгез, өйдә татарча сөйләшегез», – дия идем мәҗлестәге яшьләргә. Хәзер, кызганыч, балаларым оныклар белән русча сөйләшә. Оныкларыма татарча әйткәндә, алар миңа: «Нәрсә дип әйттең, бабам?» – ди. Мин аларга русча аңлатырга тиеш булам. Русча белмим, дисәм дә: «Син рус телен бик яхшы беләсең», – диләр. Оныгым гает намазына Җәмигъ мәчетенә килә, ул минем русча сөйләвемне тыңлый. Менә бу – безнең Мәскәүдә һәм зур мегаполисларда яшәүнең нәтиҗәсе. Казанда да шул хәл, беләм».

СЫНАМЫШЛАР

Салкын көндә кар яуса – җылыта ● Төнлә ай зур, кызгылт күренсә – җепшекләтә ● Ала каргалар агачның иң өске ботакларына кунып чистарынса, тавыклар кытакласа, тиздән кар ява ● Кар түбәләрдән салынып төшсә, җәйгә иген уңа ● Кояш бик еракта булып күренсә, көннәр суыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 06 минутта чыкты,** һәм ул **16 сәгать 51 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 45 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **24 февральдә 10 сәгать 17 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

18 февраль – язучы Мәсгут Гафиятулла улы Шәрифуллинның тууына 95 ел (1928-1966).

19 февраль – язучы Локман Фатыйх улы Закировка 95 яшь (1928);

– режиссер, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Байрас Надим улы Ибраһимовка 70 яшь (1953).

20 февраль – шагыйрь Риза Закир улы Шәфиевнең тууына 100 ел (1923–2004).

21 февраль – язучы, Россиянең һәм Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Марс Әһлиулла улы Әхмәтшинга 75 яшь (1948).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(20-27 февраль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 26 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ



Дамир ИСХАКОВ,
тарих фәннәре докторы

СЕБЕР ҮЗӘГЕ КИРӘК!

Халыкны исәпкә алу нәтиҗәләре милләттәшләрне сискәндереп, уятып җибәрде, чөнки Гаяз Исхакый әйткән инкыйраз инде бүген үк каршыбызга басты. Шул уңайдан республикабыз информация чараларында зур сөйләшүләр үткәрелеп, шактый саллы мәкаләләр дә басылды. Әмма, беренче чиратта сүз «кем гаепле» төенендә тупланып, гаепләне тыштан эзләүгә күп урын бирелде. Хафалану өчен сәбәпләр җитәрлек һәм уйлый белүчеләр өчен алар яңалык та түгел. Ә мәсьәләнең икенче ягы – үзебездәге кимчелекләрне, фундаменталь җитешсезлекләрне әйләнеп үтәргә маташабыз. Аңлашыла – бакчандагы бәрәңгеңне таптаган хайваннарның күршеңеке булуын үзеңнеке икәнен тануга караганда җиңел һәм отышлырак, ул юл белән барганда, күңел дә тынычланып кала...

Чынлыкта, үзебездәге чатаклыклар турында сөйләшү әһәмиятлерәк, чөнки тыштан һәм читтән килгәне бездән тормый, андый тискәре йогынтылар элек тә булган, алга таба да юкка чыкмастыр. Алар турында без белергә, әмма алдан ук хәстәрен дә күрергә тиеш. Моның өчен эксперт-аналитиклар, бу эшкә тиешле финанслар, алар белән шөгыльләнүче үзәкләр (гыйльми, информацион, сәяси-технологик һ.б.) булдыру кирәк. Шул уңайдан язмамда конкрет мисал нигезендә бездә бу эшнең нинди хәлдә булуын тасвирларга уйлыйм.

Сүз себер татарлары турында бара һәм шунлыктан алар буенча кыскача мәгълүмат бирү фарыз.

Себер ханлыгының варислары булган бу төркем сан ягыннан әллә ни зур түгел – 200 мең чамасы. Хәзер аларны төгәл санап та булмый, чөнки бу яклардан күчүләр белән җирле себер татарлары күптән аралашып, уртак гаиләләр корды. Әмма Көнбатыш Себердәге абориген, җирле татарларның абсолют күпчелеге үзләрен татар милләтенең аерылгысыз бер өлеше дип саный һәм соңгы халык исәбе дә шуны күрсәтте – үзләрен аерым этник төркем, «себер татар халкы» дип язылучыларның саны 6,3 меңнән артмады. Саннарга карасаң, себер татарлары проблемасы юк кебек. Әмма моңа җиңел акыллы трактовкалар бирергә теләүчеләр Казанда, бигрәк тә сәяси һәм аларга якын даирәләрдә хәзер күп булачак. Ләкин үзем Себердәге күп авылларны этнограф рәвешендә айкап чыккан һәм инде чирек гасыр буе андагы татар галимнәре, иҗтимагый тормыш җитәкчеләре, гади халык белән аралашкан кеше буларак әйтәм – бу төбәктә татар проблемасы һаман чишелмичә кала икән, димәк, милләт өчен куркыныч трагик яссылыкка кереп бара, дигән сүз бу. Ә Казан ул хакта тирәннән фикерләмичә, культур-мультур (сабантуйлар вә фестивальләр) уйнау ысуллары белән генә чикләнеп, бу төбәктә өстән-өстән генә йөреп эш алып бара. Әмма нәтиҗә үтә дә тискәре – монда коточкыч тизлек белән тел ассимиляциясе дәвам итә, милли мәгариф системасына үлем яный, халык каршында торган икътисади мәсьәләләр дә авырая бара. Әлегә икътисадка кермик, ул – аерым зур өлкә, әмма алга таба аны да күтәрергә кирәк. Бу юлы сүзебездә гуманитар фән, милли аң формалаштыру, татар мәдәниятенең җирле тармагын саклау бурычлары дәвам итәр.

Совет чорында Себер җирлегендә яшәгән татарлар Татарстан галимнәре игътибарыннан читтә калмады, каршылыклар булса да, Казаннан килгән диалектолог, этнограф, фольклорчылар монда зур тикшерү үткәреп, себер татарларының традицион мәдәнияте, тел үзенчәлекләре буенча фәнни мәгълүмат туплый-туплый зур хезмәтләр язды, аларны гомуммилли фәнни-информацион кырга кертә барды. Безнең белән хезмәттәшлек иткән җирле татарлардан галимнәр дә үсеп чыкты. Шушы хезмәтләрне яза-яза, Казан белән бәйле булмаган галимнәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә дә, себер татарларында милли горурлык һәм милли аң ныгыды. Бу яклар турында тарихи хезмәтләр дә басылды. Әйтик, үземнең турыдан-туры катнашым нигезендә зур академик хезмәт – «История и культура татар Западной Сибири» (2015) һәм тарихны укыту өчен кулланма буларак «История и культура сибирских татар (с древнейших времен до начала XXI века)» (2014) китаплары басылды. Кызганыч ягы шул – бу эшләрне башкару күп очракта Татарстан Фәннәр академиясенең дә, башка фән өчен җаваплы даирәләрнең дә катнашыннан тыш, иҗтимагый тәртиптә, дәүләт планнары нигезендә түгел, бушка диярлек башкарылды. Хәзер дә истә – күрсәтелгән хезмәтләрнең беренчесендә иң әһәмиятле бүлекләрне (алар бик күләмле) язган өчен 17 мең сум гонорар алдым... Безнең арттан башка тарихи китаплар да күренде, хәлбуки, алар без язганга карата эпигон һәм ашыгыш эшләнгән иде (мисалга, Археология институты һәм Казан федераль университеты канаты астында чыккан «Тюменское и Сибирское ханства» (2018) хезмәтен күрсәтә алам). Дәүләтнең игътибары булмагач, фундаменталь «История и культура татар Западной Сибири» хезмәте 100 (!) данәдә басылды, ә укыту өчен кулланманың тиражын гонорарларны юк дәрәҗәдә калдырып булса да, 500 данәгә җиткердек. Соңгыларын җилкә белән ташып, Көнбатыш Себердәге татар мәктәпләре һәм китапханәләргә илтеп тапшырдык.

Күрәсезме – монда Татарстан ягыннан ярдәм бар да кебек, грант акчасы бирелгән бит, ә чынлыкта, бу – мескен суммалар гына. Ашаган белми, тураган белә, дигәндәй, мин моны бик тә яхшы, төптән үзләштердем.

Ягъни Себер төбәге буенча, Татарстанның ныклап, планлаштырып башкарыла торган бернинди фәнни сәясәте дә юк. Г.Ибрагимов институты гына соңгы елларда системалы рәвештә Томск, Омск, Новосибирск, Төмән өлкәләрендә эшләде, комплекслы экспедицияләр оештырды, китаплар чыгарды, яңаларын да әзерли. Ләкин бу фәнни эзләнүләрнең дә еракка карап корылган стратегиясе юк, аның ачык мисалы мондый: Мәскәүдә кайбер тюркология гыйлеме белән шөгыльләнгән үзәкләрдәге галимнәр, милли эшләр белән мәшгуль федераль орган (ФАДН) белән бергә, «себер татарлары теле» турында «түгәрәк өстәлләр» һ.б. шуның ише акцияләр үткәргәндә (бу эшне бик тырышып башкорт политтехнологлары да хуплады), безнең телчеләр ягыннан Мәскәүгә барып ләм-мим сүз әйтүче табылмады. Сәбәбе аңлашыла: үзебезнең бу өлкә буенча сәясәтебез юк. Биштәр асып материал җыю бар, ә сәясәт – юк.

Әйтелгәннәрне читтән күзәтсәм, ә төп эшем Бөтендөнья татар конгрессында журнал чыгару булса да, Милли шура әгъзасы буларак, мондый тәкъдим ясарга кирәк дип таптым: Мәрҗани исемендәге Тарих институтының җитәкчелеге белән киңәшеп, ул фәнни учреждение эчендә Себер үзәге булдыру кирәк. Аналог бар: Мәскәү кушуы буенча бу институтта Кырым үзәге эшләп килә. Хәлбуки, кырым татарлары мөстәкыйль милләт булса да... Ә бу очракта исә татар милләтенең үзенчәлекле, ләкин башка татарлар белән күптән береккән себер татарларын һәм безнең яклардан Себергә күчкән күп санлы татар төркемнәре тарихын өйрәнү турында сүз бара! Өстәвенә, Себер үзәге ул якларда алып барыла торган тикшерүләрне башкарачак координацион үзәк тә була алыр иде.

Бу хакта Тарих институты директоры Р.Салихов белән киңәшеп, үземнең укучым, Тубыл шәһәрендәге татар автономиясе рәисе З.Тычинских ярдәме белән ул шәһәрдә урнашкан Россия Фәннәр академиясенең Урал бүлеге структурасы карамагындагы «Тубыл комплекслы фәнни станциясе» дип аталган (ул чынлыкта институт) академик учреждениега барып, ул фәнни үзәк һәм Тарих институты арасында килешү төзеп, Себер үзәге өчен анда урын бирелү турында имза салдык. Чынлыкта Себер үзәге Казанда, Тарих институтының бер бүлеге буларак (Кырым үзәге нәкъ шулай эшли) оешып, бездән финанслау гына алырга һәм Себердәге галимнәрне ул төбәк тарихын өйрәнүне татар күзлегеннән карап башкарырга тиеш иде.

(Дәвамы 4 нче биттә).

вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Мөнәсәбәт

Тәкъвалык җае

Тәкъвалык турында сүз барганда, гадәттә, кешенең диндарлыгы, аның дин кушканны гына эшләп, гөнаһ эшләрдән саклану сыйфаты күздә тотыла. Әмма, диннәр – күптөрле, ә Хак Тәгалә – бер һәм бердәнбер. Шуңа күрә Аның кануннары бөтен Җиһан өчен дә уртак. Димәк, бар тереклек дөньясы (шул исәптә адәми зат та) әле яралтылышта ук урнаштырылган шул тәртип вә закончалыклар буенча яшәргә тиеш була. Аерма шунда гына – мәхлукатның аңсыз өлеше тигезләнешне хайвани инстинкт һәм илаһи закончалыклар аша саклаган, кеше инде илаһи яшәешкә аңлы рәвештә омтыла. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә аңа акыл бүләк иткән. Әгәр дә ул яшәү функциясен хайвани дәрәҗәгә төшереп үти башлый икән, ул чакта инде илаһи закончалыклар аның үзен дә тотрыклы тигезләнеш хәленә китерәчәк. Шуңа күрә бу язмада, «тәкъвалык» төшенчәсенә киңрәк мәгънә биреп, адәми затның илаһият кануннары буенча гына яшәү һәм ярамаган (гөнаһ) эшләрдән тыелып калу сыйфаты итеп тә фикер йөртербез.

Шуны да искәртеп үтик, илаһи миссияле милләт өчен рухи яңарыш хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы (мәңгелек һәм тәҗрибә ителә алмый торган илаһи башлангычларның даимилеген таный торган фәлсәфи тәгълимат) югарылыгында аңлаудан башлана. «Тәүхид» кәлимәсе анда Аллаһның бер һәм бердәнбер булуын белдерсә, «иҗтиһат» төшенчәсе инде Аның юлында тырышлык кылуны аңлата. Ислам метафизикасы теоретигы Рашат Сафин хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын үзенең хезмәтләрендә (Р.Сафин, «Татар инануы», 2014, 253-254 битләр) шаһәдәткә салынган тирәнтен мәгънәләргә нигезләнеп дәлилли. Аның язуынча, Аллаһны күреп-ишетеп тә, ничектер тоемлап та, хәттә абстракт акыл белән дә танып-белеп булмый. Аның барлыгына бары тик язмышыбызның объектив закуннарга буйсынганлыгы (тәкъдир) аркылы гына ышанабыз. Кеше исә – әлеге тәкъдирне гамәлгә куюу буенча Аллаһның илчесе, димәк, үз язмышын үзе хәл итә: тәкъдирдә каралганны ничек реальләштерү мәсьәләсендә ул тулысынча ирекле, тик, акыл иясе буларак, кайчан һәм кайда нәрсә кирәклеген (вакыт-пространство таләпләрен) аңлап эш итәргә тиеш (моның өчен аңа җаваплылык йөкләнгән, ялгышканнарга исә җәзалар да каралган). Димәк, илаһи исламның да фәлсәфи асылы һәм төп максаты – Аллаһка кайту юлының соңгы маягын күрсәтеп, адәми затка иң югары омтылыш ирег биру һәм, аны соңгы баскычка күтәрү өчен индерелгән дин буларак, кешеләрнең зиһенен рәсүли аң югарылыгына күтәрү, шул рәвешле, аларның илаһият кануннары буенча иҗтиһат кылуына ирешү. Татар милләтенә исә ошбу изге эшләрдә үрнәк һәм әйдәп баручы кавем булу вазыйфасы да тәкъдирдән йөкләнгән.

Югарыда әйтелгәннәрне һәм бүгенге кискен хәлләрне дә (рухи деградация, системалы кризис, халыкара хокук нормаларының санга сугылмавы һ.б.) исәпкә алып эш иткәндә, рухи яңарыш вә тәкъвалыкка ничек ирешергә соң? Әлбәттә, сорау бик тә катлаулы, әмма, дөрес ният кылганда, Аллаһ ярдәме белән хәл итәрлек. Моның өчен иң элек, хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлап, дин әһелләренең Аллаһ ризалыгы өчен югары дәрәҗәдә фикер йөртергә һәм гамәл дә кылырга өйрәнүе бик мөһим. Бары шуннан соң гына, рухи яңарышны системага салып (аның юнәлешләрен, ысулларын, киңәю тәртибен, этапларын, географиясен һ.б. билгеләп), конкрет эшчәнлекне максатчан һәм колачлы итеп җәелдереп җибәрергә була. Әлбәттә, төп җаваплылык, илаһи миссияле кавем буларак, татар милләтенә төшә һәм ул илаһи факторлар (аның шанлы тарихы һәм Урталык җирләрендә бүгенгәчә таралып яшәве, меңьеллыкларга сузылган илаһи сынауларны уңышлы үтүе һәм асыл сыйфатларын саклап калуы, ислам варислыгы һәм хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлау сәләтенә ия булуы һ.б.) белән дә билгеләнә. Димәк, инсаниятнең рухи нигездә глобальләшүе дә (ягъни, Ләүхел-мәхфүздә үк язылганча, кешелек дөньясының илаһи нигездә берләшүе), тарихның географик күчәре саналган Урталык җирләреннән башланып, бөтен дөньяны цивилизацияле күптөрлелек берлеге итеп үзгәртергә һәм гармонияле яшәешкә китерергә тиеш була.

Ә тәкъвалык мәсьәләсенә килгәндә, Җирдә бөтенләй дә гөнаһсыз кеше юк һәм була да алмыйдыр кебек. Чөнки адәми затның табигате шундый (Адәм белән Хәваның оҗмахтан куылуын гына искә төшерик). Әмма татарда нарасыйны «Әй, бер гөнаһсыз сабый!» дип сөю гадәте дә бар. Әлбәттә, бәндә хатадан хали түгел. Гөнаһларга да ул яшиви бата. Әмма бөтен хикмәт – гөнаһ гамәлләреңне танып, тәүбәгә килә белүдә. Мәгәр, гөнаһ белән гөнаһ арасында аерма да зур. Иң яманы – кешелек сыйфатларын югалтуга китерә торган гөнаһлар. Ә бу инде андый кабахәтлек кылучыларга (үзара мөнәсәбәтләрдә буламы ул, тәркем белән яисә ил күләмендәме) ләгънәт камыты кидерелергә тиешлекне аңлата.

Фоат УРАЗАЙ.

Укытучылар һәм остазлар елы башланды

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Татарстанда Укытучылар һәм остазлар елын ачу тантанасында катнашты. Тантаналы чара КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында үтте.

Татарстан Рәисе укытучы профессиясенең дәрәҗәсен күтәрү һәм эш шартлары яхшырту, профессиональ һәм иҗади өлкәдә мөмкинлекләрне киңәйтү максатыннан укытучыларның эш шартларын яхшыртачакларын белдерде. «Иң мөһиме – белемнең сыйфаты», – диде Рөстәм Миңнеханов. Рәис шулай ук, Укытучылар һәм остазлар елында аерым игътибарның фәнгә юнәлтеләчәген әйтте.

«Быел аерым игътибарны без фәнгә юнәлдерергә тиеш, бигрәк тә югары уку йортларында. Яшь галимнәр – Россиянең тиз арада техник һәм технологик төзелешенең өмете. Без, һичшиксез, галимнәрнең нәтиҗәле эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудырачакбыз. Безнең өстенлек – талантларга, интеллектуаль хезмәткә сакчыл мөнәсәбәттә», – диде ул.

Тантанадан соң Татарстан Мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин журналистлар белән очрашты. «Милли мәдәниятләр һәм традицияләр белән Укытучылар һәм остазлар елын бер ел дип санарга була. Чөнки укытучылар – милли мәдәният, традицияләр һәм тел сагында торучылар. Укытучылар – безнең балаларны тәрбияләп, бөтен җәмгыятьне тәрбияләүләр», – диде И.Һадиуллин. «Бүгенге чараның төп максаты – укытучы һөнәренә мәхәббәтне үстерү, арттыру, аңа яшьләрне җәлеп итү булса, икенче яктан шушы системага гомерен багышлап, күпме буын балаларны тәрбияләп чыгарган остазларыбызга рәхмәт әйтү дә. Укытучыларыбызны хөрмәт итик, аларны яратыйк. Аларга чын күңелдән «рәхмәт сиңа, укытучым», дип әйтсәк, менә шул була инде безнең мәгариф системасына булган карашны үзгәртү һәм аны яхшырту», – диде министр.

Илсур Һадиуллин 2023 ел укытучылар өчен чараларга бай булачагын әйтте: «Конкурс, конференция, төрле очрашулар көтелә. Республикада мәгариф системасының тарихы турында китап чыгарасыбыз, музей ясыйсыбыз килә. Укытучылар һәм остазларга багышланган урамнар, парк, скверлар булдыру кирәк. Бәлки бөтенесен дә быел эшләп булмас, шулай да проектларның идеяләре бар». Министр әйтүенчә, укытучылар көнендә республикада «Укытучылар атналыгы» узачак.

И.Һадиуллин 7 ел элек кадрлар әзерләү буенча республика проекты булдырылуын искә алды. «Иң мөһиме – кадрлар әзерләү һәм мәгариф системасын кадрлар белән тәэмин итү, – диде ул. – Хәзерге көндә 745 студент укый, шуларның яртысы полилингваль программа буенча белем ала. Аларның 88 проценты мәктәпләргә укытырга бара. Бу – безнең өчен зур куанычлы фактор. Ай саен 15 мең стипендия алып укыган укучылар мәктәпләргә кайтып, биш ел дәвамында тулы көчен биреп эшне башлый һәм шунда төпләнеп кала икән – мәктәп өчен моннан да зур бәхет, табыш юктыр дип уйлыйм».

Энҗе ГАБДУЛЛИНА.

Минзәлә театры гастрольгә килә

20 февральдә Г.Камал театрында Мостай Кәримнең «Кыз урлау» әсәре буенча куелган спектакль белән С.Өметбаев исемендәге Татар дәүләт драма театрының Казанда гастрольләре башланып китә. 21 февраль көнне Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында Заһир Бигиев әсәре буенча куелган «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» беренче татар детектив спектакле күрсәтеләчәк. Ул – режиссер Ренат Әюповның Минзәләдә куйган сигезенче тамашасы. Тамашачы барысын да бик яратып караган һәм карый. 22 февраль гастроль Осиново бистәсендә дәвам итеп, 23 февральдә Әтнә театрында тәмамланачак.

Минзәлә театрында утыз елга якын директор булып эшләгән һәм алтмыш яшьлек юбилеена бер ай кала гүр иясе булган Роберт Шәймәрдәновның истәлеген мәңгеләштерү максатында балалар театрлары фестивален башлап җибәрү күз уңында тотыла. Фестивальдә Минзәлә балаларын гына түгел, Актаныш, Мөслим, Сарман, Тукай районнарында яшәүчеләрне дә колачларга уйлыйлар. Киләчәктә фестивальгә Татарстан Мәдәният министрлыгы да булышыр, бәлки. Бу хакта Минзәлә театрының Казандагы гастрольләре уңаеннан «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында хәбәр ителде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Өмет яшь галимнәрдә

Казанда «Татарстанның иң яхшы яшь галиме – 2022» республика конкурсында җиңүчеләрне һәм республиканың махсус дәүләт стипендиясе иялӘрен хөрмәтләделәр. Чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Ул республикада фәнни эшчәнлекне стимуллаштыру өчен грант һәм стипендия программалары, фәнни премияләрне дә кертеп, төрле ярдәм чаралары гамәлдә булуын билгеләп үтте. Татарстанда фәнни эшчәнлеккә ел саен 20 млрд сумнан күбрәк акча тотылуына игътибар юнәлтте.

Ф.Мөхәммәтшин белдергәнчә, «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы табигать, техник һәм социогуманитар фәннәрдә иң талантлы тикшеренүчеләрне ачыкларга мөмкинлек биргән. «Тарих күрсәткәнчә, нәкъ менә яшьләр зур фәнни ачышлар ясаган. Әлбәттә, яшь галимнәребезнең зур фәнни ачышлары турында сөйләгәндә, мин Казан университеты доценты Ирек Мөхәмәтдинов исемен атап үтәргә һәм аны котларга телим, ул илебез Президенты Указы белән Россия Федерациясе Президенты премиясе лауреаты булды. Бу Татарстанның бүгенге буын галимнәренең кайчандыр республикабызны дөньяга танытkан өлкән буыннарның эшен лаеклы рәвештә дәвам итүен раслый», – дип билгеләп үтте парламент башлыгы.

Аның сүзләренчә, Фән һәм технологияләр елы дип игълан ителгән 2021 ел Россиядә 2022-2031 елларда узачак Фәнни унъеллыкның башы булды.

1 нче биттә – Казанда узган «Россия чаңгы юлы» гаммәви ярыш-бәйрәменнән бер күренеш.

Солтан ИСХАКОВ фотосы.
«Татар-информ».

Аны бар дөнья белә

Казанда бөек рус опера җырчысы Федор Шаляпин истәлегенә багышланган мемориаль такта ачылды. Скульптор Тимофей Тюрин ясаган бронза такта Пушкин урамындагы 10 нчы бинада урнаштырылган.

Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты. Тантанага шулай ук Татарстан мәдәният министры Ирада Аюпова, Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшин, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов, Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Вадим Дулат-Алеев һәм башкалар килгән иде.

«Күренекле якташыбыз, бөек опера һәм камера җырчысы Федор Иванович Шаляпинның тууына 150 ел булды. Татарстанда аңа багышланган мәдәни-агарту, музыкаль, фәнни һәм театр чаралары әзерләнгән. Сәүдәгәр Лисицин йорты фасадында (ул туган флигельдә) Федор Шаляпинга мемориаль такта ачу мөһим вакыйгаларның берсе булып тора», – диде Р. Миңнеханов.

Татарстан Рәисе сүзләренчә, Шаляпин тудырган сәхнә образлары эталон булды, аны сәләтле актер һәм талантлы рәссам буларак таныдылар. «Федор Ивановичны артист буларак бөтен дөнья диярлек белә иде», – дип өстәде республика башлыгы. Р.Миңнеханов Шаляпинның Казанны бик яратуын һәм танылган җырчының бирегә берничә тапкыр кайтуын искә төшерде.

Кариев театрында юбилей

Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры 35 еллыгы уңаеннан бәйрәм чаралары уздыра. 25 февральдә театр бинасының һәр почмагында тантаналы рух хөкем сөрәчәк. Фойеда, мәсәлән, бүген репертуарда булган спектакльләрдән фотокүренешләр күргәзмәсен тамаша кылырга мөмкин булачак. Икенче каттагы кече сәхнәдә беренче спектакльләрдән күренешләр җанланыр. Зур сәхнәдә исә Габдулла Кариевның әсәре Ркаил Зәйдулла пьесасы буенча куелган «Артист» спектакле уйнала. Татар театрына нигез салучыларның берсе, казанышлары өчен «татар театрының атасы» исеменә лаек булган, нибары 33 яшендә үзеннән соң якты эз калдырып бакыйлыкка күчкән Габдулла Кариевка багышланган бу тамашада бөтен труппа катнаша һәм анда беренче артистларыбызның мәгърифәт юлында күргән газаплары, шатлык вә көенечләре тасвирлана.

Әмма бәйрәм чаралары шуның белән генә бетми, иҗат фасылы тәмамланганчы дәвам итә. Мәсәлән, апрель аенда олуг шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган «Йөз Тукай» исемле урам перформансы күрсәтелүе көтелә (режиссеры – Эльдар Гатауллин). Белүебезчә, Габдулла Тукай – татар театрының аякка басуы өчен җан аткан бөек шәхес. Шәһәр буйлап «Ике Габдулла» дип исемләнгән променад уздыру да күздә тотыла. Ул Казан урамнары буенча самокатта йөрүдән гыйбарәт булачак. Тукталышларда театральләштерелгән күренешләр вакытында Габдулла Тукай һәм Габдулла Кариев театр турында «гәпләшәчәк».

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Әнисе Шүкрия ханымның фаҗигале үлеме сәбәпле, газетабызның даими авторларыннан берсе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче Фатих Кутлуның тирән кайгысын уртаклашабыз.

“Мәдәни җомга” газетасы редакциясе.

«Мирас» фестивалендә татар операсы

«Мирас» татар музыкасы фестиваленең икенче концертында Миләүшә Хәйруллинаның «Кави-Сәрвәр» операсының дөньякүләм премьерасы тәкъдим ителде. Спектакль аншлаг белән үтте. Яшь авторларның беренче зур күләмле әсәрен тыңларга сәнгать әһелләре күп килгән иде.

«Миләүшә бик тырыш, сәләтле композитор. Мин аның эшләрен күзәтеп барам, үзен Татарстан Композиторлар берлегенә дә алдык. Мәскәү консерваториясенә керде», – дип сөенечен белдерде премьерадан соң яшь композиторны котларга ашыккан Россия һәм Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин: «Партитура» конкурсында жюрида мин дә бар идем. Миләүшәнең бу конкурста беренче урын алуына шатландым. Бу әсәренең музыкасы бик матур, сәяси ягы да бар әсәренең», – диде ул.

«Миләүшә бик актуаль темага алынган. Бу аның көтелгән иҗат җимеше», – диде спектакльдән соң композиторны котларга кергән Казан шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова.

«Татар сәнгатендә опералар күп түгел, алар санаулы. Шушы аз санлы операларыбызга тагын бер опера өстәлде. Мин моңа бик шатмын», – диде композитор Эльмир Низамов.

«Кави-Сәрвәр» операсының либретто авторы – Айдар Әхмәдиев. Спектакльдә җырчылар – Эльза һәм Артур Исламовлар, Айсылу Нуруллина, Денис Хан-баба, Рөстәм Асаев, Сөмбел Кыямова, Илүсә Хуҗина, Айгөл Гардисламова, Илгиз Мөхетдинов, Ирек Фәттахов, Любовь Добрынина, Руслан Закиров һәм башкалар чыгыш ясый. Операда ТР Дәүләт камера хоры катнашты, аның җитәкчесе Миләүшә Тәминдарова төп рольләрнең берсе – Хәтирә ролен башкарды.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Себер үзәге кирәк!

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Ул арада З.Тычинских Төмән һәм Тубыл шәһәрләрендәге безгә кирәк юнәлештә белгечлеге булган галимнәрне туплап, кайберләрен югарыда әйтелгән Комплексы фәнни станциягә эшкә (0,25-0,5 ставка белән) алдыруга ирешә. Милли шура әгъзасы булган Р.Салихов бөтен кирәкле финанс кәгазьләрен эшләгәч, аларны рәисебез В.Шәйхразыевка тапшырдык. Елга кирәкле сумма 3-4 млн чамасы иде (башта гына компьютерлар, өстәл-урындыклар алу өчен өстәмә чыгымнар бар). Мәскәүгә ел саен 800 млрд сум салым озатып, әллә кайларга гуманитар ярдәмнәр ташып торган республика өчен без сораган чыгымнар күп түгел.

Ләкин, һәрвакыттагыча, бу проект урыныннан да кузгалмады, кабинетларда батты. Кыргый хәл түгел, чөнки узган елның язында БТК эшчәнлеген үзгәртеп кору буенча экспертлар төркеме эшләгән тәкъдим дә (ул Конгресс корылтаена чыгару өчен булдырылды) Кремльдәге аппарат эченнән чыкмыйча, «әреп» юкка чыкты. Конгресс җитәкчелеге дә бу очракта кирәкле адымнарны ясамады...

Ә чынлыкта Себер үзәге булдыруның башка яклары да бар иде. Моннан берничә ел элек (2019) Тубыл татар автономиясе исеменнән Рәисебез Р.Миңнехановка Төмәндә (аннан соң Тубылда да), татар мәдәнияте һәм тарихына багышланган музей төзүгә ярдәм сорап, мөрәҗәгать ясалды. Аннан шушы музейны булдыру турында күрсәтмә төшерелде. Ул эшләрне координацияләү БТК башкарма комитетына һәм Милли Шурага йөкләнде. Идеяне Төмәндә торучы эшмәкәр, БТКның андагы вәкиле Р.Насыйров күтәреп алды, ул үз акчасына бина сатып алып һәм зур суммалар кертеп, аны төзекләндерде. Ул арада мин фәкыйрегез һәм З.Тычинских булачак музейның 120 битлек концепциясен бернинди түләүсез рәвештә булдырдык. Аның эчке структурасын (бүлекләр, экспозиция урнаштыру һ.б.) билгеләдек, хәтта дизайн мәсьәләләрен дә тикшердек. Барысын да җәмәгатьчелек тәртибендә... Әмма фәнни хезмәткәрләрдән башка мондый учреждение-саклагычны ахырга кадәр төзеп булмаячагын яхшы аңлый идек. Чынлыкта, анда куелачак әйберләр дә әле җыйналмаган бит. Төмән өлкәсе хакимияте исә безнең башлангычка кырын карап торды (чит милләт албастыларына без соң кирәкмени?). Себер үзәге менә шушы музейны аякка бастыру өчен дә кирәк иде. Безнең планнар шушы якны да исәпкә алып эшләнде. Хәзер музейны төзеп бетерү, булдыру эше дә туктады. Төзеп бетергән очракта да, аның чираттагы «буш куык» булып чыгуы ихтимал, андыйларны күп күрдек.

Инде өлкән яшькә җиткән һәм күпне күргән шәхес буларак, хәзер уйга талам: берәр вакыт республикабызда милли эшләрне төптән аңлап, аларны системалы рәвештә башкару-оештыру айсбергы урыныннан кубармы икән?..

● Казахстанда чыгымнары керемнәреннән күбрәк булган түрәләрне эштән куу турында закон кабул ителгән. Дәүләт хезмәткәренә һәр очракта да чыгымнарының законлы булуын дәлилләү мөмкинлеге биреләчәк. Тагын бер яңалык – коррупция турында хәбәр иткән гражданнарны яклау хакында: аларны дисциплинар җаваплылыкка тарта яки эштән куа алмаячаклар.

● Миллиардер Илон Маск – 200 миллиард доллар акчадан колак каккан тарихта беренче кеше. Bloomberg язуынча, Tesla компаниясе акцияләре арзанайгач, 51 яшьлек Маскның байлыгы 137 миллиард доллар гына калган. Ә 2021 елның ноябрендә аның мөлкәте 340 миллиард долларга тәңгәл булган.

Шәҗәрә төзүчеләр җыены

Шәҗәрә төзү кемгә, нәрсә өчен кирәк, ата-бабаларны барлау юлында нинди кыенлыкларга очрарга мөмкин? Бу һәм башка шундый ише сорауларга җавапны Татарстан Мәдәният министрлыгы, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты ярдәме белән гаилә кыйммәтләре һәм ыру традицияләре буенча социаль проектларны тормышка ашыручы «Самородок» оешмасы үткәргән «Терра.Татарстан» исемле беренче генеалогия форумында белергә мөмкин иде.

Ул Казаныбызда ике көн дәвамында үтте. Утырышларда туган якны өйрәнүче, тарихчы галимнәр, архив хезмәткәрләре катнашты. Дәрәҗәле кунаклар арасында Рус генеалогия җәмгыяте президенты Игорь Сахаров һәм Россия генеалогия федерациясе президенты Станислав Думин да бар иде. Форум белән бер үк вакытта башкалабызның А.С.Пушкин исемендәге мәдәният үзәгендә күренекле каллиграф, текстолог галим Нәҗип Нәккаш һәм форумны оештыручыларның берсе график дизайнер Светлана Агапова төзегән шәҗәрәләрдән гаҗәеп күргәзмә оештырылган иде. «Самородок» оешмасының директоры Владимир Романовның әйтүенә караганда, февральдә генеалогия клубы утырышлары башланып китәргә тиеш, мартта исә шәҗәрә мәсьәләләренә багышланган журнал-белешмәлек дөнья күрергә тора.

Форумда С.Думинның Литва татарларына багышланган чыгышы кызыксыну уятты. Аның сүзләренә караганда, Туктамышның дусты Витовт кенәз, 1395 елда ханга каршы олысларга яу белән баргач, татарларны әсир итеп алып кайта. Шуннан башлап татарларның Литвадагы тарихын өйрәнәләр. Соңгы зур төркем татарлар Литвага XVI гасыр башында Алтын Урданың соңгы ханы Шәех Әхмәт белән килә. Литва татарлары хәрби хезмәттәдан казана, шуңа күрә алар җирле халыклар белән беррәттән (илнең сәяси тормышында катнашудан кала) бөтен хокукларга ия була. XVIII гасыр ахыры – XIX йөз башында биредә 200 ләп татар нәселе исәпләнә. Литва татарларын мәҗбүри чукындырмыйлар. Әмма XVI гасыр башында ук алар ана телләрен югалта. Гарәп язуын исә тиз генә онытмыйлар. В.Думин, мәсәлән, Литва татарларының җирле халык телендә, әмма гарәп хәрефләре белән язылган таныклыкны күрсәтте. Думин Литвадагы милләттәшләребезнең зур хокукларга, югары дәрәҗәләргә ия булган бердәнбер диярлек татарлар төркеме булуын искәртте. 200 нәселнең дә дворян дәрәҗәсен раславы турында мәгълүмат күңелгә сары май булып ятты. Әмма арада социаль дәрәҗәне раслату таныклыкларын тапшырырга соңаручылар да була. Шуңа да карамастан Литва татарларына 1764 елгы, дворян булмаганнарны бүтән түбәнрәк сословияләргә язарга, дигән канун да кагылмый. Чөнки милләттәшләребез бик бердәм була, безнең арада фәкать аксөякләр генә, крестьян-фәләннәр юк, дип бер-берсен яклый. Дворяннардан булмаган җирле халыкны мещанга язганда да, Литва татарларына аксөяк булуларын алга таба да дәлилләргә мөмкинлек бирелә. Һәм сенат расламаса да, 1917 елга кадәр бөтен Литва татарлары, шул исәптән таныклыкларны тапшырырга йоклап калганнары да дворян булып исәпләнә. Думин Литва татарларының югары дәрәҗәсен раслаган тагын бер мисал китереп үтте. Бервакыт җир һәм 130 крестьян сатып алып урнашкан Иван Степанович Соболевскийның мөселман икәне ачыклана. Мөселманнарга исә крепостнойлар тоту тыелган. Шуннан соң милләттәшләребездә нибары 1250 баш крепостной крестьян булуын санап чыгаргач, бу санны җитдигә алмыйча, Соболевскийның 130 крестьянына күз йомалар.

Галимә Эльмира Сәлахова шәҗәрәләр төзүдә метрика кенәгәләренең зур әһәмияте турында сөйләде. 1828 елгы указ белән гамәлгә кереп, 1918 елда граждaннарның хәлен теркәү турында декрет кабул ителгәнче рәсми рәвештә алып барылса да, чынлыкта метрика кенәгәләре 1930 елларга кадәр кулланылышта була. Ләкин метрика кенәгәләренең иске татар телендә гарәп графикасында алып барылуы һәм Кырым, Себер, Әстерхан татарларының тел үзенчәлекләренең чагылуы укуны кыенлаштыра. Метрика кенәгәләреннән үзеңә кирәкле мәгълүматны табу өчен, аны укучыдан ислам дине турында белеме булуы, гарәп, фарсы, төрек телләрен белүе сорала.

Рязаньнан архив белгече Екатерина Дворникова шәҗәрәләр төзүчеләрне сабыр һәм тырыш булырга, кыенлыклардан курыкмаска өндәде. Төбәкләрнең административ-территориаль бүленешен, өяз, волость исемнәрен алдан, өйрәнеп чыгу кульязма архив материалларын укуны шактый җиңеләйтәчәк, дип киңәш бирде. Революциянең беренче елларына караган соры кәгазьдә карандаш белән өч-дүрт сүзне бергә кушып, күбесен кыскартып язылган таныклыкларны уку булмастай эш тоелса да, нәсел шәҗәрәгезне төзү эшеннән бизә күрмәгез, дип үгетләде.

Яушевлар нәселеннән Булат әфәнденең чыгышы күңелләргә хуш килде. «Тамырларын белгән кешене генә җитлеккән шәхес дип әйтеп була, чөнки ул үзенең кемлеген, башкалардан өстенлекле, көчле якларын яхшы белә һәм файдалана ала», – диде ул. Бүген Яушевлар нәселендә 2 мең шәхес билгеле. Утыз буынны бернинди шәҗәрәгә дә сыйдыра торган түгел. Булат Яушев морзалар җәмгыятенең тарихи артефакт булып кына калмыйча, бүген дә бик кирәкле оешма икәнен дәлилләргә тырышты. Чыннан да, морзалар иң асыл шәхесләр була. Тарихта күп фаҗига кичереп, чукындырылуга, крестьян сословиесенә язылуга карамастан, аларның асыл сыйфатлары югалмый. XIX-XX гасыр чигендә алардан зур промышленник, хәйриячеләр үсеп чыга. Рәмиевләр – шундыйлардан. Рәмиевләрнең нәселен дәвам иткән Бәшир Рәмиев Советлар Союзында беренче санакларны («Стрела», «Урал-1») эшли. Казанның ИТ-паркы лаеклы рәвештә аның исемен йөртә. Бәширнең әтисе Искәндәр исемле була. Дуслары, хезмәттәшләре аны яратып, үз итеп «Искәндәревич» дип йөртә. «Искәндәр» ракетасы исеме дә шуннан килә. Асыл затлар буларак, морзалар һәр чорда фәндә, икътисадта, сәнгатьтә алдынгылар рәтендә тора. Бүген исә милләтнең әйдәманнары кем? Морзалар – бик югары үзаңлы шәхесләр. Бүгенге әйдәманнарыбызның милли үзаңнары ни дәрәҗәдә? Морзалар җәмгыяте – генетик хәтерне саклаучы татар дәүләтчелеге институты, дияр идем». Булат әфәнде бүген элитар катламның формалашуы дөрес бармавы җәһәтеннән уфтанды. Бу зур җитешсезлек җәмгыятнең тормышында тискәре чагылыш таба, диде. Аның йомгаклап әйткән сүзләре хәтергә уелып калды. Морзаларда тәрбия мәсьәләсе турында әйткәндә, ул чагыштыру өчен дини тәрбияне мисалга китерде. Белгәнебезчә, диндә тәрбия кыямәт көненә ышанудан, тәмугътан куркудан, оҗмахка омтылудан гыйбарәт. Морзаларда тәрбия исә белемгә нигезләнгән. Һәр буын аңа кадәрге буыннарны белә, гамәлләре белән горурлана, булмаса – көенә. Бер үк вакытта киләчәк буыннарның да шулай ук аның тормышын беләчәген, горурланачагын яки көенәчәген белә. Шуны белә торып, ничек начар яшәмәк, ничек гөнаһлы, пычрак гамәлләр кылып түбәнлеккә төшмәк кирәк, дип Булат Яушев шәҗәрәнең мәгънәсен гап-гади итеп аңлатып бирде.

Форумда яңгыраган бер сөенечле яңалык шул – «Казанские истории» газетасы мөхәррире Любовь Агеева сүзләренә караганда, 4 еллык эшнең нәтиҗәсе буларак, бүген Арча һәм Яңа Татар бистәсе зиратлары мәгълүматлары цифрлаштырылган һәм апрель айларында интернет сайтында анда күмелгәннәр турында тулы белешмә алырга мөмкин булачак. Шәҗәрә төзүдә исә зиратларның, андагы кабер ташларының әһәмияте әйтеп бетергесез зур...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.



●**Фәрит Мөхәммәтшин (әнисе ягыннан) һәм Шиһабетдин Мәрҗани шәҗәрәләре. Нәҗип Нәккаш эшләре.**

АКТАНЫШ ГАЗЕТАСЫНА 90 ЕЛ

«Татмедиа» җәмгыятенең Кама аръягы районнарында нәшер ителә торган газета мөхәррирләре узган җомгада Актаныш район үзәгенә кунакка җыелган иде. Сәбәбе сөенечле: Актаныш матбугат үзәге хезмәткәрләре капиталь ремонттан соң яңартылган үз биналарына әйләнеп кайтты. Аннары узган җәйдә Актаныш район газетасы чыга башлауга да 90 ел тулды бит, «газиз» йортлары ремонтка ябылган булу сәбәпле, ул юбилейны да билгеләп үтә алмаганнар иде, ниһаять, менә шул туган көн тантанасы да зур игътибар үзәгендә булды.

Тантанага Россия Дәүләт думасы депутаты Ә.Когогина, Казан каласыннан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Әхмәтов, «Татмедиа» матбугат агентлыгының һәм акционерлык җәмгыятенең генераль директорлары А.Сәлимгәрәев белән Ш.Садыйков, «Мәдәни җомга», «Безнең мирас» матбагаларының баш мөхәррирләре В.Имамов, Л.Лерон һәм, әйтелгәнчә, Кама аръягындагы дистәдән артык район газетасы редакторлары рәхим иткән иде. Әүвәл урамда редакциянең яңартылган бинасын ачу тантанасы булды, аннары кунаклар матбугат үзәгендәге газета редакциясе, телевизион үзәк һәм җирле радио кабинетлары белән дә танышып чыкты. Шуннан соң мөхәррирләр район үзәгендәге күп телле «Адымнар» мәктәбенә күчеп, мәгълүмат тарату, социаль челтәрләрдә эшләү, блогерларны үз мохитләренә тарту өлкәсендә тәҗрибә уртаклаштылар.

Район газетасының 90 еллыгына багышланган тантана Әлфия Авзалова исемендәге мәдәният сараенда узды. Район башлыгы Л.Зарипов белән Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Әхмәтов редакция коллективына дәүләт бүләкләре һәм сертификатлар тапшырды. А.Сәлимгәрәев белән Ш.Садыйков та район журналистларын матбугат агентлыгы һәм акционерлар җәмгыяте бүләкләре белән зурлады.

Без газеталарны «район тарихын теркәп бара торган энциклопедия», дип бәялəргә күнеккән. Актаныштa тәүге номеры 1932 елның август аенда дөньяга килгән «Колхоз ударнигы» газетасы да – үз чорының көзгесе. Анда район авылларында узган иң зур вакыйгалар, социалистик җәмгыять төзү батырлары, һәртөрле яңалыклар урын алган. Газета тора-бара «Игенче даны», «Актаныш таңнары» исемнәрен алган, татар дөньясы чагыштырмача гөрләп яшәгән елларда аның тиражы 8-9 мең данә дә тәшкил иткән. Шушы газета битләрендә ничәмә-ничә талант иясенең тәүге иҗат каләмнәре тамыр ярган, никадәрле хезмәт иясе шунда ук үзенең казанышлары турында укып сөенгәндер.

Ни кызганыч, район матбугаты да хөр тавышлы мөнбәр була алмый. Ул гына түгел, хәтта үзәк матбугат та Сталин җәлладлары хөр аваз салган меңләгән муллаunion, әдипләрне, авылдаш яки якташ булган миллионлаган кешене төрмәләргә яки Себергә озаткан чагында да яклап чыга алмаган шул. Бүген дә хөкүмәткә тел тидергән меңәрләгән адәм баласы рәшәткәләр артына озатылып тора. Әмма шундый хәвефле җәмгыятьтә дә шайтан таяклары арасыннан матур гөлләр сайлап яза алган каләм ияләре халыкның күңел яки вөҗдан чисталыгын саклый белә, менә шуның өчен аларның кадере-абруе мәңге кимемәстер.

«Тибенгән тавык җим тапмыйча калмый», дигән гыйбарә каләм ияләренә дә тәңгәл килә. Әнә, ут күршеләр үзләрендәге төньяк-көнбатыш районнарга гына түгел, хәтта элекке Минзәлә өязендәге 200 гә якын авылга да «башкортныкы» дигән мөһер сугып чыкты. Ә асылда аларның Ярмәкәй районындагы Илбакты, Нуримандагы Кызылъяр, Байкилде, Бикморза, Теңкәш, Иглино районындагы Турбаслы һәм Шиде, Әлшәйдәге Торынтаеш авылларын да бүгенге Актаныштагы дистәләгән авылдан күченгән татарлар төзеп биргән. Шул ук Актаныш җирлегеннән Илеш, Чакмагыш, Аскын, Балтач, Тәтешле, Яңавыл, Бүздәк, Краснокама, Калтасы районнарына күченеп, анда яңа нигез корган татар авылларының саны да йөздән артып китә. Актаныш матбугат үзәге журналистлары өчен газиз милләтебез мәнфәгатьләрен яклап чыгу өчен менә дигән форсат... Аннары 1812 елгы Ватан сугышына Актаныш авыллары «Башкорт-мишәр гаскәре» составында 3, 5 һәм 6 нчы, тагын 19 һәм 29 нчы «башкорт», алардан тыш Бүләр волостеннан Икенче типтәр полкларын да озаткан бит әле. Ул бабаларыбыз да һичнинди «башкортныкы» түгел, татар яугирләре. Димәк, ул югалган данны татар милләтенә кайтарырга кирәк...

Безнең татар санын соңгы җанисәп вакытында да 600 меңгә киметтеләр. Милләт булрак юкка чыкмау өчен кулга-кул тотынып көрәшү, ялган сәясәт диварларын селкетү дә фарыз.

И.ВАХИТОВ.

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

Бу – безнең дә гаеп, сезнеке дә, Беребез дә түгел әүлия...

УЕН ДӘВАМ ИТӘ

Ал тирәк, гөл тирәк,
Бездән сезгә кем кирәк?
Уен

Яңа ел ул башланмады, ахры,
Җанда дулый февраль бураны.
Узган елны купкан туфаннарның
Мизгелгә дә юк ла тынганы.

Җаннар өзгәләнде сыкрап, әрнеп,
Урладылар бәхет-шатлыкны,
Күк йөзенең аяз садәлеген,
Гаделлекнең үзен – хаклыкны.

Бәйрәм төннәре дә – матәм төне,
Гаип булган бәхет төннәре.
Күпме күңел өздә өметләрен,
Туй үткәрде тәмуг җеннәре...

Күзләрдә яшь, бугазларда төер,
Нәфрәт, ачу вә җан ачысы.
Учлар йомарланган бәддогага,
Күктә уйный үлем камчысы...

Туфракта кан, һавасында сөрем,
Күк йөзеннән тимер таш ява.
Тынып тормый мәхшәр, дәвам итә,
Сыешалмый кеше дөньяга.

Тыныч яши алмый адәм заты,
Аңа суеш, аңа кан кирәк.
Иблис мәлгунь шатлыгыннан үкерә,
Ил белән ил уйный «Ал кирәк...»

Әсирләрне алмашалар шулай,
Һәм шашалар, язып акылдан.
Күзне камаштырып оча туплар,
Чәлпәрәмә дөнья – ватылган...

Чәлпәрәмә килгән күпме язмыш,
Күпме маңгай шешкән каралып.
Канлы уен ләкин дәвам итә,
Дөнья гүя ята таралып...

УРТАК ФАҖИГА

Хакыйкать бер – кеше җаны корбан,
Атта ни дә гаеп, тәртәдә...
Һәммәбез дә буялганбыз канга,
Һәм дә буялырбыз иртәгә...

Бу мәхшәрдә кем дә садә калмас,
«Кырый йортта яшим!» – дисә дә.
Фикер-гамәлләре, сүз сөреше
Төрләнсә дә әллә ничәгә.

Бу – безнең дә гаеп, сезнеке дә,
Беребез дә түгел әүлия.
Ут эчендә, кан эчендә берәү,
Икенчеләр бары хәл җыя.

Өченчеләр – кием-салым тегә,
Дүртенчеләр – ясый коралын.
Һәрбер деталь, һәр винт үз урнында
Алга әйди сунар корабын.

Ә ул бара курсны үзгәртмичә,
Бозваткычтай, алып буразна.
Һәр якага җитә аның кулы,
Үрелә ул һәммә бугазга.

Ул аерып тормый ак-караны,
Ул тигезли барын җир белән.
Дөнья йөзе тулган корал белән,
Ә зиратлар үле ир белән.

Без ил белән хәсрәт эчләрендә,
Без ил белән тәмуг кисәве.
Сагындыра садә, ваемсыз чак,
Сагындыра көннәр кичәге...

Чистарына җиһан кешелекнең
Вәхшәтеннән дәһшәт аркылы.
Кемдер җансыз аунаганда җирдә,
Селкенми дә кемнең җан кылы...

Кешелекнең кыргый ерткычлыгы
Җир өстенә калка, шәп-шәрә.
Кыямәткә ярты карыш адым
Калуына ачык ишарә.

Хаталардан хали түгел кем дә,
Тәртәдә дә гаеп, атта да.
Фаҗигасе уртак һәммәбезгә –
Кайгы шакый һәрбер капкага.

НИ ХАКЫНА?

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –
Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук!
Г. Тукай

Кысрыкланган урыс телен яклый,
Телен тешләп, җирле халыклар,
«Урыс дөньясы» дип яуга керә –
Чыжлый камчы, җиккән камытлар...

Дирбияләр бармы, юкмы – алга!
Көнбатышка таба, сугымга...
Телсез хокуксызлар эшелоны
Рәт-рәт булып шунда сузыла.

Алда – фронт сызыгы. Юк кызыгы,
Юктыр шөһрәте дә, даны да...

Күпме гомер, күпме күз яшьләре,
Күпме хәсрәт, күпме фаҗига...

Агыла да агыла БЭТЭЭРлар,
Канлы ядкәр – мүкле танклар...
«Урыс дөньясы» дип, җанын бирә
«Дөнья» телсез иткән халыклар.

Шул ук хәлләр булган: «Фашизмны
Җиңәбез!» – дип, моннан элек тә.
«Ил бәхете!» – диеп җан атканнар
Әфган җирләренә кереп тә.

«Бердәмлек!» – дип, җанын фида кылган,
Күпме ирләр чечен җирендә.
Ичкерия – эчкерсезләр иле –
Туалмаган урыс илендә.

Һәм бүген дә эчкерлеләр сүзен
Тыңлый тугры мәхбүс халыклар.
Үлсә үлә, ләкин чыгымчылап,
Тәртәсенә типмәс – калып бар!

Шул калыптан чыкмас күндәм атлар,
Ил күрсәткән юлда – һәммәсе.
Ә тәртәгә тибәр затлар өчен
Күптән әзер дәүләт хәйләсе.

Күптән чыгарылган бар кануннар,
Күрсәтмәләр, әзер зинданнар.
Зеклар, башкисәрләр – кан коеша,
Камералар бушап калганнар...

Әмер чыккан, эш шурадан узган,
Боерылган, димәк, үтәргә!
Мәхшәр көне житте, алда – тәмуг!
Сират күперен кирәк үтәргә!

ЧИСТАРЫНУ

«Сугыш – җәмгыятьне чистарта
торган әйбер...»
Р.С.

Әйе, безне иплэп чистарталар,
Әйе, безне җайлап сөзәләр.
Ничек кенә итеп тугламыйлар:
«Түзәр әле!» – диеп, изәләр...

Чистарындык Явыз Иван килгәч,
Казансуның аунап ярында.
Нарат урманнары белән бергә
Чапты безне Пётр тагын да.

Чукындырып чистарттылар безне,
Асып, чукынмаган өчен дә.
Чистарыну чара-кораллары
Һаман сафта, һаман көчендә...

Чистарындык влач алмаштырып,
Әйе, түнтәрелеш ясап та.
Нинди генә газап чикмәдек без,
Ясак түләр өчен азакта.

Интервентларны да илдән сөрдек,
Нимес белән дә без көрәштек....
Империя генә таркалмасын!
Без шултикле кулга иләштек...

Иләштек без корыч куллыларга,
Таш йөрәкле залимнәргә дә.
Тәре асып, кара чапан киеп,
Инҗил тоткан галимнәргә дә.

Гарәпчәләп, латинчалап яздык,
Үзләштердек кирилл имлясын.
Французча да, нимесчә дә белдек,
Һәм өйрәндек инглиз җөмләсен.

Тоттырдылар ачлык уразасын,
Кылдырдылар сөрген хаҗларын.
«Панисламист» диеп, денсез чорда
Кигерделәр дәһри таҗларын.

«Пантюркистлар», «милләтчеләр» диеп,
Диварларга терәп аттылар.
Милли зыялылар җеназасыз
Ташсыз каберләргә яттылар.

Карцерларда кыям басып кундык,
ГУЛАГларда сәҗдә кылдык без,
Сазлыкларга ятып шуыштык без,
Окопларга төшеп туңдык без.

Төрек, япун, балкан, фин сугышы,
Басмачларны барып бастыру,
Интернациональ бурыч үтәү,
Ирек мәйданында ач тору!

Ичкерия төзелмәсен өчен,
Эче черек дәүләт эчендә,
Кабат «чистарыну» үтте халык,
«Чистарыну» янә көчендә.

Әйе, илне берләштерә курку,
Берләштерә хәсрәт-кайгылар.
Чынга ашмас тормыш вәгъдә итеп,
«Чистарталар», кабат алдыйлар...

ЯШӘП ЯТЫШ...

Без ялганга ышанырга мәҗбүр,
Һичьюгында, мәҗбүр килешергә.
Яманлыкны изгелеккә тиңләп,
Утта янганда да мең өшергә.

Без дәүләтен җуйган кавемнәрнең,
Үксез милләтләрнең сыңарыдыр,
Алданырга хөкем ителүче
Туган туфрак мәхбүс-колларыдыр.

Без кичәбез гомер: «Аерылырга
Яхшы түгел» дигән парлар сыман.
Бәхетлеләр булып кыланабыз,
Җиккән аттай, тәртә арасыннан...

Ил дә безне нишләтергә белми...
Үз иреннән гарык хатын төсле:
«Чит ярларга багып исермә» дип,
Авызлыклап буып тоткан көнче.

Ә үзенең – изүләре ачык,
Кемнәр генә саумый аның «сөтен».
Тик «җилбәзәк» диеп гаепләү дә
Ярамый һич – күзгә өрә төтен...

Менә шулай яшәп ятышыбыз,
Сыгылмыйча тәкъдир сынавына.
Ватан-Ана түшләренә багып,
Баш күтәрми үкчә ызанынnan.

БУ ЧОР

Ир башына тәкә алмашынган,
Урман бүлгәләнгән заман бу.
Мүкләкләргә, күтләкләргә бер дә
Артык түгел, нәп-нәкъ таман бу.

Ил башына ил каныккан чор бу,
Ызгышкан чор туган-тумача.
Татулыкка зар-интизар булып,
Утта яна җаннар меңнәрчә...

Им табалмый, ип табалмый дөнья,
Ит тарттыра «махсус» тегермән.
Дәвереме акылыннан шашкан,
Кешелекме тәмам тилергән?!

Таш гасырга кайтып төшүме бу, –
Адәм заты адәм ашаган?!
Кешелеген җуйган кешелексез
Кешеләргә чоры тап-таман!

Кешелексез кыргый кануннарга,
Канунсызлыкларга тарган чор.
Хак вә ялган тәмам буталган чор,
Бар кешелек өчен яман чор.

Кешелеккә ләкин үтә таныш,
Кемнәргәдер хәтта үтә тансык,
Балчык белән ашланган чор,
Акка кызыл буяу манган чор...

БӨЕК ҖЫРЧЫ

(Ахыры. Башы 5 нче санда).

Ул минем янга килгәндә, куҗабикә безне тәмле кайнар аш белән сыйлый иде. Училище җитәкчеләре Илһамны төрле җыеннарда, оешмаларда булган түләүсез концертларда еш җырлатты, бигрәк тә сайлаулар вакытында аңа күп эшләргә туры килде. Мондый тамашаларга ул мине де чакыра, башкаларга кушылып дустыма ихлас кул чабып утырам. Аз булса да акча эшләү максаты белән Илһам Камал театрында масса күренешләрдә катнаша башлады. Ул чакта Опера һәм балет театры спектакльләре шул бинада (хәзер Кәрим Тинчурин театры) уза иде. Шуларның берсендә Илһамны борынгы заман «сугышчысы» итеп киендереп, кулына ыргаклы сөңге тоттырып, башка «сугышчылар» сафына бастыралар. Илһам абайламый кала, аның сөңгесенең ыргагы ачылган зур пәрдәгә эләгеп, югары менеп китә, «сугышчы» коралсыз кала. «Әй, мине нык ачуландылар шуның өчен», – дип сөйләде дустым.

Тагын бер вакыйга истә калган. Ворошилов районы кызлары Татарстан радиосына студент Илһам Шакировны җырлатуны сорап, хат язган. Радиодан Илһамның җырлавын тыңлаган төрле район кешеләреннән бик күп хатлар ява башлый, аның тагын җырлавын сорыйлар. Илһам моңа шат, ул халкына хезмәт итә, өстәвенә, бераз гонорар да бирәләр. Сирәк кенә булса да, дустымны радиога чакыра башладылар. Рояльдә Екатерина Соколова, микрофон каршында Илһам, шаулаталар эфирны! Татарстан радиосы студиясендә (М.Горький урамы) Илһам мәшһүр җырчы Рәшит Ваһапов (1908-1962) белән таныша, аның өендә була, ноталар ала, җыр сәнгате турында фикерләрен белешә. Алар бергә концертларда чыгыш ясый. Тәҗрибәле Р.Ваһапов Илһамга игълымлы, хәерхаһлы мөнәсәбәттә була, аның музыка белеме алуын хуплый, киңәшләрен кызганмый.

Биредә Илһам яшьтән үк патефон, радио аша яратып тыңлаган җырчылар Гөлсем Сөләйманова (1907-1968), Зифа Басыйрова (1910-1979), Фәридә Кудашевалар (1920-2010) белән таныша, аларны ихтирам итә, күп нәрсәгә өйрәнә. Үз чиратында, татар халкының мәхәббәтен казанган җырчылар да Илһам иҗатына югары бәя бирә.

Бер бик салкын көнне мин Илһамны туганым Гөлшат апа Зәйнашеваларга алып бардым. Ул чакта апа китап нәшриятендә мөхәррир булып эшли иде. Некрасов урамындагы ярымподвалның кечкенә бүлмәле фатирда алар өчәү – ире Мөхәммәт, ике яшьлек кызы Асия яшәде. Бүлмә тар булса да, Гөлшат апаның күңеле киң, ул безне тәмле чәй белән каршы алды, сыйлады. Аны дустым белән таныштырдым, кайда укуын сөйләдем. Бу танышу соңрак аларның озак елларга сузылган иҗади дуслыгына китерде... Кызыклы, озак әңгәмәдән соң, без китәргә җыендык. Гөлшат апа әйтте: «Илһам энекәш, Казанда егетләр ак бияләй киеп йөрми, алыштыр син аларны». Әйе, Илһам кулларында әнисе бәйләп җибәргән ак йон бияләйләр иде. Гөлшат апаның киңәшен тотып, ул аларны алыштырды.

Илһам үзе катнашкан концертларга мине чакырмый калмый, без гел бергә булдык. Үзе җырламаган тамашаларга да «контрамарка» юнәлтеп миңа бирә, ә акчасыз студентка бу бик ярап куя иде.

Беркөнне Илһам яшәгән фатирына барсам, аның янында хәрби киемнән, үзенә ошаган, өлкәнрәк егет утыра. Илһамның бертуган абыйсы Кыяметдин икән, таныштык. Армия хезмәтеннән туган авылы Яңа Бүләккә кайтышлый, яраткан энесе белән күрешеп, хәлен белергә булган. Энесен, Татарстанны бик сагынган, күрәсең, Илһамны җырлатты да җырлатты. Аңа зур төзелешкә барып эшләргә тәкъдим иткәннәр. Әмма Илһам абыйсына әниләре янында, авылда калырга кушты. Анда хәзер ипи бар, ачлык чигенде, диде. Кыяметдин авылына кайтты, озак еллар колхозда шофер булып эшләде. Аның Флүр исемле улы мин эшләгән Казан авыл хуҗалыгы институтында укыды, агроном булды. Кыяметдин дә моңлы итеп җырлый иде, үзешчән концертларда катнашты, мин аны Казанда да тыңладым.

1955 ел көзенең салкын бер көнендә Илһам сөеклесе Клара Мостафина янына, университетның Ленин урамы, геология факультеты бинасындагы тулай торагына барып кайтты. Урамда сөйләшеп торгач, Клара аны үзе яши торган бүлмәгә алып керә. Ә анда 20 студент кыз көн күрә икән. Илһамның музыка училищесы студенты, җырчы икәнен әйтә дә: «Әйдә, җырла әле бер җыр!» – дип мөрәҗәгать итә. Илһам «Карурман» көен җырлап җибәрүгә, бүлмәгә тулай торакта яшәүче кызлар кереп тула, сыймаганнары коридорда җыела. Җыр тәмамлангач, кул чабып, алкышлыйлар. Җырчы студентны чәй белән сыйлап озаталар.

1956 елда Илһам мине «Зәңгәр шәл» спектакленә чакырды, анда үзе дә катнаша икән. Афишаны укыйм, аның исеме юк. Булатны кайсы артист уйнагандыр, хәтерләмим. Ә менә качкын «Булат»ның урманда, башка качаклар арасында Илһам башкаруындагы «Карурман ариясе» һич онытылмый. Ул җырлап җибәрүгә, зал тулы тамашачы тын да алмый сәхнәгә текәлде. Җыр тәмамлангач, зал алкышларга күмелде, җырны кабатлауны сорадылар. Спектакль өзелде, Булат-Илһам тагын җырлады, алкышлар тагын кабатланды! Илһамның зур сәхнәдә беренче уңышлы чыгышы татар сәнгате күгендә өр-яңа якты йолдыз балкуы, аның олуг җингә, казанышы булды, моң, җыр сәнгатендә 65 ел дәвам иткән Илһам Шакировның шанлы дәвере башланды!

Спектакльдән соң Илһамны кочаклап тәбрикләдем: «Казаныш бу, дустым, афәрин!» Илһам үзе дә гадәттән тыш дулкынланган, мондый хәлне көтмәгән. «Бу җиңүнең сәбәбе нәрсәдә?» – дим. «Җырның көчле, куәтле булуы!» Шагыйрь Харрас Әюп яза: «Гөл тамыры җирдә була, җырда була халык җаны».

● И.Шакиров һәм Е. Соколова. 1960 нчы еллар.

2020 елда дустым, профессор Казим Гарифуллин белән К.Тинчурин театры куйган «Зәңгәр шәл»не карадык. Аны Илһам җырлаган тарихи спектакль белән чагыштырып утырдым. Театр артистлары рольләрен әйбәт башкарды, ә Булатның «Карурман ариясе» зәгыйфь тавышлы булды. Театр җитәкчеләренә тәкъдимем: «Чакырыгыз бер шәп җырчыны, җырлатыгыз урманда, качаклар янында «Карурманны»!» Театр отачак! Илһам Шакиров дәрәҗәсендә булмаса да, бездә моңлы җырчылар бар бит әле!..

Илһам – яшь булса да, тырыш студент, таныла башлаган җырчы. Аның үзенә тиң бер кыз белән дуслашасы, кулга-кул тотынып театр-концертларга, экскурсияләргә, табигать кочагына йөрисе килә. Аның гашыйк булган кызы Клара Мостафина Казанда бит. Илһам Кларага үзенең саф мәхәббәте турында әйтеп, дуслык тәкъдим итә. Әмма тәкәббер кыз аны кире кага. Шуннан соң Илһамның кызларга мөнәсәбәте кискен үзгәрде. Ул бу хәлне авыр кичерде. Илһамга гашыйк булган, бу хакта аңа хат аша белдергән кызлар шактый булды, фоторәсемнәрен җибәреп, җавап көттеләр. Тик Илһамның күңеле катты, ул кызларга битараф карады, нәтиҗәдә бөтенләй өйләнмәде.

Клараның язмышына килсәк, бик аяныч булды. Университетны тәмамлагач, аны Азнакайга җибәрәләр. Анда ул кияүгә чыга, уллары туа. Ләкин ни сәбәптәндер гаилә таркала. Клара улы белән Казанга килә, телестудиядә эшли, аңа бер бүлмәле фатир бирәләр. 1970 елларда ул акылдан шаша, улы да шул авыруга дучар була...

Безгә, өченче курс студентларына, 1955 елда Ферма-2 бистәсендә институтның тулай торагында, ниһаять, урын бирделәр. Анда агрономия факультеты, өйрәнү-тәҗрибә хуҗалыгы уңышлы эшли. Без басуда, җиләк-җимеш бакчасында, терлекчелек фермасында практика үтәбез.

Илһамның музыка училищесында укуы бик киеренке дәвам итә, программа һаман катлаулана, буш вакыты калмый. Мин дә аның янына еш бара алмыйм, безнең дә эш тыгыз, җитмәсә ара ераклашты, күрешү сирәгәйде. Училищеда бер ел укыгач, Илһам 1955 елда консерваториягә керде. Ул авылдан килгән бердәнбер студент иде. Бераз укыгач, Илһам консерватория студентларына концерт бирә. Бу хакта мәшһүр җырчыбыз Зилә Сөнгатуллина бер мәкаләсендә бик җылы искә алып язды.

Консерватория ректоры, мәшһүр композитор Нәҗип Җиһанов 1951-1959 елларда РСФСР Югары Советы депутаты булып сайлана. Ул Мамадыш округында берничә очрашу үткәрә, үзе белән артистларны, Илһам Шакировны да алып бара. Очрашуларда Илһам тамашачыларның көчле алкышларына лаек була, ректор да рәхмәтен җиткерә.

Консерваториядә Илһамга Е.Абросимова һәм З.Г.Байрашева вокаль белеме бирә. Консерватория укытучысы Мансур Мозаффаров (1902-1966) белән бергә, иҗади дуслыкта моңлы җырлар иҗат итәләр. Илһам тавышына җайлап, Мансур ага махсус җыр музыкасы тудыра, аны бергәләп камилләштерәләр.

1958 елда мин галим-агроном дипломы алгач, Министрлык юлламасы белән Яңа Юл дәүләт сортлар сынау участогы (ГСУ) мөдире хезмәтенә керештем. Бәхетемә әлеге оешма үз авылымда – Иске Дөрештә урнашкан, аның 100 гектар җире, бригадасы бар иде. Каникул вакытында туган авылы Яңа Бүләккә кайткан Илһам белән Теләнче Тамакта кочаклашып күрештек, концерт карадык. Дустымны кунакка чакырдым. Елгыр атлы тарантаска утырып киттык. Алма бакчасында, күләгәдә әңгәмәбезне дәвам иттек.

Бер елны, кояшлы җәй аенда, туган авылына каникулга кайткач, Илһам Сарман районы җитәкчесенә килә. «Район халкын Иганә елгасы буена җыйсагыз, мин түләүсез концерт бирер идем», – ди. Җырчының сәер гозеренә гаҗәпләнгән түрә: «Ә ник бөтен район халкын җыярга?» – дип сорау бирә. Илһам: «Минем үзем туган район халкына җырларымны бүләк итәсем килә, ярдәм итегез!» – ди. Шаккаттыргыч, күңелле хәбәр радио аша таршырылгач, Сарманның Иганә елгасы буендагы яшел, матур болынына бик күп халык җыела, хәтта ерак авыллардан да киләләр. Кичтән башланган концерт төне буе, таң атканчы дәвам итә, Илһам туктаусыз җырлый да җырлый. Аның тиңдәшсез моңы белән сихерләнгән тамашачы, бу гомергә күрмәгән могҗизаны калдырып китәргә җыенмый, көчле алкышлар өзлексез дәвам итә.

Татарстан яшьләренең беренче фестивалендә (1957 ел) студент Илһам «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясен һәм «Җырым сиңа, Һиндстан»ны башкарды, беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде...

Консерватория студенты Илһам беркөнне (1960 ел) Гөлшат апа Зәйнашеваларга килә. Шагыйрә Илһамга үзе-

● И.Шакиров, Т.Миңнуллин, А.Арсланов.

● З.Хәбибуллин,И.Шакиров, Р.Гомәров.

ДУСТЫМ

нең берничә шигырен укырга тәкъдим итә, ә үзе чәй әзерли. Илһамга «Менәргә иде Урал тауларына» исемле шигырь бик ошый: «Гөлшат апа, бу шигырең үзе җырлап тора, мин аны композитор Мансур абыйга күрсәтим әле», – ди. М.Мозаффаров менә дигән музыка иҗат итә, икенче көнне ноталарын Илһамга тоттыра. Илһам тиз өйрәнә, ике талант Татарстан радиосына барып шул ук көнне җырны яздыра, тыңлаучыларның күңеленә хуш килә. Әмма Гөлшат Зәйнашеваның җыр текстын коммунизм әкиятенә ышанган өлкән әдипләр кабул итми, яшь шагыйрәне пессимист дип рәнҗетәләр, хәтта композитор белән Илһамга кизәнәләр. Популяр җыр озак елларга сузылган бәхәс тудыра. 1961 елның декабрендә язучы Габдрахман Әпсәләмовның 50 яшьлек юбилей мәҗлесендә «Менәргә иде Урал тауларына» җырын мәшһүр Рәшит Ваһапов башкара. Мәҗлестә текст авторы Гөлшат Зәйнашева да утыра. Җыр тәмамланган, бер әдип җырчыга: «Таптың җыр. Тауга менәргә телисең икән, мен, кем комачаулый?» – ди. Мәҗлестә үк кайнар бәхәс куба. Матбугатта урынсыз тәнкыйть мәкаләләре дә, киресенчә, җыр текстын яклаучы язмалар да пәйда була. Гөлшат Зәйнашева, әле яшь язучы, бик кыен хәлдә кала. Ул: «Әллә текстымнан ваз кичим микән?» – дип композитор М.Мозаффаровка һәм Илһам Шакировка мөрәҗәгать итә. Алар катгый каршы килә, җырны халык яратты, калсын шул килеш, диләр. Рәшит Ваһапов та: «Мин аны барыбер җырлаячакмын, чөнки мин аны яратам», – ди. Гөлшат апа җыр турында фикерен сорап Татарстан җитәкчеләренең берсе Мансур Хәсәновка мөрәҗәгать итә. Ул җырны мактый, рәхмәт әйтә.

«Социалистик Татарстан» газетасының 1964 ел, 27 ноябрь санында Илһам болай язды: «Репертуарымнан төшермичә җырлаган, М.Мозаффаров һәм Г.Зәйнашева тарафыннан туган илне яратып, аның Урал тауларына сокланып иҗат ителгән «Менәргә иде Урал тауларына» исемле әсәр турында бер шагыйрь миңа болай диде: «Тапкансың җыр! Туган илнең матурлыгын күрер өчен нигә Урал тауларына менәргә? Бөркет сайраучы кош түгел, аңа ничек кушылып җырларга?» «Гафу итегез! – дим мин ул иптәшкә. – Беренчедән, туган илнең гүзәллегенә таудан гына түгел, хәзер космостан торып та сокланалар. Икенчедән, мәсәлән, мин җырчы буларак, бу җырны башкарганда кош турында түгел, ә җир бөркетләре – совет кешеләре, Уралдагы дусларым турында уйлыйм. Образлы әйтүне шулкадәр натураль аңламыйк инде. Сандугач – сайраучы кош та бит, әмма кушылып кара син аңа! Натурализм күзлегеннән карaганда, сандугачка да кушылып җырлап булмый!»

Нәтиҗәдә тәнкыйтьчеләр түгел, күркәм, популяр җыр, аны иҗат иткән өч талант – Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе һәм халык мәхәббәте лауреатлары җиңеп чыкты. Бу моңлы җыр озын гомерле булды. Аны Хәйдәр Бигичев, Эмиль Җәләлетдинов, Идеал Ишбүләков, Рөстәм Маликов, Филүс Каһиров һ.б. күренекле җырчыларыбыз башкарды.

Илһам илебездә булган тарихи вакыйгаларга битараф калмады, аларны иҗатында чагылдырды. 1961 елның 12 апрель иртәсендә Юрий Гагаринның космоска очуын ишеткәч, ул бу зур вакыйга турында җыр иҗат итү максаты белән шагыйрә Гөлшат Зәйнашева янына, Матбугат йортына йөгерә. Алар бергәләп композитор Әнвәр Бакировка бара. Талантлы өч сәнгатькяр 4-5 сәгать эчендә «Галәм лачыны» исемле җыр иҗат итеп өлгертә, Илһам һәм композитор әле генә табадан төшкән җырны радиодан яңгырата...

Ниһаять, 1960 елда консерваторияне тәмамлау вакыты килеп җитә. Шул чакта Илһам янына Уфадан Башкортстан радиосы хезмәткәре килә, аны үзләренә эшкә чакыра. Әйбәт фатир, мул хезмәт хакы вәгъдә итә. Илһам ризалык бирергә ашыкмый, туган иле Татарстанны калдырып, чит җирдә хезмәт итүне күз алдына да китерә алмый. Бу хәбәр ректор, профессор Нәҗип Җиһановка барып ирешә. Ул Илһамны кабинетына чакырып, катгый рәвештә: «Татар филармониясенә барасың», – ди һәм юлламага кул куя. Татар җыр сәнгатендә намуслы, шанлы, ярты гасыр дәвам иткән хезмәтен бөек композитор фатихасы белән башлаган Илһам, гомере буе Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли. 1960-1992 елларда ул әйдәп баручы солист, 1992-2010 елларда – сәнгать җитәкчесе. Дустым Илһамның олуг хезмәт казанышлары бик зур һәм күптөрле, аларны санап бетерерлек түгел!

1960 елның җәендә без Илһам белән Минзәләдә очраштык. Ул чакта мин Минзәлә районы авыл хуҗалыгы идарәсендә агроном вазыйфасында, әле буйдак егет идем. Филармония беренче мәртәбә яшь артистлар төркеменнән труппа оештырып, гастрольгә җибәргән икән. Бу төркемдәге Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, башка яшь артистларның шанлы концерты тамашачылар күңеленә хуш килде, һәр җыр көчле алкышлар яулады.

Шул ук елның август һәм ноябрь айларында Илһам ике тапкыр Бөтенсоюз радиосы аша татар халык җырларын үзәккә үтәрлек итеп башкарды. Минзәләдәге дусларым белән бергә, аны сокланып, горурланып тыңладык.

Илһамның милләткә олуг хезмәтен исәпкә алып, 1960 еллар уртасында Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидат итеп күрсәтteләр. Җәмәгатьчелек тә бу гамәлне хуплады, матбугатта күп мәкаләләр дөнья күрде. Илһам һичшиксез бу олуг бүләккә лаек булачак дип, 26 апрельне көттек. Әмма ни гаҗәп, Илһамга бу премияне бирмәделәр. Илһамның үзенә әйткәннәр: «НКВД рөхсәт итмәде, чөнки сез Әстерханда гастрольдә бүләк ителгән кечкенә Коръән китабын кабул итеп алгансыз, рәхмәт әйткәнсез, бу җинаять санала, имеш. Илһам труппасында һәрчак НКВД «сексоты», ягъни шымчы йөри. Җырчы дәүләткә миллионнарча сум акча эшләп бирсә дә, шул органнарның даими күзәтүе астында була... Халык күңеленең көзгесе Илһамга Г.Тукай премиясен 1970 елда барыбер бирделәр. Ул чакта Илһам ТАССРның атказанган артисты (1964), ТАССРның халык артисты (1969), Россия Федерациясенең атказанган артисты (1968) иде инде!

Шул ук вакытта Илһамның хезмәт хакы ташка үлчим, кешечә яшәргә әле фатиры да юк. Шактый еллар ул төрле кешеләрдә өйдәш (фатирдаш) булып яшәде. Колхоз базары кырында ул яшәгән фатирда булганым бар. Хуҗасы татар, гарип ир кеше, күбрәк урында ята, өйдә чисталык, тәртип чамалы. Ул журналист, элек «Комсомольская правда»ның корреспонденты булган. Шактый озак еллар хезмәт иткәннән соң, ниһаять, Илһамга Галактионов урамындагы яңа йортта бер бүлмәле фатир бирделәр. Күп еллардан соң ул Тукай мәйданы һәм һәйкәле янындагы әйбәт йортка, өченче каттагы, балконлы иркен фатирга күчте, анда 30 ел яшәде.

1968 елда Казанга зур кунак – Казахстанның абруйлы җитәкчесе, КПСС ҮК Политбюросы, СССР Югары Советы Президиумы әгъзасы Динмөхәммәт Кунаев килә. Ул инкогнито – мыштым гына, Мәскәүдән Алма-Атага кайтышлый, юл уңай, мәшһүр Илһам Шакировның җырлавын тыңлау өчен ике көнгә махсус туктаган. Алар Мәскәүдән Ф.Табеев белән бергә кайткан. Казахстан, СССР халыклары Кунаевны казах милләтеннән дип белде. Чынлыкта ул татар икән. Уйгур язучысы Абдукәрим Ганиев документаль повестенда, Әхмәд улы Кунаев татар булса да, карьера өчен паспортында милләтен казах дип яздырган, дип раслый. Хатыны Зөһрә Шәрип кызының татар булуы күптән билгеле. Олуг кунак Ф.Табеевка гозерен – Илһам җырлавын тыңлыйсы килүе турында Мәскәүдә үк әйткән, күрәсең. Әзрәк тарихка күз салыйк.

1962 елның октябрь аенда Казахстанда «Татар әдәбияты һәм сәнгате» декадасы шаулап үтә. Татарстан җыр һәм бию ансамбле составында яшь җырчы Илһам Шакиров искиткеч моңлы итеп башкарган татар һәм казах җырлары тамашачыларның ихлас мәхәббәтен яулый. Хөкүмәт ложасында республика җитәкчесе Динмөхәммәт Кунаев та җәмәгате Зөһрә белән Казан артистларының чыгышларына кул чабып утыра. Бу тарихи декада турында Казахстан матбугатында аны мактап күп мәкаләләр дөнья күрә. Илһамның гадәттән тыш, искиткеч моңлы җырлары Кунаев күңеленә көчле тәэсир итә. Зур түрә Илһамны тыңлау өчен махсус Казанга килгән бит!

(Ахыры киләсе санда).

Марс ГАИТОВ.

Мәдәни җомга
17 февраль
№6, 2023



Василий ШУКШИН

СӘЕРЛЕ

Аны хатыны «Сәерле» дип йөртте. Кайчак ул моны ягымлы итеп әйтә иде.

Сәерленең бер үзенчәлеге бар: аның белән гел әллә нинди көтелмәгән хәлләр чыгып тора. Ул моны үзе дә авыр кичерә, газаплана, тик һаман да ниндидер күңелсез вакыйгаларга очрый. Алар болай вак-төяк шикелле, тик барыбер күңелгә тия бит.

Бер мәртәбә юлга җыенган чагында да аның белән менә нинди хәл булып алды...

Ялы вакытында абыйсы янына Уралга барып кайтмакчы булган иде, чөнки унике елга якын күрешкәннәре юк. Исәбе анда балыкка да барып карау иде.

– Ә кайда икән минем ташбаш балыгына охшаган алдавычым? – дип кычкырды ул хатынына келәттән.

– Мин каян белим ди?!

– Соң, барысы да шушында гына иде бит! – Сәерле түгәрәк, зәңгәрсу күзләре белән кырыс итеп карарга тырышты. – Калганнары монда, ә монысы юкка чыккан.

– Ташбашка охшаган дисеңме?

– Әйе. Чуртан тота торган.

– Мин аны, мөгаен, ялгыш куырганмындыр.

Сәерле бераз дәшмичә торды.

– Йә, ничек соң?

– Нәрсә?

– Тәмлеме? Ха-ха!.. – Сәерле болай җор телле булмаса да, бу юлы бик тапкыр тел белән әйтергә теләде. – Тешләрең исән калдымы соң? Ул бит алюминийдан!..

...Озак, тәмам ярты төнгә хәтле җыендылар. Ә иртән иртүк Сәерле кулындагы чемоданы белән авыл буенча атлый иде.

– Уралга! Уралга! – дип җавап кайтарды ул очраган авылдашларының: «Кая җыендың?» – дигән сорауларына каршы. Үзенең түгәрәк йөзе, түгәрәк күзләре исә ерак юлларга төкереп карауның иң югары дәрәҗәсен чагылдыра сыман иде. – Бер айкап кайтырга кирәк әле Уралны.

Ләкин Уралга хәтле ерак иде әле.

Хәзергә әле ул район исемен йөрткән шәһәргә генә килеп җитте, монда билет алып, поездга утырырга кирәк.

Тик моңарчы әле шактый вакыт бар иде. Сәерле бертуган абыйсының балаларына күчтәнәчләр – конфет, прәннек ише нәрсәләр алырга булды... Ашамлыклар кибетенә кереп чиратка басты. Аннан алда эшләпәле ир-ат, ә аның алдында иреннәрен буяган тулы гәүдәле хатын-кыз басып тора иде. Хатын-кыз акрын гына тавыш белән, эшләпәлегә карап:

– Күз алдыгызга китерәсезме, шул кадәр дә тупас, әдәпсез кеше булырга кирәк бит! – дип тиз-тиз сөйләнә, – Анда – склероз, имеш! Әйе, анда инде җиде ел склероз, тик шулай да аңа беркем дә пенсиягә китәргә тәкъдим итмәде. Ә менә бу – әле коллективны җитәкләргә аягы да кереп җитмәгән килеш – аңа шундук: «Бәлки сезгә, Александр Семеныч, пенсиягә китү яхшырак булыр?»

Эшләпәле аның сүзен җөпләп тора.

– Әйе, әйе... Алар шундый хәзер. Харап булган – склероз, имеш. Ә Сумбатыч?.. Соңгы вакытта ул да хәтере белән мактана алмый бит. Ә монысы, ничек әле ул хатынның исеме?..

Сәерле шәһәр кешеләрен хөрмәт итә. Дөрес, барысын да түгел: хулиганнар белән сатучыларны хөрмәт итми. Алардан курка иде ул.

Аның чираты килеп җиткәч, ул конфет, прәннекләр, өч плитка шоколад сатып алды да, читкәрәк китеп, аларны чемоданына сала башлады. Идәнгә күзе төшсә, чират басып торган прилавка янында, кешеләр аяк астында, илле сумлык кәгазь акча ята! Менә шулай ята бирә бу яшел юләр, ә беркем дә күрми! Сәерле шатлыгыннан хәтта калтыранып куйды, күзләре ут шикелле кабынды. Ашыгып, берәрсе аннан өлгеррәк булып чыкмасын дип, тиз генә чираттагыларга, шушы кәгазь акча турында күңеллерәк итеп, үткер сүз белән ничегрәк әйтергә икән дип уйлый башлады.

– Яхшы яшисез, гражданнар! – диде ул көр тавыш белән, кычкырып.

Барысы да аңа таба борылдылар.

– Бездә, мәсәлән, мондый кәгазьләрне җиргә ташламыйлар. – Шунда барысы да бераз җанланып алды. – Бу бит өчлек, бишлек кенә түгел, ә илле сумлык, аның өчен ярты ай эшләргә кирәк! Ә шуның хуҗасы юк!

«Мөгаен, әнә теге эшләпәле төшергәндер», – дип уйлап алды Сәерле.

Кәгазь акчаны прилавканың күренә торган җиренә куярга булдылар.

– Хәзер берәрсе йөгереп килеп җитәр, – диде сатучы хатын.

Кибеттән чыкканда, аның кәефе күтәренке иде. Менә хәзер бу акча белән ничек шулай җиңел һәм кызык килеп чыгуы турында уйлап алды: «Бездә, мәсәлән, мондый кәгазьләрне җиргә ташламыйлар!» Кинәт шунда аның өстенә кайнар су сипкән шикелле булып китте: ул саклык кассасында үзенә дә шундый ук кәгазь акча һәм тагын егерме биш сумлыкны биргәннәрен хәтерләп алды. Аның егерме биш сумлыгын менә хәзер кибеттә вaкылады, ә илле сумлыгы кесәсендә булырга тиеш... Кесәсенә тыгылса – юк!

– Минеке булган бит ул акча! – дип кычкырып җибәрде ул. – Анаңны саткыры!.. Минем акча булган лабаса!

Кинәт башына төшкән кайгысыннан хәтта йөрәге чәнчеп куйды. Шунда башына килгән иң беренче уй – барырга да: «Гражданнар, минем үз акчам икән бит ул, – дип әйтү омтылышы булды. – Мин аларны саклык кассасыннан икене алган идем: бер егерме биш сумлыкны, бер иллелекне. Егерме биш сумлыгын, менә хәзер монда вакладым, ә икенчесе – юк». Ләкин шундук бу сүзләре белән барысын да шикләндерәчәген, күпләрнең: «Әлбәттә, хуҗасы табылмагач, ул аны үзенеке итәргә тели», – дип уйлаячагын күз алдына китерде. Юк, бу акчага кулын суза алмый ул. Җитмәсә, бирмәүләре дә бар... Шулай итеп, ул үз-үзен бу уена ышандырды да...

– Нишләп менә шушындый икән соң мин?! – дип әзгәләнде Сәерле. – Хәзер нишләргә инде?..

Кире өенә кайтырга кирәк иде.

Кибет янына килде, читтән генә булса да теге кәгазь акчага күз төшереп алырга теләп, ишек төбендә басып торды да... эчкә кермичә, китеп барды. Анда керсә, бигрәк тә авыр булыр, йөрәге түзмәскә мөмкин иде.

Автобуста әченнән генә сүгенеп кайтты. Бу аның, өйдә хатыны белән аңлашыр алдыннан, кыюлыгын җыя торуы иде.

Кенәгәләреннән тагын илле сум алдылар.

Менә инде үзенең пешмәгәнлегеннән аптыраган Сәерле (аңа бу турыда хатыны да аңлатып бирде, хәтта уклау белән бер-ике мәртәбә сугып та алды) поездда бара. Әкренләп әрнүе дә басыла төште. Тәрәзә артында урманнар, агачлыклар, авыллар йөгереп кала... Кешеләр поездда керә-чыга торды, төрле хәлләр турында сөйләнделәр... Тамбурда тартып торганда, Сәерле үзе дә ниндидер бер укымышлы кыяфәтле берәүгә шундый бер хәл турында сөйләп алды.

– Безнең күрше авылда шулай бер юләр исерекбаш кулына кисәү башы тота да – әйдә әнисе артыннан куарга! Әнисе аннан куркып чаба, ә үзе: «Кулыңны пешерә күрмә, улым!» – дип кычкыра. Ә ул, исерекбаш, ыжгырып килә. Әнисенә бит! Күз алдыгызга китерәсезме, моның өчен нинди тупас, әдәпсез булырга кирәк...

– Үзегез уйлап чыгардыгызмы? – дип сорады укымышлы кеше кырыс кына, аңа күзлеге өстеннән карап.

– Нишләп? Бездә елга артында гына ул Раменское авылы...

Укымышлы тәрәзәгә таба борылды да башка сүз катмады.

Поезддан соң әле Сәерлегә сәгать ярым чамасы самолет белән очасы иде. Аның кайчандыр бер мәртәбә очканы бар, тик күптән инде. Ул самолетка кыюсыз гына кереп утырды да: «Сәгать ярым эчендә, чынлап та, моның бер шөребе дә ватылмас микән!» – дип уйлап алды. Аннары – ярыйсы, кыюланып китте. Хәтта күршесе белән сөйләшергә дә теләгән иде дә, ләкин тегесе газета укый бирде. Аңа аны уку кызыграк тоелды бугай, тере кешене тыңларга да теләмәде. Ә Сәерленең, самолетларда ашарга бирәләр, дип ишеткәне бар, аннан шуны ачыкламакчы иде. Ә монда нигәдер һаман китермиләр. Аның бик тә самолетта ашыйсы килә иде: кызык өчен!

«Кысмырландылар», – дип уйлап алды ул.

Шуннан иллюминатордан аска карап бара башлады. Анда болыт таулары күренә. Сәерле төгәл генә әйтә алмады: матур идеме алар, әллә юкмы? Ә тирә-якта: «Ах, нинди матурлык!» – дип сокланалар. Кинәт ул үзендә бер ахмак уй барлыкка килүен сизде: их, менә шушы болытларга, мамыкка төшкән шикелле, сикереп төшәсе иде! Күңеленнән ул тагын: «Мин нишләп бер дә гаҗәпләнмим икән?! Ә аста биш километр чамасы ара бит»! – дип уйлап алды. Ул үзен гаҗәпләндерү өчен менә хәзер шушы биш километрны күз алдына китереп, аны «бастырып» карады, тик... барыбер гаҗәпләнә алмады.

– Менә ничек, ә!.. Уйлап тапкан бит шушыны кеше, – диде ул күршесенә.

Тегесе аңа карап алды да, берни дә әйтмичә, газетасын укуын дәвам итте.

– Каешларыгызны эләктерегез! – диде сөйкемле яшь кенә кыз. – Җиргә төшәбез.

Сәерле тыңлаучан кыяфәт белән каешын эләктерде. Ә күршесенең уенда да юк.

– Каешны эләктерергә кушалар, – диде ул, акрын гына аңа кагылып.

– Ярар ла, – дип, күршесе газетасын читкә алып куйды да, утыргыч артына ук сөялде һәм, нәрсәнедер хәтерләгәндәй:

– Балалар – тормыш чәчәкләре, аларны башлары белән аска каратып утыртырга кирәк, – дип куйды.

– Ничек инде ул?! – диде Сәерле, аңламыйча.

Газета укучы күршесе каты итеп көлеп кенә куйды, башка сүз катмады.

Самолет тиз генә аска төшә башлады. Менә инде җир кул сузымында гына, ул ашкынып артка таба чаба. Ә самолет һаман җиргә кагылмый әле. Соңыннан белгән кешеләр әйтүенчә, очучы «ялгышкан» икән. Ниһаять, самолет җиргә бәрелде һәм барысын да шундый итеп селкергә тотынды, хәтта тешләрнең бер-берсенә бәрелгән һәм шыгырдаган тавышлары ишетелде. Газета укучы, урыныннан кубарылып, пеләш башы белән Сәерлене сөзеп алды, аннары иллюминаторга килеп сыланды, аннан исә идәнгә килеп төште. Шул вакыт эчендә ул ник бер аваз чыгарсын! Тирә-яктагыларның да ник берсе бер сүз әйтсен! Бу хәл Сәерлене гаҗәпкә калдырды. Ул да дәшмәде. Туктадылар. Исләренә килүчеләрнең беренчеләре шундук иллюминаторга ябышты һәм самолетның бәрәңге кырына төшүен абайлап алдылар.

Кабинасыннан караңгы чырайлы очучы килеп чыкты да ишеккә таба атлады. Кемдер аннан сак кына:

– Без бәрәңге басуына утырдык, ахрысы? – дип сорады.

– Сез нәрсә, үзегез күрмисезмени? – диде аңа очучы.

Бераздан куркыну бетте һәм кайбер шаянрак пассажирлар хәтта кыяр-кыймас кына шаяртып алырга да тырыштылар.

Сәерленең пеләш башлы күршесе бу вакытта үзенең ясалма теш казнасын эзли иде. Каешын ычкындырды да аңа ул үзе дә эзләшергә тотынды.

(Ахыры киләсе санда.)

Русчадан
Әхәт САФИУЛЛИН
тәрҗемәсе.

Мәдәни җомга
17 февраль
№6, 2023

«ШУЛКАДӘР НАДАН, ХӘТТА ШАККАТКЫЧ!»

Бер видеоязманы карагач, шундый фикергә килдем. Башта борчылдым, кулларымны болгый-болгый сөйләп, бар кешене туйдырып бетердем. Аннары утырып уйладым. Карале – ни дәрәҗәдә әрсезлек! Бу мактауга лаек дәрәҗәдә әрсезлек – моның өчен дә йөрәкле булу кирәк бит. Үзең шыр надан булган өлкәдә үзеңне «эксперт» итеп күрсәтеп, дәүләт учреждениесендә консультацияләр бирү – шаккаткыч кыюлыктыр.

«Идегәй» дастанын Тинчурин театрында куелуы уңаеннан «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына җыелып фикер алыштык. Рәхмәт Туфан Имаметдиновка! Кыю кешеләр хөрмәт уята. Берәү булса, чукырлар дип куркып, килмәс иде. Ә ул килде, галимнәрнең тәнкыйтьләрен кабул итте. Очрашуга килгән Илнур Миргалиев, Дамир Исхаков, Миләүшә Хәбетдинова, Рамил Төхвәтуллин, Рауза Солтанова, Фәнзилә Җәүһәровага да рәхмәт.

Тинчурин театрында консультант булып йөрергә батырчылык иткән язучы, Татарстан китап нәшрияты мөхәррире Галимҗан Гыйльмановны да чакырган идек. Ул: «Килә алмыйм, атна буе эшем күп», – диде. Ярар. Ул бит әле үзен язучы гына түгел, «галим» дип тә атый, гәрчә фәнни дәрәҗәсе бөтенләй булмаса да... Бу бик сәер хәл, әмма бүгеннән башлап, сәер булмас кебек. «Ачык университет» кысаларында аның Тинчурин театры артистларына сөйләгән лекциясен карадык, фикерләр алыштык. Бар татар шаккатты...

Бергә берне кушкач, ун була дип уйлый торган кеше була ала. Бергә берне кушкач, ун була дип уйлый торган кеше мәктәптә дә укый ала. Бергә берне кушкач, ун була дип уйлый торган кеше хәтта мәктәпне бетереп тә чыга ала, дөрес, андыйларга аттестат кына бирелми. Әмма дә инде бергә берне куша белмәгән кеше математика укытучысы була алмый!!! Ә татарга – ярый! Г.Гыйльманов Тинчурин театры артистлары алдында «Идегәй» буенча консультацияләр үткәргән, язмасын карагач, чәчләр үрә тора.

Менә ниләр сөйли:

«Идегәй» дастанын табарга кирәк каяндыр. Нәкый ага бирмәде, бик нык ялындык, барып чыкмады...»

Галимҗан Гыйльманов, «арабист буларак» фондларга барып, ике ай эчендә кырык вариантны укып, шулардан «Идегәй»не җыеп чыкканын сөйли. Ике ай эчендә!! Ышанасызмы шуңа? Фондларда сакланган вариантлардан ике ай эчендә җыеп чыккан! Ә Нәкый Исәнбәт «бирмәгән» дигән вариант – 1940 елда «Совет әдәбияты»нда басылган. Милли китапханәдә бар. Имеш, шул вариантны таба алмаган икән бу, өр-яңадан җыеп чыккан үзе. Валлаһидыр, ышанмыйм. Шул Исәнбәт вариантын тураклап бирмәделәр микән, дип тә шикләнәм әле бераз.

Алга таба Г.Гыйльманов янә дәвам итә: «Идегәй – бер генә җиңүгә дә ирешмәгән кеше инде ул... Ләкин фигура бик зур...».

Ничек җиңмәсен ди? Ә Кондырча буендагы сугышта кем җиңә? Бурсыклы янындагы сугышта кем соң өстен чыга (Сражение на Ворскле)?

Г.Гыйльманов сөйли: «Туктамыш – Казанның беренче ханы. Һәм Алтын Урданың соңгы ханы. Алтын Урданы җимергән кеше ул. Һәм тарайтып (?!), Казан ханлыгына кереп утырган кеше». Хет көл, хет ела. Википедия булса да укырга кирәк инде артистлар янына барганда. Олуг Мөхәммәд дигән исемне ишеткәне юк микәнни аның?

Г.Гыйльманов һаман сибә генә: «Казан ханлыгына әзер генә кереп утыра ул. Анда инде ханлык оешкан була». – Кем әзерләп бирде икән аңа Казан ханлыгын? Туктамыш 1406 елда һәлак була бит, ә Казан ханлыгына Олуг Мөхәммәд 1438 елда гына нигез сала.

«Ул Чыңгызлардан (чингизид). Шуңа күрә Казан ханлыгына аны куярга тиеш булалар. Башка ханнар юк». «Мин рәсми тарих буенча сөйлим!» – дип җөпләп куя әле «бөек белгеч». Тәгәрәпләр китәрсең!

Г.Гыйльманов фикеренчә, Аксак Тимер белән Туктамыш сугышы «хәзерге Актаныш тирәләре»ндә була. Шакир Мөхәммәдев «Рус-япон сугышы, яхуд Доброволец Батыргали агай» әсәрендә Батыргали агайның фикерләвен болай сурәтли бит: «Байкал, аның уенча, Африкада бик зур яна торган таудыр».

Былтыр гына Кондырча елгасы буендагы сугыш турында конференцияләр узды. Кондырча Самара өлкәсе буйлап ага, безнең Нурлат районына да кереп чыга. Күпме яздылар, күпме сөйләделәр, шул яңалыкларның һичьюгы берсен булса да ачып карарга кирәктер бит инде үзен галим дип санап йөргән кешегә?!

Г.Гыйльманов Тинчурин театры вариантында куелачак сценарийны караган. Димәк, бу әсәрнең консультанты буларак, җаваплылык аның өстендә. Ник Норадын-Идегәй конфликты кертелмәгән, диючеләргә җавап әзер – консультант шундый булган. Нигә ханбикә гади генә бер хатын итеп бирелгән, диючеләргә дә җавап шул ук.

«Бөтенесе дә ошады. Берничә генә сүзем бар... Менә Норадын. Сездә ул керми. Бәлки кертмәсәгез дә була инде. Просто кайбер халыкның күңелендә калырга мөмкин... Янәкә матур бирелгән».

Артистларга Г.Гыйльманов Идегәй турында аңлата-аңлата да, «бер бандит инде алайса» дип нәтиҗә ясый. «Әйбәт бандит! Халыкның күңелендә кала торган булгач, ул бөек бандит», дип йомгак та яңгырата.

Нугай линиясен көчәйтүдә «тарихчы» әдипнең каләм эзе дә бик аз калмагандыр. «Татар дигән әйбер әсәрдә мыскыл итеп кенә әйтелә», – ди ул артистларга. Аннан янә «ачыш» өстенә «ачыш».

«Нугайның көчле вакытлары, Казан оешып ята бит инде, Сөембикә вакытлары», дип сөйли ул Идегәй заманнарын. Моның хаталану-бутау колачлары – берәр гасыр. Бу ике вакыйга арасында ким дигәндә 110 ел ята.

Фәнни телне явызларча файдалану фактлар фәне булырга тиешле нәрсәне сүз фәненә (боткасына) әйләндерә.

Николя КОНДОРСЕ,
француз әдибе.

«Туктамыш Мәскәүне ике мәртәбә тоташ яндырып кайта. Просто яндырып кайта».

Туктамыш Мәскәүне ике тапкыр яндырмый. «Сәбәбен беләсезме? Сәбәбе бик мощный», – ди эксперт. Гыйльманов версиясе буенча, Туктамышның илчеләрен Мәскәүдә үтергәннәр икән. «Барысын үтерәләр дә асып куялар».

Мәскәүдә Туктамышның илчеләрен үтереп, асып куйганнар дигән вакыйга кайсы рәсми тарихта тасвирланган, Гыйльманов каян тапкан?

Г.Гыйльманов фикеренчә, Алтын Урда Туктамыш заманында таралган. «Мәскәү китә. Көньяклар, Кырым ханнары баш бирми. Гәрәйләр бик көчле. Башкортлар, казахлар үз ханнары белән сугышып ята (!!!) Бетә шуның белән. Ә көнбатыш, мишәр яклары теге якка китә. Касыймнар... (!!!) Алар китә, Туктамыш ханның гаебе дә шунда – тота алмый ул. Казан кала, шунда кала ул. Чыңгыз хан нәселе кирәк бит инде. Әйбәт кенә кереп утыра (!!!)».

Афәрин вә браво!!! Бу кадәр әкиятне әле берәүдән дә ишеткән юк иде. Җөмлә саен «лажа». Әйтәм бит – «шулкадәр начар, хәтта сокландырырлык». Кырым ханлыгы Туктамыш үлгәннән соң оеша. Башкортларның нинди ханнары булган? Казахлар нинди ханнар белән сугышкан ул вакытта? Касыйм ханлыгы да Казан ханлыгыннан соң гына оеша лабаса. Шаккатырлык хәл бу!..

Мин спектакль ни өчен дастаннан кире якка киткән, татарны юньсез итеп чагылдырган, урыс кенәзе җимергән Болгарны Туктамышка сылап калдырган, кансыз Аксак Тимерне юаш бабай итеп сурәтләгән, ә Идегәй дастандагы кебек фаҗигале шәхес түгел, дип уйлаган идем. Мондый Сусанин сазлыкка түгел, футбол кырына керсәң дә адаштырып калдырыр. «Идегәй»не үзенеке дип тәкъдим итә икән, башка хезмәтләре дә үзенекеме, дигән сорау туа башлый.

Театр әһелләренә дә дәгъвам бар. Казан ханлыгына Олуг Мөхәммәд нигез салган икәнен белүче бер генә булса да кеше юк идемени соң арагызда? Сезгә бит теләсә кем кереп, теләсә нинди ялганны өеп чыгып китә ала икән татар тарихы турында – ышанып утырачаксыз. Сез дә бит татар зыялылары булып саналасыз. Казан ханлыгына Олуг Мөхәммәд нигез салуын һәм Сөембикәнең Идегәй белән бер чорда яшәмәвен генә һәр татар зыялысы да белергә тиешле бит! Инде сез дә укымагач, ул китапларны, тарих турында язылган мәкаләләрне кем генә укысын соң?

Аһ, бетәргә йөз тоткан милләттер инде бу! Әдәбият галиме дип аталган кеше «Википедия»дә укып чыкмыйча консультант була икән!..

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.

МИҢГӘРДӘ –

Моңа кадәр Саба районының Миңгәр авылын кичке Сабан туйлары, саф сулы чишмәләре, ясалма күлләре, балыкчы йортлары, Сөембикә манарасына охшатып салынган мәһабәт корылмасы, зур сәламәтләндерү-ял үзәге һәм, әлбәттә инде, СССРның халык артисты Шәүкәт ага Биктимеровның музее аша белсәк, озакламый ул тагын да зуррак яңгыраш алып, эре сәнгать үзәгенә дә әйләнергә мөмкин. Яңа гына биредә рәсем сәнгате музее ачылды, Татарстанның төрле районнарыннан һәм Башкортстан, Чуашия республикаларыннан, Киров өлкәсеннән, Череповец шәһәреннән килгән кырыклап рәссам катнашында зур пленэр үтте.

Анда ике атна дәвамында йөзләгән этюд һәм картина иҗат ителде, шуларның кырыклабы Миңгәр авылына бүләк итеп бирелде һәм алар озакламый рәсем сәнгате музеенда урын алачак. Киләчәктә исә Миңгәрдә рәсем мәктәбе ачу күздә тотыла. Гап-гади авыл җирлегендә гомер тормышка ашмас кебек тоелган хыялларны бер-бер артлы чынга ашыручы – туган ягын күтәрүне ният иткән эшмәкәр, «Татарча көрәш» буенча Бөтенроссия федерациясе президенты, Россиядә танылган хуҗалык һәм җәмәгать эшлеклесе, спорт остасы Җәүдәт Минназмәтов.

Бу юнәлештә эш инде байтактан алып барыла. Моннан ел ярым элек Миңгәргә күренекле рәссам, журналист, кинорежиссер Фәйзрахман Камал кайтып төпләнә. Без аны К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының баш дирижеры, оста виолончелист, композитор Ильясның һәм әдәбият өлкәсендә үз юлын салып килүче Салаватның әтисе, утыз ел Татарстаныбыздан читтә, Санкт-Петербургта гомер кичерсә дә, балаларына милли тәрбия биргән шәхес буларак та беләбез. Кайткач, иске мәктәп бинасында остаханә ачып җибәрә. Аның бер өлешендә Ф.Камалның туганы мөгаллим, скульптура остасы, тел белгече Раушания Габидуллинаның кул эшләре булса, икенче өлешендә Ф.Камал иҗат иткән сувенир сынчыклар, майлы буяу белән ясалган картиналар һәм рәссамга төрле илләрнең күренекле осталары бүләк итеп биргән сурәтләр урын алган. Монда Сөембикә ханбикәбез, аның улы Үтәмешгәрәй сыннары да бар. Фәйзрахман Камал тарих белән кызыксынучы кылкаләм остасы буларак та таныш. Аның «Борынгы Болгар табышмаклары» фильмы Казандагы халыкара мөселман киносы фестивалендә күрсәтелеп кенә калмыйча, Төркиядәге дәрәҗәле фестивальдә дә катнашкан иде. Остаханәсендә дә ул балаларга сыннар әвәләткән, рәсемнәр ясаткан арада, «тарихтан табышмаклар чиштерә», газиз халкыбызның үткәннәре белән кызыктырырга тырыша. Ф.Камал Сөембикәгә охшатып салынган манараның эчке интерьерларын бизәү эшендә дә катнашкан. Миңгәрдә үткәрелгән ярминкәләрдә дә сувенирларын күрсәтә. Тимершыкта узачак җыенга да күргәзмә белән барырга ниятләп тора. Остаханәдә музыкаль кичәләр дә үткәрәләр. Биектаудан музыка уен кораллары ясаучы оста Җәлил Вилданов килеп, балаларны таң калдырып киткән. Рәсем сәнгатенең дә әллә нинди кызыклы төрләрен өйрәтәләр. Кукмара егете Мөнип Фатыйхов, мәсәлән, артыш агачыннан җәнлек сыннары ясап күрсәткән. Ул агачның хуш исе остаханәдә әле дә бетмәгән. Фирдәвес кызы Раушания дә әле күннән бизәнү әйберләре эшләргә, әле чигәргә өйрәтә. Кыскасы, остаханәдән балалар да, авыл халкы да өзелеп тормый. Көне буе бала-чага белән әвәрә килгән вакытлар була, дип сөйләде Фәйзрахман әфәнде. Җәй айларында якын шәһәрләрдән каникулга кайтучы балалар да кызыксынып килә, ди. Яшь буынны телефоннардан, җенесе билгеле булмаган җан ияләре турындагы сәер чит ил мультфильмнарыннан аеру өчен әйбәт шушындый остаханәләр. Раушания ханым белән эзләнеп, Миңгәр тарихы турында әзерләнгән саллы китап та озакламый басылып чыгарга тиеш икән. Остаханә байтактан эшләп, авыл халкының күңелен яулап өлгерсә дә, тантаналы ачылышы яңа гына булды. Анда рәссамның улы Ильяс Камал һәм яшь музыкант Динә Шакирова да кайткан иде. Затлы музыка тыңлап, хан-ханбикә сыннарын, милли колоритлы картиналарны карап рәхәтләнде авыл халкы. Бу көннәрдә биредә пленэрга ерак җирләрдән килгән рәссамнарның остаханәләре дә оештырылды.

Кунакчыл Миңгәр пленэрның матди ягын кайгыртса, рәссамнарны иҗат сәфәренә Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев илһамландырган. Бу сурәт остасы республикабыз буенча кырык пленэр үткәрде. Иң зур хыялы – туган ягы Сабада рәссамнарны җыю иде. Шушы як чишмә суларын эчеп үскән Шәмәрдән егете бит. Ниһаять, җитмеш яше тулгач, бу хыялын тормышка ашыруга ирешә. Рәссамнар Саба районы җитәкчелегенә рәхмәт әйтеп туя алмый. Балыкчылар комплексында аларга иркен, якты бүлмәләрдә яшәү, иҗат итү мөмкинлеге тудырылган. Киндер, буяу, кылкаләмнәр белән тәэмин ителгәннәр. Пленэр башланганда республикабызда көннәр салкын торгач, рәсем осталары өшемәсен өчен, итекләргә кадәр китерткәннәр. Вертолетта сәяхәт иттергәннәр. Рәссамнар авыр халкын, авыл урамнарын яратып сурәткә алган. Иҗат кешесе урам этедәй типкәдә яшәгән заманда зур игътибар, хөрмәт күреп, үз-үзләренә ышанычлары арта төшкән, күңелләренә илһам иңгән, бер гаилә булып шау-гөр килеп яшәгәннәр, иҗат иткәннәр. Этюдларны туган, эшләгән шәһәрләренә алып китәрләр һәм анда Татарстанның Саба районындагы Миңгәр авылы пейзажлары зур картиналарга

● Рәссам Полина Илюшкина эш вакытында.

сәнгать музее

● Эшмәкәр Җәүдәт Миннәхмәтов һәм рәссам Елена Шилина.

иңдерелер, кунакчыл Миңгәрне, киләчәкне кайгыртып яшәүче хуҗаларын, садә авыл халкын сагынып искә алырлар.

Пленэр азагында матур бүләкләү тантанасы оештырылды. Рәссамнарны Җәүдәт Миннәхмәтов һәм Саба районы башкарма комитеты җитәкчесе Марат Ишниязов сәламләде. «Иң шәп композиция», «Иң яхшы этюд» өчен рәссамнар Новиков һәм Черныйга, тамашачы мәхәббәтен яулаган Камалетдиновка махсус дипломнар һәм премияләр тапшырдылар. Миңгәр балаларын осталыкка өйрәткән Хөсәенова, Баймяшкина, Илюшкина, Евграфовага рәхмәт хатлары бирделәр. Пленэрда катнашкан өчен Самойлова, Филипповага, Николаевка да рәхмәт белдерелде. Рәссам халкының башлары күккә тиде. Бу заманда шушындый хөрмәтне тагын кая күрәсең?!

Афәрин, сабалылар! Җәүдәт, Фәйзрахман, Мөдәррис кебек егетләребез булганда сәнгать мәктәбенең сафка басачагына күңелдә тузан бөртеге кадәр дә шик юк.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.
Елена ШИЛИНА фотолары.



Даһи әдипнең рәсем күргәзмәсе

Талантлы кеше – һәрьяктан да талант, дигән гыйбарәне ишеткән бар инде. Менә, туган телебезне академиклар дәрәҗәсендә камил белүче Марсель Галиевкә Аллаһ Тәгалә башка бик күп сәләтләрне дә өеп-өеп биргән. Ул – табигатьне чиксез сөюче турист һәм натуралист та, шул табигать могҗизаларын фоторәсемнәргә оста итеп эләктереп ала белүче бик шәп фоторәссам да.

Без, дөм сукыр кешедәй, корыган агач ботаклары яки череп ауган агач төпләре яныннан гамьсез генә узып китәбез, ә Марсель әфәнде шул ботак йә төпләр арасында безнең өчен «газиз» Шүрәле гәүдәсен, йә инде «теп-тере» адәм күзләрен күреп ала. Әнә шул – фәкать үзе генә күрергә, эзләп табарга һәм күңеле сизгер кешеләрне сискәнергә мәҗбүр итәрдәй күргәзмәләрне ул былтыр да уздырган иде, быел инде, әнә, үзе сәяхәт кылырга яраткан Алтай төбәгенең табигатен үзе ясаган рәсемнәр белән дә тәкъдим иткән.

Әдәбиятны яратып, әдипләр тормышын күзәтеп баручылар өчен күптән мәгълүмдер: Марсель әфәнденең бөек шагыйребез Хәсән Туфан портретын сурәтләгән сирәк рәсеме бар. Артта – төрмә тәрәзәсендәге тимер рәшәткә, соры, җансыз диварлар. Ә алда – хәсрәткә һәм борчуларга чумган олуг шагыйрь... Хәсән аганы ничәмә-ничә профессиональ рәссам үзләренең кылкаләм очына алып карады, әмма, ни галәмәт, берсе генә дә Марсель әфәнденекенә тиң портрет тудыруга ирешә алмады шул...

Менә, аның Алтай табигатен чагылдырган, фотокадрларга сеңдереп алгандай камил рәсемнәренә карап тору да – ләззәт. Табигать – табигать инде ул, иртән – кояш калка, кичен офык шәфәкъкә күмелә сыман. Ләкин, әнә, Марсель әфәнденең әдип күзләре ташлар яки сынган агачлар арасында да рәнҗетелгән күз карашларын күреп өлгерә, кыялар арасында челтерәгән чишмәләр дә бөтенләй үзгә, сыкрый-сыкрый ага. Аның кыялар уртасына яшеренгән уйсулыклары, әллә нинди гарасатларга да бирешмәгән кыя ташлары, үзләрен фәкать меңьяшәр дип таныткан карагай-наратлары – һәммәсе дә безнең милләт, безнең татар үҗәтлеген, бөеклеген вә ныклыгын чагылдыра кебек.

Халык язучысы дәрәҗәсенә ирешкән әдипнең фоторәсемнәре дә, хәтта үз кулы белән ясаган портрет һәм табигать күренешләре бәяләп бетергесез, камил һәм сокландыргыч килеп чыга. Марсель әфәндегә янә иҗат илһамы телисе генә кала.

И.ВАХИТОВ.



УТЛЫ БИЮ ОСТАСЫ

Фламенко остасы, студия җитәкчесе Гөлсинә Галимуллинаны үз һөнәре хакында сәгатьләр буе сораштырып була. Ә профессионал биюче булып киткәнче, дистә ел буе Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгында хезмәт куйган ул.

«Мин – Балтач районы кызы бит, – ди Гөлсинә. – Иске Салавычта туып үстем. Әнием Фирдания – кадрлар бүлеге хезмәткәре, ә әтием Рафис озак еллар баш зоотехник вазыйфаларын үтәде, кызганыч, мәрхүм инде. Әтием басуларга чыкканда, мин дә аңа ияреп йөри идем...

Урта мәктәпне тәмамлагач, дәүләт һәм муниципаль хезмәт академиясендә белем алдым. Кечкенәдән бии идем, әмма биюләрнең төп һөнәрем булып китәсен күзалламадым. Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшләгәндә, читтән торып Казан аграр университетының икътисад факультетында, бухгалтерия хисабы, анализ һәм аудит белгечлегенә укыдым. Министрлыкта 2008-2017 елларда хезмәт куйдым һәм бу чорымны сагынып искә алам. Чөнки шул 9 ел эшләгән чорда Казанда татар телен куллану җирлегенең никадәр тар булуын бөтенләй сизмәгәнмен. Без бит министрлыкка татарча исәнләшеп керә, татарча саубуллашып чыга идек. Рәсми чараларның Казанда узганы русча булса да, хезмәттәшләрем белән татарча аралаштык. Анда эшләгән руслар да ипи-тозлык татарча сөйләшә иде. Халыктан килгән мөрәҗәгатьләрнең күбесе татар телендә булгач, татарча җавап бирдек. Атнасына биш көн сигезәр сәгать татарча сөйләшкәннән соң, яраткан кафега кереп, татар кыстыбыен татарча сорый алмавыңа әһәмият бирмисең икән. Министрлыктан киткәнгә 6 нчы ел. Аллага шөкер, мин күңелемә канәгатьлек бирүче яраткан эш белән шөгыльләнәм, тик хәзер тулысынча диярлек рус теле эчендә яшим. Русча гына исәнләшәм, саубуллашам, русча аңлатам, русча сорап, кофе-чәй эчәм... Юк, рус телен дә яратам, тик минем күңел Ана телемдә аралашуны сорый! Бәлки, минем кебекләр аздыр? Чөнки татарча белүче кайбер танышларыма барыбер. Алар Ана теленең бетүен табигый дип саный һәм балаларын да татар теленә өйрәтүне кирәк дип тапмый. Аяныч...»

Әңгәмәдәшемне борчыган темадан биюләргә күчәбез. Чөнки Гөлсинә Галимуллина – талантлы яшьләребезнең берсе. Ул фламенко биюенә алынуга ук испан телен өйрәнә башлаган һәм бүген испанча сөйләмне тулысынча аңлый. «Башкача мөмкин дә булмас иде! Чөнки мин 2012 елдан башлап һәр ел саен Көньяк Испаниягә, Севильяга барып, бер ай буе андагы укытучыларымнан көненә 6-7 сәгать дәвамында бию дәресләре алдым. Биюләр испан телендә генә аңлатыла, гомумән, бу карарыма җитди караштa булдым. Фламенкога өйрән, дип беркем дә йогынты ясамады. Әлеге бию белән 2009 елдан бирле шөгыльләнәм. Испаниядә көч түгеп өйрәнгән белемне хәзер практикада кулланам. Андагы берничә мәшһүр укытучы якын дусларыма әйләнде. Берникадәр вакыттан соң алар Казанда оештырылган лабораторияләргә килеп тә осталык дәресләре бирә башлады».

Гөлсинә Испаниядәге фламенко укытучыларының искиткеч осталыгы биючелеккә, хореографиягә укуга түгел, ә нәкъ менә үз гаилә династияләре тәҗрибәсенә таяна, ди. Бу мөгаллимнәрнең әниләре, әбиләре дә оста биючеләр булган. Фламенкога өйрәнү өчен хәтта Кытай, Тайвань һәм Япониядән килүчеләр бик күп икән. Испаннар үз мәдәниятләрен яратучыларга хөрмәт белән карый. Билгеле, Испаниягә юл тотканчы, Гөлсинә Казан бию студияләренең берсенә юнәлгән. Башкаладагы Анна Федорова җитәкчелегендәге фламенко студиясенә ике ел йөргән, Анна чит илгә киткәч, бер ел әлеге студиядә укыткан да. Аннары исә, биергә теләүче ун хатын-кыз белән бергәләшеп, зал табып, биюләр белән аерым шөгыльләнә башлаганнар.

«Министрлыктан китүемне аңлаучылар аз булды. «Акылыңа кил, мондый эштән үз теләге белән беркем дә китми», – диючеләр байтак иде. Әмма мин тәвәкәлләдем, хәзер дә үкенмим. Чөнки фламенко минем бөтен барлыгымны биләп алды. Билгеле, мәктәптә укыганда ук .биемәгән бию калмагандыр. Бервакыт миңа видеокассета бүләк иттеләр һәм анда фламенко остасы Мария Пахес биюе дә бар иде. Шуны карагач, соклануым бермә-бер артты. Чыннан да, фламенко – гади бию төре түгел. Аның барлыкка килүе дә үзенчәлекле: фламенко бию, җыр һәм гитара көе белән берләштерелгән сәнгать, ул ике төрле, аның берсе – бик борынгы һәм драматик стильдә, ә икенчесе – заманчарак һәм бераз гадиләштерелгән... Бу ике төр эчендә тагын иллегә якын, ә кайберәүләр фикеренчә аннан да күбрәк бию төре бар һәм алар арасында төгәл чикләрне билгеләү дә авыр. Хәзерге көн биючеләре аны һаман үзгәртә бара. Испан милли биюе фламенкога импровизацияләр хас, аның нигезендә – катлаулы ритм, үзенчәлекле техника, гәүдәнең кискен борылышлары... Бию киемнәре дә үзгә. Биюче ирләр киеме караңгы төстәге чалбар, киң җиңле ак күлмәк, кыска жилет-болеро, киң путадан гыйбарәт. Кайчак муенга кызыл яулык та тагыла. Ә хатын-кыз биюче идәнгә кадәр озын, купшы күлмәк кия. Гадәттә, аның итәге һәм җиң очлары җилфер-җилфер бәби итәкле, бөрмәле, күлмәк борчаклы җирлекле, ак, кара яисә кызыл тукымалардан тегелә. Чөнки чегәннәр дә шундый күлмәкләрдән бит. Иңнәрдәге озын чуклы испан шәле, мантон да – классик бию атрибуты. Ул билгә бәйләнеп, тамашачылар игътибарын биюченең төз гәүдәсенә юнәлтә, иңнәрдә чакта исә биюче кеше очар кошка ошый. Чәчләргә дә гадәттә матур чәч тоткычлар яисә җете төстәге чәчәк беркетелә. Тагын бер кирәк әйбер –кул җилпәзәсе. Кулларга махсус музыка инструменты – кастаньеталар тотып та биергә мөмкин. Әмма гадәттә аяк киеме үкчәләре белән ясалган ритмга, җитез итеп кул чабып яисә кул бармакларын шартлатып бию ешрак кабатлана. Чөнки кулларга кастаньеталар киеп биегәндә, кул пластикасы тарая. Тамашачыларга кастаньеталы бию ныграк ошый.

Фламенко сүзен беренче тапкыр испан драматургы Хуан Игнасио Гонсалес 1785 елда язып куйган. Әмма тарих буенча бу инде ун гасырдан артык биегән бию... Борынгы Андалусиядә һәрчак көрәш барган һәм биредә һәрчак милләтләр күченеп торган, көйләрдә дә фарсы чалымнары арткан, фламенкога хас көйләр шулай туган дип тә санаучылар бар. 1425 елда бирегә чегәннәр күчеп килгән. Чегән фольклоры көнчыгыш традицияләр белән берләшкән һәм фламенко әүвәл таверналарда гына башкарылган. Чегәннәр ябык төркем булып гомер сөргән. Алар гитарада да яхшы уйнаган. Аларны биредә дә какканнар, әлеге халыкны кабул итәргә теләмәгәннәр. Нибары XIX гасыр уртасында гына фламенко урамнарда да биелә башлаган. Фламенкологлар фикеренчә, шашкын хиссиятле бию гасыры сүрелгән чаклар да юк түгел... Ул бик гадәти биюгә әйләнеп калган вакытлар да булган. Әмма тора-бара биюче, җырчы, музыкант арасындагы диалогка, моңлы структура һәм стилистикага ия булган әлеге бию популярлаша гына барган. Мәсәлән, 1955 елны Гонсалес Климент махсус китап нәшер иткән. Махсус мәктәпләр, фламенко үзәкләре дә ачыла барган... 2010 елның 16 ноябрендә ЮНЕСКО фламенконы Бөтендөнья мирасы объекты исемлегенә кертте. Чегәннәр XIX гасырның икенче яртысына кадәр фламенконы, җырга кушылып, яланаяк кына биегәннәр, ул үзләренең, туганнары, танышларының күңелләрен ачу өчен генә башкарылган. Латин теленнән «flamma» сүзе «ялкын» дип тәрҗемә ителә. Фламенко җаны испанча «дуэндэ» сүзе белән аңлатыла, испанча ул «ут», «сихер», «хис» дигән төшенчәләрне аңлата. Биюләр мәхәббәт, шашкын хисләр, горур ялгызлык, шатлык, бәхет хакында. Фламенкода катгый кагыйдәләр юк, анда импровизацияләр, динамика, каршылыклы хисләрне ачып бирү, кайнарлык та һәм салкынлык та, көрәш тә күп... Кайчак ул сихри ритуалга, чәчәк ату могҗизасына да тиң...»

«El Deseo» бию студиясендә дә хиссиятле биюләргә генә өйрәнәләр. Студия аталышы да испанчадан «дәрт» дип тәрҗемә ителә. Җан азыгы эзләп килүчеләр арасында базарда сатучылар да, бизнес җитәкчеләре, дәүләт хезмәткәрләре дә бар... Төрле профессиядәге шушы хатын-кызлар күбрәк кышларын дәрес ала, җәй айларында биючеләр күпкә азая. Әмма аларның саны сентябрь җитүгә тагын арта. Биюләрне психотерапиягә тиңләүчеләр бар, студиягә йөрүчеләр арасында 50-60 яшьтән өлкәнрәкләр дә шактый, бүгенге көндә иң өлкән биюче ханымга – 69 яшь! (Сүз уңаеннан, фламенко бәйгеләрендә катнашучылар арасыннан яшь биючеләр белән чагыштырганда өлкән яшьтәгеләр күбрәк тә җиңә икән, бу аларның үз тормыш тәҗрибәсендәге хисләрне бию палитрасына мулдан

●Бауман урамында бию проектында.

● Сәидә Миннебаева белән.

кушулары белән дә бәйле). Көннәр буе утырып эшләүчеләргә сыгылмалы, актив хәрәкәтләр җитми, кемнәрнеңдер чылап торып биеп карыйсы килә. Кайсылары үзләрендәге тискәре эмоцияләрдән азат булу өчен, үз җаннарын дәвалау өчен бии. Кемдер биюләр тренажер залларына йөрүгә караганда яхшырак, ди. Ә кайберләре Гөлсинә Рафис кызының холык-фигылен ошатып, аның харизмасын күреп соклану өчен дә килә. Чөнки аларның җитәкчесе – Казанда иң оптимистик рухлы шәхесләрнең берсе. Канаты салынганнарның, күңелсезлеккә бирешкәннәрнең халәтен ул тиз арада күтәрә белә, боегырга ирек бирми.

– Гөлсинә, сез, бәлкем, инде ир-атларны да биергә өйрәткәнсездер? «Фламенко биергә телим» – дип килсәләр, аларны да кабул итәсезме?

– Фламенко биюләрен өйрәнергә дип өч-дүрт егет килгәне булды... Әмма алар күбесенчә биредәге сылу кызларыбызны күзләргә дип килгән булып чыкты. Арадан берсе, чыннан да, күңеленә хуш килгән биюче кызыбызга өйләнде. Ә икенчесе үзенең булачак хәләл җефетенең фламенко биергә яратканы белән килешеп, биюгә күңел салып йөрде. Алар да гаилә корды. Ягъни студиямдәге эшчәнлегем бәхетле гаилә коруларга да булышлык итте. Аннары бер шәп биюче – Алсу Мәгъсүмҗанова туганыбызга кияүгә чыгып, безнең гаилә туганына әйләнде.

– Сез узган җәй Бауман урамында узган «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектында катнашып, осталык дәресен үткәрергә дә җитештегез...

– Әйе, «Зәлидә» татар биюе буенча осталык дәресен, җанлы музыкага кушылып, халык биюләре педагог-хореографы Сәидә Миннебаева белән бергәләп үткәрдек. Аны барысы да ошатты! Сәидә белән Кабан күле янында «Ярмәк вагы» Самара татарлар биюен дә башкардык әле. Һөнәри биюче егетләр дә, тамашачылар да безгә кушылып биеде. Ярмәк авылында шушы биюне әле дә кадерләп саклаганнары өчен сөенәм. 2021 елны Кабан күле янындагы шушы мәдәни проектта Алсу Мәгъсүмҗанова белән фламенконы татар «Чабата»сы белән бергә берләштереп чыгыш ясаган идек! Бу перформансның үз тарихы бар. Безнең Балтач районы мари яклары белән чиктәш. Түгәл әйтү дә кыен, әмма районыбызда башка милләт биюләре хәрәкәтләрен дә хәтерләтеп башкарыла торган «Чабата» биюен һәрчак теләп бииләр. Сабантуйларда да, башка бәйрәмнәр дә дә... Мин әлеге биюне дә балачактан бирле күреп үстем. Берчак бу бию исемә төште дә Алсуга: «Әйдә, испан фламенкосындагы булериас стиле биюен һәм татар «Чабата»сын берләштерәбез дә, халык алдында чыгыш ясыйбыз! Аларның бию ритмнары охшаш бит!» – дип тәкъдим иттем. Алсу да теләп риза булды. Музыкантлар да таптык! Баян, аккордеон һәм гитарада уйнадылар. Кабан күле янында шушы гадәти булмаган биюне биедек. Бар тамашачылар кызыксынып карады. Аларны кушып, берләштереп биеп, татар булуыбыздан туктадык диган сүз түгел бит әле! Шул көнне үк Алсу Мәгъсүмҗанова күбесен «Чабата» биюенә өйрәтеп, осталык дәресе дә үткәрде.

2016 елда Гөлсинә белем-тәҗрибәсен «Казан» бию ансамбле коллективы белән дә уртаклашкан. Ансамбль аңа мөрәҗәгать иткәнче дә испан биюен башкарган, әмма Гөлсинә һөнәри киңәшләрен биргән, бию композицияләрен төзегән.. «Минем кызым да биргә йөрсен әле», дип үтенүче ата-аналар булса да, ул мәктәптә укучы кызларны өйрәтүгә алынмый. Беренчедән, үзен үзлегеннән биергә өйрәнүче дип саный, икенчедән, ул педагогика юнәлешендә югары белемле түгел һәм холыклары формалашып кына килгән яшүсмерләр белән эшләүнең бик зур җаваплылык икәнен аңлый.

– Яңгыравык кастаньеталар белән чыгыш ясаганыгыз булдымы?

– Аларны алып кайтканыма берничә ел узды. Явыз вирус сәбәпле карантин айлары башлангач, авылда шулар белән биергә өйрәндем. Алар ике төрле, инструментның сул кулдагысын – «мачо», ә уң кулдагысын «эмбра» дип атыйлар. Карантин айларында көн саен сәгать ярым шулар белән шөгыльләнү психологик терапия булды, тик кастаньеталар белән сәхнәләрдә чыгыш ясаганым юк әле.

– Сезнең биимичә торган вакытыгыз да бармы?

– 2020 елда минем өчен бар яктан да үрнәк булган әтиебез якты дөньядан китте. Шуннан соң берничә ай биемәдем. Шул көннәрдә рәссам Нияз Хаҗиәхмәтовның социаль челтәрдәге сәхифәсенә күзем төште. Мин аңа язылган идем. Ул да минем сәхифәмне күзәтеп бара икән. Нияз минем бик мәлем сурәтләнгән фотосурәтем нигезендә бик матур, күңелле постер ясаган! Шуны карадым да: «Биюләрем рәссамнарга да илһам өсти икән. Бу Ходайның миңа белгерткән бер билгеседер!» – дип уйладым. Үз-үземне кулга алып, студиягә юнәлдем.

– Фламенко – ул кырыс кысалардан чыгарга, үзеңне хөр итеп хис итәргә теләүчеләр биюе. Ә менә сезнең күңелегездә бу бию шундый ук кичерешләр тудырамы?

– Әнием әлегә кадәр: «Кызым, ник син татар биюләрен генә биимисең?» – дип сорый. Ул Алабугадагы мәдәни-агарту училищесын тәмамлаган режиссер булган, мәдәнияті өлкәсен яхшы белә. Үзе дә биегән кеше. 3-4 ел чамасы авыл клубы җитәкчесе дә булып эшләгән, һәвәскәр театрда да рольләр уйнаган. Тик мин аңа һәрчак бер төсле җавап бирәм: «Җан кушуым буенча биелә торган биюем – тик шушы!» Йөрәк ритмын биюләргә күчерә алуым да ошый. Бу биюне сүзләр белән аңлатып та булмый. Ул – горур, көчле рухлы, бәйсезләр, көрәшчеләр, протест белдерүчеләр тарихы кушылган бию дә. Татарлар да – үз бәйсезлекләре өчен көрәшкән халык. Әмма татар биюләрендә башка хис өстенлек сөрүен күрәм. Бу – үтә дә тыйнаклык хисе.. Мин үз милләтем телен дә, мәдәниятен дә сөям, әмма гел яулык очын тотып, күз карашларын да гел аска төбәп кенә биисе килми шул кайчак...

● Гөлсинә Галимуллина Эльвира Бәшәрова белән.

«Тукаебыз фламенконы күрсә, аны ошатыр идеме икән?» дигән уйлар да килә... Хисләр спектры мулдан булган биюләрне генә башкару теләге, ахрысы, балачактан бирле күңел түрендә йөргән. Мин моңа ирештем. Билгеле, мондый биюләр өчен аерым бер төр холык таләп ителә, аларда аерым бер сюжет линиясе булмаса да, һәркемгә аңлашыла: бу – үз идеаллары һәм прициплары булганнарның күңеленә генә туры килә торган сәнгать...

Гөлсинә Галимуллина көннәр буе биюдә. «2012 елдан башлап 2019 елга кадәр «Театр на Булаке» белән берлектә студиябез ел саен спектакль куйды. Бәлки, быел да эшләрбез. 2014 елда К.Тинчурин театры артистлары булышлыгы белән «Кружева» спектаклен дә куйдык, Зөлфия Вәлиева әлеге спектакльне әзерләгәндә, режиссер буларак ярдәм итте»... Кабан күле янында оештырылган «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектына, «Печән базары»на да үз өлешен керткән. «Сәләт» форумының мәдәни чараларындагы осталык дәресләре дә алардан читтә калмаган. 2018 елны алар югары дәрәҗәдәге биючеләрне чакырып, ике көн дәвамында чираттагы «Фламенко над Волгой» Бөтенроссия фестивален дә үткәргәннәр. «Дустым Эльвира Бәшәрова белән иганәче оешмалар да таптык, әлеге фестивальдә Россиянең иң ерак калалары, Себер яклары биючеләре дә катнашты, концертларыбызны меңнән артык тамашачы карады. Әмма Татарстандагы һөнәри биючеләр арасыннан бер катнашучы да табылмады. Югыйсә аларга да: «Биергә өйрәнеп калырга мөмкинлек булачак», – дип алдан ук хәбәр иткән идек... 2018 елда Казанда мондый биюләргә өйрәнүчеләр саны нибары йөз кеше булгандыр, хәзер инде күбрәк. Көчле бию студияләре Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Новосибирскида да бар. Әмма безнең студия кызларының адымнары кыю! Мин шушы сәнгать юнәлешендә булуым белән бәхетле... Тормышны бик яратам, башкалар да шат күңелле, оптимист булса иде!» – ди кыюсызларны да матур итеп биергә өйрәтүче ханым.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

РУХИ КҮТӘРЕЛЕШТӘН БЕР ТАЛПЫНУ

Китап киштәсен җыештырам. Аеруча «тамгалы» китапларны яратам мин. Автор белән күңелдән әңгәмә корам. Истәлекләрне барлап, һәр китапның йөзен дымлы тастымал белән сөртәм... Шул арада үземнең күзләр дә дымлана. Тик бу ачы яшьләр түгел. Шатлыктан туган тамчылар... Аллага шөкер, язмыш мине күпме бай күңелле кешеләр белән очраштырган икән.

Менә учымда сабакташым Гөлзадә Бәйрәмованың «Син һаман шул сандугач» китабы. Тышы ук якты... һәм бераз гына моңсулык та бөркелә. Җыентык 2013 елда чыккан иде. Ул чакта аны энәсеннән алып җебенә хәтле укып чыктым. Тик бер хикәя, яфрак астындагы гөмбә кебек, яшеренеп калган. «Уртача матурлыкта, уртача уңганлыкта, чыкы-мыкы килеп йөрмәс, кияүгә чыгар яше җитеп, узыбрак барса да, утырып калудан да курыкмас, үз көенчә генә яшәп ятучы, кешенекенә тимәс, үзенекен бирмәс бер кыз иде ул». Тизрәк танышасым килде Һаҗирә белән һәм «Үз хәлемне үзем беләм» хикәясенә башаягым белән кереп киттем. Менә осталык, менә нинди отышлы психологик портрет!

Берчак «Казан утлары»ның сайтын актарып утыра идем, бер шигырьгә тап булып «беректем». Исемен хәтерләмим. Күңел төпкелегеннән куптарылып меңгән хис йомарламын учка кыскан хәлдә, кат-кат укыдым. Ә икенче кулымны йөрәк турысына куеп, тирән сулыш алдым. Бу – рухи күтәрелештән талпыну һәм Күкләр тынын тоеп, күңел белән Аллаһ хозурына ялгану иде. Йә, Илаһ сакчысы, шул авторча язсаң иде ул! Гел язып торыр идем. Гөлзадә Бәйрәмованың хикәясен укыгач та шундыйрак халәт кичердем.

Һәр уңышлы ир-ат артында нинди хатын-кыз тора, диләр әле?! Мөгаен, бәхетле хатын-кыздыр. Үзен, бернигә дә карамыйча, бәхетле итеп хис итүче хатын-кыздыр. Дөнья түм-түгәрәк була алмый инде ул. Бер төше кителсә, икенчесе ялгана. Бәхетле хатын-кыз гына ир-атны уңышлы һәм бәхетле итәргә сәләтле. И-их, Һаҗирә иренә карата җылырак караштa булса иде! – дип куясың. Бәхетсез язмыштан куанычлы тормышка әверелер иде, чөнки, белеп куллансаң, хатын-кызда фәрештәләр күсәсе бар!

Һәр әдәби әсәр дә тәрбияви үзлеккә ия. Үзем дә, түбәнчелек белән баш иеп, уйга калдым. Хикәядән чыгып, минем кайсы сыйфатларымны үстерергә кирәк әле? Ә кайсыларыннан арынырга вакыт?! Китапны читкә куеп, үземә анализ ясап утырам... Вәгазьләрдә дә, дини юнәлештәге китапларда да «күркәм холык» турында еш әйтелә. Язучы да әсәрләрендә укучыны, күзгә күренмәс җепләр белән, Хак Тәгалә белән тоташтыра...

«Әллә чынлап та бар микән соң бу Ходай?!». «Теләк» хикәясендә «күчтәнәчләр салынган пакетын кочаклап ишек төбендәге урындыкка чүмәшкән Фәнисә әнә шулай уйлады». Фәнисәгә ияреп, хикәягә үзем кереп киттем. Тирән кичерешләр аша ача автор үзенең геройларының язмышларын. «Дару-уколлар нәрсә ул! Иң мөһиме – күңел савыксын. Күңелгә шом кереп урнашырга юл калмасын. Үз-үзеңә ышаныч булсын... үзеңнең нык булырга тиешлеген аңлатырга тырыша Зәйтүнә Әсгатовна авыруларына». Минем дә, баш иеп, рәхмәт әйтәсем килде табибәгә. Дөресен әйтим, фәлсәфи күзлектән чыгып тасфирланган күренешләр минем җанымны да дәвалады.

...Исем китте язучы дустыма. «Фал китабы» дигән сүзләрне ишеткән бар. Ә Гөлзадә ханым тәгаен белә, алай гына түгел, түбәндәге юлларны китерә. «Синең күңелең Юныс пәйгамбәр кебидер... Хак Тәгалә һәр эшеңне хәерле итә, сиңа яхшылык бирә, морадыңа ирешерсең, иншалла...» Мин Фал китабын ачучы ак әби каршында утырам кеби... Юныс пәйгамбәрнең әмере буенча фәрештәләр башымнан сыйпый кеби... Күңелне биләгән сафлыктан, күкләрдән иңгән илаһи яктылыктан оеплар утырам менә.

Әлеге кичерешләр «Син һаман шул сандугач» повестен укыганда туган иде. Кайсы гына күренешне алма – чынбарлыкны рухи югарылыкта хәл итә автор. Халыкчан һәм фәлсәфи фикерләр белән үрелеп бара әсәр.

...Гомер буе авылда яшәгәнгәме, бигрәк якын миңа авыл темасы. Гөлзадә белән бер төркемдә укыдык. Беренче курста, сентябрь аенда, аның туган ягында – Саба якларында булсак, икенче курста Азнакай якларына җибәрделәр. Бусы инде – безнең яклар. Актүбә бистәсеннән ерак булмаган рус авылына урнаштырдылар. «И-их, – ди студент кыз, – татар әбисе белән татар бабае йөрсен иде каршыда». Татар теленең чик сакчысы булып, Гөлзадә Бәйрәмова төрле чараларда катнаша. Ел буе сәләтле балалар өчен оештырылган бәйгеләр барды. Остазлар республика мәктәпләрендә булдылар. Телевидениедә дә чыгыш ясадылар.

Әй, туктагыз, нәрсә турында яза идем әле? Ә-ә, шулай итеп, яшәп ятабыз иконалы өйдә. Тик тартмый инде аның күңеле бу тирәлеккә. Беркөнне, көндез амбарда эшләп йөрибез. Матай белән бригадир килеп туктады. Җитәкче нидер әйтте. Мотор тавышыннан без ишетмичә дә калдык, ә Гөлзадә инде аңлап, мине чакыра. «Фәйри, әйдә, ак эшкә барабызмы?!» – ди. Электән үк елгыр ул Бәйрәм (мин аңа яратып Бәйрәмем, дип эндәшә идем). Ак эш – ашлама склады икән. Бәйрәм белешкән, эшчеләрне вахта йөртә икән. Шулай итеп, без Азнакайга кайтып йөри башладык. Татарлар оясына! Чөгендер алуга да йөрдек. Актүбәнең хуҗалык идарәсендә, соңгы көнне, конверт белән акча бирделәр. Гөлзадәнең хезмәт хакы минекеннән бер тиенгә артык иде. Кунакның күңелен күрергә теләгәндер инде безнекеләр. Рәхәтләнеп көлештек. Яратты безнең якларны Саба кызы... Асфальт юлларына дан җырлады. Кунакчыл халкына кат-кат рәхмәтләр укыды...

Китапның икенче өлешендә публицистик язмалар, әңгәмәләр урын алган. «Җырлы-моңлы еллар» дип атала ул. «Казан утлары» журналын укып, бу язмалар белән танышып бара идем. Ә болай туплап биргәч, бик күп иҗатчылар, язучылар, артистлар белән берьюлы очрашкандай булдым. Мин белгән, тирән ихтирам иткән шәхесләр турында кабат уку аеруча рәхәт булды. Якты кайтаваздай, яшьлек үзе кайткан сыман булды. Әйтик, Нияз Акмалның шигырьләрен яттан сөйләп йөри идем. Сокланып укыдым, Г.Бәйрәмова тирән язма тудырган. «Нияз Акмал шигъриятенең, талантының сере нәрсәдә соң? Гадилектә. Юк, бу такмак рәвешендәге примитив гадилек түгел, халыкчанлык дәрәҗәсендәге гадилек». Әлеге юллар «Яхшы атлар үргә чабып менә» язмасыннан алынды. Г.Бәйрәмова үзе дә лаек бу сүзләргә.

Әле хәтерлим, күп еллар элек, бер ректор-шагыйрь турында язып ятам әле, дигән иде Гөлзадә ханым. Азнакайлар белән Тукай клубына, әдип Мирсәй Гариф иҗатына багышланган кичәгә бардык. Хәзерге Язучылар берлегенең рәисенең урынбасары Рифат Корбанны (Рифат Җамал) шунда күрдем. «Ректор-шагыйрьнең күңел сүрәләре» язмасында «Танк» сүзе дә бар иде, өйгә кайткач укыдым: «Р.Корбановның академиядәге кушаматы – «Танк». Бу кушамат аңа, бәлки, фән өлкәсендә бер-бер артлы ирешкән уңышлары өчен тагылгандыр». Шигырьләрен сокланып тыңладым һәм үзегем белән милләтпәрвәрлек хисләрен тойдым. Ике шәхес – мәкалә авторы да, шагыйрь дә – минем күңелгә яктылык булып керде.

Нәфкать Нигъмәтуллин турындагы язмада тагын туктап калдым. «Моңлы көйгә ил колагын салыр». Шигъри исемдәге мәкаләдә нинди бәһа! «Шәһәрләрне җимереп, китапларны яндырып була, ләкин Моң үлемсез».

Адашым Фәйрүзә Мөслимова да күңелдә бер моң һәм сагыш булып калды:

Безнең гомер – чиксезлектә
Сызылып үтү генә...
Ак кәгазем, киткән чакта,
Уткәнгә үкендермә.

Флёра Тарханова белән әңгәмәнең биеклеген, садәлеген нинди матур сүзләр белән язйым икән?! Хатын-кызларча сихри язма килеп чыкан.

Рифә Рахманны беренче тапкыр «Яшь ленинчы» газетасында күргән идем. Фотосын да урнаштырганнар иде. Якыннан аралашмасам да, тирән бер хөрмәт белән яшәдем. Хезмәт баскычларыннан күтәрелүен дә сөенеп күзәттем һәм иҗаты белән дә танышып бардым. Гөлзадә Бәйрәмовага рәхмәтлемен, яшьтәшем турында уку бик рәхәт булды.

«Дисбемнең өч төймәсе», – ди автор. Әби. Әни. Апа.

Әнисенә тукталам... Студент чакта Гөлзадәнең туган йортында кунак булган идем. Нурлы йөзен дә хәтерлим. Чибәрлеген дә күңелгә салып куйганмын. Әйтем-мәкальләр белән сөйләшүләре бүгенгедәй исемдә. Мичтә пешкән тәбикмәгенең тәме хәтердә кебек. Кәрәз кебекләр иде...

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛОВА,
С.Сөләйманова
премиясе лауреаты.

Очрашулар булмас иде, аерылулар булмаса, ди халык мәкале. Гыйбрәтле бер очрашу Габдулла Тукайның шагыйрь иткән төбәктә – Казахстанның Уральск (Җаек) шәһәрендә булды.

Казах дуслар янында

Арчадан чыгып китүгә үк күңелне үзеңнең кече Ватаныңа читтән, ерактан торып карау, аның белән горурлану хисе биләп ала. Чит илгә чыгып киткәч бу хис тагын да арта, горурлык көчәя. Ә аерым бер җирлектә милләттәшләр белән күрешкәч, җанга җылы рәхәтлек тарала, үзеңне бөек милләт вәкиле итеп тоясың, укмашкан татар каны тамырларда көчлерәк ага башлый.

Уральск шәһәренең Татар мәдәни үзәге җитәкчесе Флера ханым бер төркем арчаларны матур сүзләр белән каршы алды. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Эльмира ханым җитәкләгән җыр һәм бию ансамбле үзенең иҗатын бүләк итте. Рәссам һәм фотограф Камил Муллашев татар мәдәни үзәген бизәүгә бик зур өлеш керткән, үзәк чын мәгънәсендә милли, аһәңле һәм зәвыклы.

Татарстан кунакларын – Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте директоры Гөлнара Гарипова, директор урынбасары Лилия Мусина һәм шәхсән мине иң әсир иткәне Җаек шәһәрендәге Тукай музеен карау булды. Шәһәрнең милли җанлы кешеләре сөекле шагыйребезнең музеен булдырган, бөртекләп экспонатлар җыйган һәм киләчәк буыннарга бу рухи мирасны тапшыра килә. Музей 2006 елның 12 декабрендә ачыла һәм татар мәдәни үзәгенә тапшырыла. Директоры танылган милләттәшебез, математика укытучысы Марат Баһаветдинов. Музей ачылу иң югары дәрәҗәдә сөйләшүләрдән соң, 2005 елда беренче Президентыбыз М.Шәймиев һәм Казахстан Президенты Н.Назарбаев килешү төзи. Килешүнең бер пункты булып Урал шәһәрендә Тукай музее ачыла.

Г.Тукай Җаек шәһәрендә 1894 елдан 1907 елга кадәр яши. 8 яшендә килә, 21 яшьтә Казан шәһәренә китә. Кырлай авылыннан аны Газизә апасы алдырта. Җизнәсе Галиәсгар Усманов аягында нык басып торучы сәүдәгәр була. Монда яшәгәндә Тукай мохтаҗлыкны белми. Шул вакыт өчен алдынгы саналган тирән белем ала. Укытучысы Мотыйгулла Төхвәтуллиннан Апуш гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. Әле яңадан Әхмәтша учительгә йөреп рус телен дә өйрәнә.

Менә шушы Мотыйгулла Төхвәтуллинның өен музей итеп сайлыйлар. Андагы яшәүчеләрне күчерү өчен өлкә хакимияте 6 квартира бирә. Мотыйгулла өенә реконструкция ясала. Музей 4 залдан тора, 400дән артык экспонат бар. Йортның подвалында элек типография булган. Анда «Урал көндәлеге», «Фикер», «Уклар», «Әл-Гаср, Әл-Җәдит» газеталары басылган. Хәзер бу типография шулай ук музей залы итеп торгызыла.

Музей белән танышканнан соң безнең делегация Тукай эзләре буенча сәяхәт итте. Бу урыннар Татар бистәсе дип атала. Бик күп татарлар яшәгән бирелә, өйләре рус һәм казах өйләреннән аерылып тора: тәрәзәләренең өске өлешләре түгәрәкләнеп эшләнгән. Мондый өйләр байтак. Менә истәлек тактасы куелган Галиәсгар Усманов йорты. «Бу йортта 1895-1900 елларда бөек татар шагыйре Габдулла Тукай яшәгән». Заманында Мотыйгулла Төхвәтуллин имам булган Кызыл мәчеттә дә булдык. Яшь Тукай анда намаз укырга йөргән. Мәчет хәзерге материаллар белән бик әйбәтләп ремонтланган, өр-яңа итеп яңартылган.

Марат Баһаветдинов безгә һәр тарихи йорт турында сөйләп бара. Җаек шәһәре яңадан татар артисткасы Галия Кайбицкая, композитор Нәҗип Җиһанов, тарихчы-галим Рәфыйк Нәфыйгов исемнәре белән дә бәйле, бу танылган шәхесләр шушы җирлектән чыккан. Татар бистәсенең тагын бер күркәм урыны Тукай паркы һәм Тукайга куелган һәйкәл. Урал мәдәни үзәге вәкилләре белән берлектә һәм Арча делегациясе белән Тукай һәйкәленә чәчәкләр салдык.

Татар бистәсендә әле дә Тукай рухы хөкем сөрә. Монда һәр агач, һәр таш Тукайны хәтерли кебек. Һавасы да күкрәкне тутырып суларлык, һәр йортның тәрәзәләреннән Тукай карап тора кебек. Менә нинди ул Җаек-Урал!

Казах халкы белән татар халкының уртаклыгы бик зур. Безнең телләребез якын, динебез бер, гореф-гадәтләребез, бәйрәмнәребез шул ук диярлек. Кичен, ял иткәндә уртак җырларыбызны да җырлап утырдык әле:

Биргәнсең син миңа
Ал нурын таңнарның,
Җыйгансың син миңа
Бар гөлен даланың...

«Әниемә» җырын без татарча, хуҗалар казахча җырлый, көе уртак, сүзләр аңлашыла. Ә эчтәлеге дә, гомумән, бар халыклар өчен дә интернациональ, иң газиз, иң якын тема.

Ике көнлек сәфәр бик тиз үтте. Мондый очрашулар һәр якны да рухи яктан баета. Казах коллегаларыбыз белән максатыбыз уртак: туган телебезне саклау, Тукай, Абай, Җиһанша кебек милли батырларыбызның данын тагын да көчәйтү, киләчәк буыннарга алар турында түкми-чәчми җиткерү. Милли каһарманнарыбызны күтәреп, без халкыбызны зурлыйбыз.

Дамир ТАҖИЕВ,
«Әлифба» музее җитәкчесе.

Айга карап карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

18 февраль (шимбә). ***Рәҗәб аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 7.50 сәгатьтә калка, 14.34 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.49 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Иммунитетны ныгыту (1)

Организм авыруларга бирешмәсен өчен, иммунитетны ныгыту зарур. Иң беренче чиратта, табыннан яшелчә һәм җиләк-җимеш өзелмәскә тиеш. Ярты стакан кайнар суга яки сөткә 1 чәй кашыгы прополис төнәтмәсе кушып, көненә 1-2 тапкыр эчү дә организмның авыруларга каршы тору сәләтен арттыра. Ә менә каты авырудан соң зәгыйфьләнгәннәргә, йөкле һәм бала имезүче хатыннарга, сабыйларга, туберкулездан интегүчеләргә, гипертония, анемия, атеросклероз белән чирләгәндә, йөрәкбавыр-бөер авырулары җәфалаганда, бик каты талчыкканда мондый катнашма файдалы: төелгән әстерхан чикләвеге һәм балны тигез микъдарда кушып, әйбәтләп болгаталар да, 100 граммын көненә 3-4 тапкырга бүлеп ашап бетерәләр.

19 февраль (якшәмбе). ***Рәҗәб аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 8.14 сәгатьтә калка, 16.12 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.54 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Иммунитетны ныгыту (2)

1 әр стакан күрәгә, йөзем, әстерхан чикләвеген, кабыгы белән 2 лимонны иттарткычтан чыгарып, 1,5 стакан бал кушалар, көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр аш кашыгы кабалар. Яисә 100 г алоэ согы, 500 г төелгән әстерхан чикләвеге, 300 г бал, 3-4 лимон согын кушып, яхшылап болгатып, көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр десерт кашыгы кабалар. Алоэ кимендә 2 еллык булырга тиеш.

20 февраль (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Сукояр йолдызлыгында, 8.26 сәгатьтә калка, 17.48 сәгатьтә бата. 10 сәгать 06 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 9.58 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Иммунитетны ныгыту (3)

Вакланган гөлҗимеш җимеше, кычыткан һәм чамбыр (чабрец) үләннәрен тигез микъдарда кушып, шуның 2 аш кашыгын термоска салалар, өстенә ярты литр кайнар су коялар, 1 сәгать төнәтәләр, көненә 2-3 тапкыр, бал кабып, яртышар стакан эчәләр. Елына 2-3 тапкыр эхинацея төнәтмәсе белән дәвалану да файдалы.

21 февраль (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,8.39 сәгатьтә калка, 19.22 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.03 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

22 февраль (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 8.48 сәгатьтә калка,20.51 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.08 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

23 февраль (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,8.56 сәгатьтә калка, 22.19 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.08 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Чыршын сихәте

Чыршын, бал икмәге (перга) – искиткеч файдалы матдә, аңарда В төркеме витаминнарының барысы да, каротиноидлар, рутин, C, D, E, H витаминнары, протеин, аминокислоталар, ферментлар һәм хәтта табигый антибиотиклар да – матдәләр алмашын җайга салу һәм организмны ныгыту өчен кирәкле бөтен нәрсә бар. Чыршынны иртән ач карынга 10ар бөртек кабу – иң яхшысы. Дәва курсы – 10 көн, аннан соң 10 көн ял, аннары – яңа курс, тагын ял, тагын 10 көн дәвалану файдалы. Елына берничә тапкыр кабатларга була.

24 февраль (җомга). ***Шәгъбән аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 9.04 сәгатьтә калка, 23.46 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.17 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчәләр файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланыуын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Рәхәт-лукум

2 стакан шикәргә ярты стакан су салып, куе ширбәт пешерәләр. Шуңа ярты стакан крахмал, 2 стакан су салып, яхшылап болгаталар. Үтә күренмәлегә әйләнгәч, майланган сай савытка бушатып, өстенә чикләвек төше сибәләр дә, суыталар. Табынга куйганда, шакмаклап кисеп, өстенә шикәр оны сибәләр.

«Ярдәм» яшәргә өйрәтә

«Ярдәм» хәйрия фонды каршындагы тернәкләндерү үзәгендә Россия Президенты грантлары фонды тарафыннан хуплау тапкан һәм илнең 100 иң яхшы проекты исәбенә кергән «Йөрәк белән күрү һәм ишетү» курслары башланды. Шушы уңайдан тернәкләндерү үзәгендә хәйрия фонды президенты Илһам Исмәгыйлев, фондның вице-президенты, Тернәкләндерү үзәге директоры, проектның җитәкчесе Мәликә Гыйльметдинова, Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары Светлана Салмина катнашында матбугат очрашуы узды.

Бүген Россиянең төрле төбәкләреннән килгән сукыр һәм начар күрүче 35 инвалид тернәкләндерү үзәгендә медицина фәннәре кандидаты Дамир Галиуллин җитәкчелегендә һәм шәфкать туташлары ярдәмендә саулыкларын ныгыта. Программа күптөрле: алар биредә мөстәкыйль яшәргә өйрәнүдән тыш, Луи Брайль системасы буенча уку һәм язу күнекмәләре, гарәп теленнән һәм башка фәннәрдән дәресләр ала, компьютер белемнәрен үзләштерә. Моннан тыш экскурсия һәм кызыклы кешеләр белән очрашулар, спектакльләр карау, музейларга, мәдәният сарайларында уза торган кичәләргә бару оештырыла. Гомумән, алганда, үзәктә укыту һәм тернәкләндерү буенча берәр айлык җиде курс эшләячәк. Курслар барлыгы 245 инвалидка исәпләнгән. Президент грантлары һәм «Ярдәм» фонды хисабына тормышка ашырыла торган әлеге проект ел ярымга исәпләнгән.

Тернәкләндерү үзәгендә инвалидлар өчен уңай шартлар тудыру өчен күп эшләнә. М.Гыйльметдинова искәрткәнчә, үзәкнең сукырларга яңа тормыш шартларына җайлашырга мөмкинлек бирүе – бәхәссез. «Йөрәк белән күрү һәм ишетү» – Россиядә тиңе булмаган, уникаль проектларның берсе. Иң мөһиме – биредә сукырлар мөстәкыйль яшәргә өйрәнә. Алар курслардан соң ярдәмчесез ашарга әзерли, көнкүрештәге мәшәкатьләрне башкарырга күнегә, кул эшләре тота. Аларны хәтта җәмәгать транспортында йөрергә дә өйрәтәләр. Курсларны узучылар бәйләп эшләгән йомшак уенчыклар, җылы киемнәр теләсә кемне хәйран итәрлек. Моннан тыш үзәктәге курсларга килүчеләр белгеч җитәкчелегендә спорткомплекста да шөгыльләнергә мөмкин. Биредәге тренажер залларында, саунада нәкъ менә сукырлар өчен уңайлыклар тудырылган. Шул ук вакытта тернәкләнүчеләргә психолог юрист ярдәме дә күрсәтелә. Тернәкләнү узучыларның күңеленә аеруча хуш килгәне – алар үзәктә үзләренә һәрдаим игътибар, кайгырту тоя. «Килүчеләрнең барысы да курслар ахырында үзгәрә, мөстәкыйль кешегә әверелә, кыюлана. Дүрт стена арасында гына яшәргә күнеккән инвалидларның үзәктән киткәч тә аралашырдай дуслары барлыкка килә. Алар компьютер белән эш итәргә өйрәнә. Бу дөньяга чыгу өчен үзе бер тәрәзә», – ди М.Гыйльметдинова. Курсларга килүчеләргә киткәндә, Брайль шрифты белән басылган Коръән биреп җибәрү дә – сукырлар өчен аеруча зур ярдәм.

●Илһам Исмәгыйлев (уңнан сулга), Мәликә Гыйльметдинова, Светлана Салмина.

Мәчетнең имамы, компьютер, әхлак, дин дәресләрен алып баручы Фәнис хәзрәт Миңгәрәев курсларга килүчеләр өчен зур рухи терәк һәм өлгедер. Алты яшеннән күрү сәләтен җуйган Фәнис хәзрәт башта әти-әнисенең ярдәме белән Казан ислам көллиятен тәмамлаган. Әлбәттә, уку җиңел бирелмәгән. Бу вакытта компьютер да, башка җайланмалар да булмаган әле. Аңа дәрестә бирелгән һәр материалны кабатлап укуны кемнән булса да сорарга туры килгән. Ул әти-әнисе белән дә төннәр буе дәрес өйрәнеп утырган. Әнисе дә китапларны конспектлап, улына ярдәм иткән. Педагоглар да, сукырларга белем бирү тәҗрибәләре булмагач, укытырга да бик теләп алынмаган. Егет «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алганда, «Ярдәм» мәчете турында ишетә. Бу вакытта үзәк оешып кына килә торган вакыт. Аллаһ йортына Гарәбстаннан Брайль системасы буенча басылган Коръән кайтартыла башлаган еллар. Ф.Миңгәрәев тә «Ярдәм»гә Коръәннәр белән танышырга килә һәм гарәп шрифтын Брайль системасында өйрәнеп чыга. Аңа Россиядә сукырларга Коръән укытуны беренче башлап җибәргән Мәликә ханымның шәкерте дәресләр бирә. Шул ук елларда «Ярдәм»дә тернәкләндерү үзәге дә барлыкка килгән. Шуннан соң инде егетнең үзенә дә биредә эшләргә насыйп була. Ф.Миңгәрәев үзәктә эшләп Россия ислам университетын да тәмамлый. Фәнис хәзрәт бик мөстәкыйль, ул гаилә корган, тернәкләндерү үзәгенә көн саен 2-3 транспорт белән үзе генә килә, төрле шәһәрләрдәге колонияләргә бара, вәгазьләр укый. Хәзрәт, имамлык эшчәнлегеннән тыш, курсларга килүчеләргә компьютер белән эш итү дәресләрен дә бирә. Биредәге компьютерларга ике төрле программа куелган. Аларның берсе һәр элементны тавыш белән хәбәр итеп бара, икенчесе исә Брайль дисплее ярдәмендә язарга, килгән текстны кул белән укырга мөмкинлек бирә. «Бу ысул ишетми, күрми торган кешеләрне үзара аралашу дөньясына алып керә. Ул инде дөньяда барган яңалыклар белән дә танышып бара ала», – ди Ф.Миңгәрәев.

●Фәнис хәзрәт Миңгәрәев.

●Марсель Ибраһимов.

●Рамил Асылбаев.

Коръән-хафиз Гыймран Шигубаев та биредә дин дәресләре бирә. Аның «Ярдәм»гә килүенә тугыз елдан артык. Мин үзем дә аның «Ярдәм» үзәгендәге беренче елларын хәтерлим әле. Ул Чечен республикасыннан, 12 яшенә кадәр Бельгиядә үскән. Әти-әнисе әле дә шунда яши. Гыймранның, Бельгиядән кайтып, Чечен республикасында яши башлаган гына вакыты була. Ул якларга сукырлар җыелышында катнашырга Илдар хәзрәт Баязитов та барып чыга. Шулай итеп Гыймран да 2013 елда «Ярдәм» мәчетенә килә һәм Коръән өйрәнә башлый. Әлбәттә, балага әти-әнисе җылысыннан башка җиңел булмагандыр. Гыймран да моны яшерми. Әмма малай бар кайгыртуны биредә эшләүчеләрдән таба. Аларның ярдәме белән ул ел ярымда Коръәнне өйрәнеп чыга. Хәзер Гыймран «Мөхәммәдия»дә укый. Егет бу көннәрдә Саратовта сукырлар арасында үтә торган Коръән-хафизлар конкурсында катнаша.

Светлана Гамбарян тернәкләндерү үзәгенә курсларга Кисловодск якларыннан килгән. Бу аның биредә өченче тапкыр булуы. Күрү мөмкинлегеннән 56 яшендә, ягъни 6 ел элек мәхрүм калган ханым биредә компьютер белән эш итәргә, дөнья яңалыклары белән танышырга, дуслары белән аралашып яшәүгә күнеккән. «Монда килгәч яңадан яшәргә өйрәндем. Ашарга да үзем әзерлим, шәһәрдә дә ярдәмчесез йөрим. Бирегә без укырга өйрәнү өчен генә килмибез, ә кабаттан яши башларга өйрәнәбез. Үзәктә күзләре начар күргән яки бөтенләй күрмәгән гап-гади кешеләр булып килеп керәбез дә иң кадерле, үз кешеләргә әвереләбез», – дип сөйли Светлана ханым.

Башкортстанның Белорецк шәһәреннән килгән Рамил Асылбаев та 47 яшеннән якты дөньяны күреп яшәүдән мәхрүм калган. Ул, Төньяк Кавказда, кайнар ноктада хезмәт иткәндә, контузия алган. Хәзер аңа – 62 яшь.

«Тернәкләндерү үзәгенә килгәнемә шатланып бетә алмыйм. Монда безне аңлыйлар, ярдәм итәргә ашкынып торалар», – ди ул. Р.Асылбаев курайда уйнап, башкорт халык моңнары белән дә хушландырды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Әдипнең беренче китабы



Татар әдәбияты тарихы һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры музее ел саен Ш.Камалның туган көненә аның тормышындагы һәм иҗатындагы халыкка бик мәгълүм булмаган вакыйгаларны ача торган нинди дә булса кызыклы күргәзмә әзерли. Быел музей язучының туууына 139 ел тулган көннәрдә кунакларны «Сада» дип аталган күргәзмә белән җәлеп итте. Ул язучының Петербург тормышы белән бәйләп корылган.

1905 ел инкыйлабы Россия халыкларын уятып җибәрү белән бергә, алар өчен яңа мөмкинлекләр дә ача. Санкт-Петербургта татар газетасы «Нур» чыга башлый. Петербург ахуны Гатаулла Баязитов, Хөсәен Фәезханов һ.б. 15 елдан артык татарча газета чыгарырга рөхсәт ала. Шул вакытта Ш.Камал да Петербургта яшәүче абыйсы Гыймади чакыруы белән Төньяк башкалага килә. «Нур» газетасының беренче санында ук Ш.Камалның фельетоны дөнья күрә. Булачак язучының «Нур» белән хезмәттәшлек итүенә Байгильдиевлар белән Баязитовларның үзара аралашып яшәве дә сәбәпче булгандыр. Санкт-Петербургта укыган һәм хезмәт иткән Гыймади, Баязитовлар ярдәмендә, хәрби ахун булып китә. Ш.Камалның төп максаты – Петербург университетына укырга керү. Ул инде инкыйлабтан соң югары белем алу мөмкинлеге ачылыр, дип тә өметләнгәндер. Әмма егетнең бу хыялы тормышка ашмый. Шулай да, Петербургта Ш.Камал тормышында әһәмиятле вакыйга була. Аның 1906 елда «Нур» газетасы басмаханәсендә «Сада» дигән беренче китабы – шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Бу вакытта аңа 22 яшь була. Китапның исеме фарсы теленнән алынган. Ул «аваз», «тавыш» дип тәрҗемә ителә. Китап белән Татар әдәбияты тарихы һәм Ш.Камал мемориаль музее директоры Айдар Шәйхин таныштырды.

31 биттән торган җыентыкта язучының биш шигыре басылган. Алар нигездә дини әчтәлектәге әсәрләр. «Китап кереш, багышлау белән ачылып китә. «Сада» дигәне – поэма кебек озын әсәр. Ш.Камалны без коммунист буларак хәтерлибез. Әмма бу елларда аның карашлары башкача була. Җыентык Аллаһны данлаудан башлана. Бу шигырьләр нәфислеге ягыннан камил түгел, тел ягыннан да госманлы йогынтысы көчле. Аларны уку өчен гарәп, фарсы төрек телләрен белергә кирәк», – дип аңлатып үтә А.Шәйхин. Ш.Камалның бу вакытта Төркиядән кайтканына да күп вакыт узмаган, аның төрек, гарәп әдәбиятларын укып үскән егет булуы нык сизелә. Ә фикер тирәнлеге ягыннан Ш.Камалның көчле публицист һәм прозаик икәне чагыла. Ул уйлана, мөселманнарны уянырга, җаһиллектән котылырга кирәклеген әйтә. Яшь язучы милләтебез алдында туган мәсьәләләрнең сәбәпчесе итеп татар байларының халкыбыз өчен тырышмавын күрә. Шигырьләрдә шулай ук 1905-1906 елларда актуаль булган проблема – дөньяда тынычлык мәсьәләсе. Бу темага «Гаскәр» дигән шигыре рус-япон сугышына бәйле рәвештә язылган. Фронтка киткән гаскәрләрдә татар егете дә булуы, аның яу кырында ятып калуы турында. Әдип моның белән милләтебезнең сугыштагы татар балалары турында да уйланырга тиешлеген белдерә.

Моннан тыш язучының «Нур» һәм «Вакыт» газеталарында чыккан аз санлы шигырьләре дә булуы мәгълүм. Алар күп түгел. «Ш.Камалның шушы җыентыкка бар шигырьләре кереп беткән диярлек», – ди А.Шәйхин. Ш.Камалның «Шура» журналына җибәрелеп тә, дөньяга чыкмый калган ике шигырен «Бастырылмаган әсәрләр» дигән җыентыгында күрергә мөмкин икән. «Тирән уйланулар белән бәйле шигырь ул. Язучы китапның керешендә аңлатмасында, шигырьләр әдәби яктан зәгыйфьрәк булса да, югалмасыннар өчен бастырырга ниятләвен искәртә.

Ш.Камал алга таба шигърияттән баш тарта, тезмә әсәрләр язмый. Без аны инде шуннан соң прозаик буларак беләбез. Ул шагыйрь буларак, танылып та китә алмас иде. Аны халкыбыз әдәбиятыбызның талантлы прозаигы буларак белә. «Матур туганда» романы өчен шигырьләр, җырлар яза, әмма инде бу тезмә жанр белән бик мавыкмый, совет чорында бу шигырьләр дә кабатлап басылмый.

Китапның төп нөсхәсе бүгенге көндә Россия дәүләт китапханәсендә саклана. Аннан музейга китапның барлык битләренең төп күчермәсенең электрон форматын җибәргәннәр. Аларны Татар китабы йортының фәнни хезмәткәре Гөлназ Җиһангирова Кирилл хәрефләренә күчергән. «Китапта фарсы да, гарәп, госманлы-төрек сүзләре дә бар. Шуңа да төгәлсезлекләрне ачыклап бетерергә кирәк. Алга таба бик җентекләп эшләргә телибез», – ди ул.

Музейда 1905 елгы революциягә кагылышлы кызык экспонатлар саклана. Күргәзмәдә шулай ук Ш.Камалның «Нур» газетасының беренче санында басылган фельетонының күчермәсе белән танышырга мөмкин. Мирасханә «Нур» газетасы урнашкан, язучы йөргән мәхәллә мәчете бинасы булган адресны тапкан. Ул Петербургтагы Мойка урамындагы 22 йортта урнашкан була. Мәчетнең тә, мәдрәсәнең дә бер бинада урнашканлыгы мәгълүм. Петербургта Бөтенроссия беренче татар мөселман съезды уза. Шәриф Камал анда, бәлки, катнашкандыр. Әмма бу вакытта ул яшьрәк була әле. Ул съездагы барлык фикер һәм тәкъдимнәрнең барысын да ишеткән, үзенә алган, шушы чордагы алдынгы фикерләр белән яшәгән. Күргәзмәдә 1905 елда Казанда инкыйлаб чолганышларында катнашып, кулга алынган революционерларның полиция карточкаларының төп нөсхәсе, большевиклар партиясенең листовкалары, 1905 елда манифестны кабул иткәннән соң, Россия Империясе Дәүләт Думасының беренче җыелышында төшерелгән фото, Санкт-Петербургның җәмигъ мәчете фотосы һ.б. бар.

Күргәзмә 23 мартка кадәр эшләячәк.

Сөембикә КАШАПОВА.

тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

17 февраль – «Тормышмы бу?..» (Г.Исхакый).
18 февраль – 11.00, 14.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 18.00 – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
19 февраль – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
20 февраль – С.Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрының «Кыз урлау» спектакле (М.Кәрим).
21 февраль – «Көл» (К.Митани).
22 февраль – «Сәфәр» (А.Шакиров).
23 февраль – 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 18.00 – «Өйләнәм.tat” (И.Зәйниев).
24 февраль – 15.00 Шәрык клубында – Балалар өчен «Нәни куллар» дип исемләнгән рәсем дәресе. 18.00 – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

17 февраль – «Царская невеста» (Н.Римский-Корсаков).
18 февраль – С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында – «Серле аваз артыннан...» дип исемләнгән камера музыкасы концерты.
21 февраль – «Трубадур» (Дж.Верди).
22 февраль – С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында – «Шаляпинга багышлау» дип исемләнгән камера музыкасы концерты.
24 февраль – «Хованщина» (М.Мусоргский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

18 февраль – «Ашина» (Р.Зәйдулла).
19 февраль – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).
21 февраль – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
22 февраль – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
23 февраль – «Полиционер» (И.Зәйниев).
24 февраль – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

18 февраль – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Супер кияү» (Т.Миннуллин).
19 февраль – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
21 февраль – 14.00, 18.30 – С.Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрының «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» исемле спектакле (З.Бигиев).
22 февраль – 13.00 – Премьера. «Хәрефләр илендә». 18.00 – «Матур-City» (А.Әхмәтгалиева).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

17 февраль – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
18 февраль – Зур залда – «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков). Кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай).
19 февраль – Зур залда – «Гуси-лебеди» (Л.Кожевников). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
21 февраль – 10.00 Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). 12.00 кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
22 февраль – «Аладдин».
23 февраль – Зур залда – «Аладдин». Кече залда – «Камыр батыр» (С.Хәсни).
24 февраль – Зур залда – Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Кәтүкнең сихри төшләре» (Х.Ибраһим, И.Нәфиев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

18 февраль – Авторларның үзләре башкаруында җырлар яңгыраячак.
19 февраль – 11.00 – Балалар өчен «Борынгы Грециянең миф һәм легендалары» дип исемләнгән концерт. 17.00 – «Мертвые души» спектакле.
20 февраль – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
21 февраль – Александр Крючко концерты.
22 февраль – Дидюля концерты.
23 февраль – «Жизель» балеты (А.Адан).
24 февраль – 15.00 -Котельнич шәһәреннән жырчы Оксана Шәйдуллина концерты. 18.30 – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

19 февраль – Татарстан Республикасы кыллы квартетының «Оставь нас с музыкой вдвоем...» дип исемләнгән концерт.
24 февраль – «La Primavera» Казан камера оркестры концерты.

Шоколад сихәте

АКШтагы Тафт университеты галимнәре кан басымы югары булган кешеләрне алар өчен махсус ясалган ачы шоколад белән дәвалаган. 100 граммлы плиткаларда флавоноидлар (бик файдалы антиоксидантлар) күп булган. Сынауда катнашучыларны икегә бүлеп, бер ай буе бер төркемгә ачы, икенчесенә ак шоколад ашатканнар да, аннары урыннарын алыштырганнар. Мондый “аралаш” дәвалану плацебо эффектын юкка чыгару һәм шоколадның чын тәэсирен дәлилләү мөмкинлеге бирә: әгәр тәэсир сизелә икән, барысында да сизеләчәк. Ак шоколадта да калорияләр һәм компонентлар кара шоколадтагы кебек үк, тик анда флавоноидлар юк. Һәм шоколадның чыннан да дәвалавы күренгән: ул систолик басымны терекөмеш баганасының уртача 12 миллиметрына, диастолик басымны 9 миллиметрына төшергән. Бер үк вакытта кандагы зыянлы холестерин микъдары да кимегән, инсулин исә нәтиҗәлерәк тәэсир иткән – бусы 2 нче типтагы диабет белән авыручылар өчен бигрәк тә мөһим, чөнки шикәр чире еш кына атеросклероз һәм гипертония белән бергә йөри һәм хәлне тагын да начарайта.

(“Fishki.net”).

Үзе бер дөнья

Кеше йөрәге, күкрәк читлегеннән алынгач та, бераз вакыт тибәргә сәләтле, чөнки аның үзенең электр системасы бар. Ашказаны кислотасы шулкадәр куәтле ки, безнең тәнебез һәр 3-4 көн саен әлеге әгъзаның лайлалы тышчасын яңартырга мәҗбүр. Кешенең борыны 50 мең төрле исне аерырга һәм хәтерендә калдырырга сәләтле. Кан тамырларының озынлыгы 96 мең чакрым тәшкил итә – бу экваторны ике ярым тапкыр урарга җитәр иде. Көн саен йөрәк йөк машинасына 32 чакрым ара үтәргә җитәрлек энергия җитештерә. Кеше 70 ел яшәү дәверендә 50 килограммга якын тиресен сала. Баш мие, йокламаганда, бер лампочканы яндырырлык электр тогы җитештерә. Кеше сөяге 31 процентка судан торса да, корычтан ныграк. Күз 10 миллион төрле төсне аера ала. Җитмеш ел яшәү дәвамында кеше йөрәге 1,5 миллион баррель кан күчерә – бу 200 тимерьюл цистернасын тутырырга җитәр иде. Безнең организм сәгатенә 180 миллион данә кызыл кан күзәнәкләре җитештерә. Бер адым ясау өчен 200 мускул эшкә җигелә. Тикшеренүчеләр кендектә бактерияләрнең 1458 яңа төрен тапкан. Кеше ике ай буе ризыксыз түзә ала. Кислородсыз 5-10 минут торырга була, шуннан соң баш мие күзәнәкләре үлә башлый. Ми 60 процентка майдан тора. Ач үлемнән котылу өчен, баш мие үзен-үзе ашаячак. Үзен чамадан артык мәгълүматтан һәм күңелсез хис-кичерешләрдән саклау өчен, баш мие күп нәрсәне онытa, бу тизрәк фикерләргә һәм яңа мәгълүматны яхшырак үзләштерергә мөмкинлек бирә.

(“Лента.ру”).

Сызгырып сөйләшәләр

Лингвистика белгечләре планетада өйрәнү өчен иң катлаулы телне атаган. Бу – Бразилиянең Амазонас штатындагы пирахан кабиләсе теле. Ул нигездә сызгыра торган авазлардан тора икән. Аралашканда, әлеге аборигеннар сүз һәм фразаларны сызгыра, аларның мәгънәсенә көйнең тональлеген танып кына төшенеп була. Норвегиядән профессор-лингвист Рольф Стоэлл әйтүенчә, пирахан – уникаль тел, шул кабиләдә тумасаң, аны аңлап та, өйрәнеп тә булмый. Тагын бер үзенчәлеге – бу телдә үткән һәм киләчәк заман юк, аралашу гел хәзерге заманда гына бара. Нәтиҗәдә халык бүгенге көн белән генә яши, тарихын да белми, киләчәк белән дә кызыксынмый.

(“The Local”).

Тамак тәмугка кертә

Дөньяда иң куркыныч ризык – фугу балыгы. Әлеге балыкның бер тамчы агуы да кешене үтерә. Тик шулай да аның тәмле итенә кызыгып гомерен куркыныч астына куярга теләүчеләр шактый. Фугудан авыз итәргә теләүчеләр бөтен җиһаннан Корея, Япония һәм Таиландка агыла. Әлеге деликатес белән сыйланырга ниятләүче үз гомерен пешекчегә ышанып тапшыра булып чыга. Бер Япониядә генә дә ел саен дистәләп гурманның гомере шулай өзелә. Тарантулның Танзаниядә яшәүче “кардәше” а-пинг үрмәкүче дә чын деликатес санала. Дөрес, сыйланыр алдыннан аның агулы казык тешләрен алып ташларга кирәк. Шулай булса да, кыздырылган шушы үрмәкүчне авыз иткәндә бу экзотик илдә ел саен Европадан килгән берничә дистә туристның гомере өзелә. Африка илләрендә үсә торган кассавадан бик тәмле сок һәм кабартма әзерлиләр, аларны сәяхәтчеләр дә яратып ашый-эчә. Тик аларның күбесе әлеге тропик үсемлек яфракларында бик күчле агу – цианлы водород булуын белми дә. Пешекче аз гына ялгыша икән, гомерең белән хушлашырга туры киләчәк.

(“Die Presse”).

Затлыдан затлы

Лимузинны күп кеше мәгънәсез машинага саный: акрын йөри, артык зур булганга, рәхәтләнеп борыла да, каядыр кереп туктый да алмый. Әмма мондый автомобильләр барыбер иң затлы санала. Иң-иңнәрен карап китик. Cadillac Beast 2009 елда Барак Обаманың махсус заказы буенча җыелган, 3 миллион доллар тора. Аны пуля тишә алмый, мылтыгы, яшь агызгыч газ сиптерү җайланмасы, янгын сүндерү системасы бар. American Dream – дөньяда иң озын лимузин, 30 метрлы, 26 көпчәкле машина 4 миллион доллар тора. Эчендә джакузи, солярий, бассейн, гаять зур караватлар, кузовының артында хәтта боралак мәйданчыгы да бар. Бәясе 2,5 миллион долларлык, 22,7 тонна авырлыктагы Midnight Rider эчендә исә 40 кеше сыйдырышлы төнге клуб урнашкан. Бәясе 1 миллион долларлык Jet Limo лимузин-очкычына 50 кеше сыя, аны авиациягә мөкиббән бер кеше Boeing 727 фюзеляжыннан ясаткан. 4,2 миллион долларлык бэтмобиль Тим Бертонның Бэтмен турындагы фильмындагы машинаның чын “игезәге” булып тора. Бруней солтаны Хәсән әл-Болкиах исә барысыннан да уздырган – аның 14 миллион долларлык Rolls-Royce Silver Spur лимузины кузовына 24 каратлы чын алтын йөгертелгән.

(“Quto.ru”).

● Cadillac Beast.



● American Dream.

● Midnight Rider.

● Jet Limo.

● Rolls-Royce Silver Spur.

● Бэтмобиль.

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

20 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00, 23.30 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.40 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.45 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
22.10 «Реальная экономика». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.35, 19.00, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «ПРАВО НА ЛЮБОВЬ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «БУДУ ЖИТЬ». 16+
14.50 «Молодая наука». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Тайна Ладоги. «Малютки». 6+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
23.45 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Федот Шубин.
7.35 «Величайшая победа Цезаря. Осада Алезии».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «Забытое ремесло».
9.05, 16.30 «АНТОША РЫБКИН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Терем-теремок. Сказка для взрослых».
12.20 Дневник XVI Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи.
12.50 «ТАЙНА «ЧЕРНЫХ ДРОЗДОВ».
14.30 «Надежда Казанцева. Парадоксы судьбы».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 Цвет времени. Альбрехт Дюрер. «Меланхолия».
17.20 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова. П.И. Чайковский. Избранные произведения.
18.45 «Чистая победа. Сталинград».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 «Спокойной ночи, малыши!»
20.55 «Семена, которые спасут человечество».
21.35 «Сати. Нескучная классика...»
22.20 «ВЗРОСЛЫЕ ДЕТИ».

«НТВ»

4.45 «СТАЖЁРЫ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00, 0.00 «МЕЛЬНИК». 16+

Сишәмбе

21 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Казаннан - казанга». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 0.15 «Соотечественники». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «ПРАВО НА ЛЮБОВЬ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «БУДУ ЖИТЬ». 16+
14.50 «Молодая наука». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Софийский Крест. Голубь мира». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 11.30, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00, 13.00, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию.
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию.
13.00, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
23.45 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Осажденные крепости. Легендарные битвы».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «НА ДАЛЬНЕЙ ТОЧКЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Путешествие по Москве».
12.20 Дневник XVI Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи.
12.50 «ВЗРОСЛЫЕ ДЕТИ».
14.05 Сказки из глины и дерева.
14.20 «Игра в бисер» «Поэзия Евгения Рейна».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Виктор Васнецов».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.40 «Забытое ремесло».
17.55 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова. С. Рахманинов. «Колокола».
18.45 «Чистая победа. Битва за Эльбрус».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 «Спокойной ночи, малыши!»
20.55 Искусственный отбор.
21.35 «Белая студия».
22.20 «СЕРЕЖА».

«НТВ»

4.55 «БОМЖИХА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.20 «ДЕЛЬТА.». 16+
11.00, 13.00 «Место встречи».
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию.
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00, 0.00 «МЕЛЬНИК». 16+

Чәршәмбе

22 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.15 «Туган авылым». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
17.30 «Трибуна «Нового века». 16+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Спортивная среда». 6+
23.50 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
9.40 «Язмыш». Әзһәр Шакиров турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «ПРАВО НА ЛЮБОВЬ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПРОЩАТЬСЯ НЕ БУДЕМ». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Хроника безвременья». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Дети».
23.55 «ЖЕНЯ, ЖЕНЕЧКА И КАТЮША».

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ». 12+
23.45 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Осажденные крепости. Легендарные битвы».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «ЛЕТО РЯДОВОГО ДЕДОВА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Михаил Фрунзе».
12.20 Дневник XVI Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи.
12.50 «СЕРЕЖА».
14.05 «Беларусь. Несвижский замок».
14.30 80 лет со дня рождения Эдуарда Лимонова. Открытая книга. «Мои живописцы».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Пелешян. Кино. Жизнь».
15.50 «Белая студия».
17.40 «Забытое ремесло».
17.55 20 лет Национальному филармоническому оркестру России под управлением Владимира Спивакова. Б. Барток, Э. Блох, М. Равель. Избранные произведения.
18.45 «Чистая победа. Величайшее воздушное сражение в истории».
19.45 «Перед «Аудиенцией».
20.15 Спектакль «Аудиенция».
22.35 «2 Верник 2».

«НТВ»

4.50 «БОМЖИХА-2». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА.». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00 «МЕЛЬНИК». 16+

Пәнҗешәмбе

23 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 21.10 «Соотечественники». 16+
6.30 «ЧЕМПИОНЫ». 6+
8.15 «ЧЕМПИОНЫ. БЫСТРЕЕ. ВЫШЕ. СИЛЬНЕЕ». 16+
10.00 Благотворительный телемарафон «Всё для Победы!»
14.00 «Ватандашлар». 16+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
15.00 Спектакль «Моңлы бер җир». 16+
17.00 «Татарлар». 12+
17.30 Легенды Российской разведки. «Ибрагим Аганин». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+
23.00 «ОТЕЦ СОЛДАТА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 Спектакль «Умырзая». 16+
8.30 «Палитра». Бакый Урманче. 16+
9.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
10.00 «Барысы да Җиңү өчен!» Хәйрия телемарафоны.
14.00 «Туган авылым». 12+
14.30, 23.30 «Ватандашлар». 16+
15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
15.30 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
18.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Бакый Урманче турында телеочерк. 16+
19.15 «Татар сүзе». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
21.25 «Мин бу җирне матурларга тудым». Әнгам Атнабаев иҗатына багышланган кичә. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «НА ПОРОГЕ ЛЮБВИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.00 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». ОСТРОВ СМЕРТИ». 16+
14.50 «Рассекреченная история». 12+
15.20 «Прокуроры 6. Профессия-следователь». 12+
16.10 «Праздничный концерт ко Дню Защитника Отечества». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ПРИКАЗАНО УНИЧТОЖИТЬ! ОПЕРАЦИЯ: «КИТАЙСКАЯ ШКАТУЛКА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

7.00 «Доброе утро».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Герои». 16+
11.10, 12.15 «ОНИ СРАЖАЛИСЬ ЗА РОДИНУ». 16+
14.35 Концерт «Офицеры». 12+
16.10 «ОФИЦЕРЫ».
18.20 Концерт «Время выбрало нас!»
21.00 «Время».
21.35 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.35 «Юстас - Алексу». Тот самый Алекс». 16+

«РОССИЯ»
4.25 «КАМИННЫЙ ГОСТЬ». 12+
5.55 «ФЕРМЕРША». 12+
9.10 Большой юбилейный концерт, посвящённый 90-летию Академического ансамбля песни и пляски им. А.В. Александрова.
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Петросян-шоу». 16+
13.40 «ДЕВЧАТА».
15.25 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ». 6+
18.00 «Песни от всей души». 12+
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «ЧЕМПИОН МИРА». 6+
23.50 «ОГОНЬ». 6+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Бюро находок».
7.40 «История Преображенского полка, или Железная стена».
8.25 «ПЁТР ПЕРВЫЙ».
10.05 «Честь мундира».
10.50 «Добровидение-2022». VII Международный фестиваль народной песни.
13.25 «Земля для ибисов».
14.10 Концерт Ансамбля песни и пляски Российской Армии имени А.В. Александрова в Большом театре России.
15.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.05 «Отцы и дети».
16.30 «ПОДВИГ РАЗВЕДЧИКА».
18.00 День защитника Отечества. «Подвиг разведчиков. Операция «Монастырь».
18.45 «Песня не прощается... 1971».
19.20 «По следам сирийских мудрецов».
20.00 «ЭСКАДРОН ГУСАР ЛЕТУЧИХ».
22.40 «Русский бал».
23.35 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ».

«НТВ»
4.00 «ОТСТАВНИК». 16+
5.35 «ОТСТАВНИК-2». 16+
7.10, 8.20 «ОТСТАВНИК-3». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
9.25, 10.20 «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ». 16+
12.00, 13.20 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА». 16+
14.20, 16.20 «ДЕД МОРОЗОВ». 16+
19.40 «ДЕД МОРОЗОВ-2». 16+
23.35 «Три танкиста». 16+

Җомга

24 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
10.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 0.50 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.30, 20.00, 21.30 Новости Татарстана. 16+
14.50 «АТЫ-БАТЫ ШЛИ СОЛДАТЫ...» 12+
17.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Металлург» (Мг).
21.00 «Родная земля». 12+
22.00 Финал Республиканского конкурса красоты «Мисс Татарстан-2023». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 16+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Казаннан казанга». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Караңгыда нурлар яктырак». Люция Галләмова турында телеочерк. 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Иң, иң, иң...» Алсу Гайнуллина. 16+
19.20 «Родная земля». 12+
19.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.25 Спектакль «Алдым-бирдем». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Прокуроры 6. Профессия-следователь». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИКАЗАНО УНИЧТОЖИТЬ! ОПЕРАЦИЯ: «КИТАЙСКАЯ ШКАТУЛКА». 16+
11.30 «НА ПОРОГЕ ЛЮБВИ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.00 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». ПОПУТНЫЙ ВЕТЕР». 16+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Прокуроры 6. Ночные оборотни Волоколамска». 16+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
7.00 «Доброе утро».
10.00, 12.00 Новости.
10.15, 12.15 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
15.40 «КАЛАШНИКОВ». 12+
17.35 «Закат американской империи». «Метрополия». 16+
18.45 «Закат американской империи». «Европа». 16+
19.45 «Закат американской империи». «Украина». 16+
21.00 «Время».
21.35 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.35 «Александр Зиновьев. «Я есть суверенное государство». 12+

«РОССИЯ»
4.35 «МОСКВА - ЛОПУШКИ». 12+
6.05 «ГАЛИНА». 12+
9.15 «ДЕВЧАТА».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ». 6+
13.05 «В ЧУЖОМ КРАЮ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.15 Вести. Местное время.
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.55 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.40 «История Семеновского полка, или Небываемое бываетъ».
8.25 «ПЁТР ПЕРВЫЙ».
10.05 Исторические курорты России. «Геленджику улыбается солнце».
10.35 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ».
12.35 «Сладкая жизнь».
13.25 «Совы. Дети ночи».
14.20 «Александр Невский. За Веру и Отечество».
15.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.50 «Первые в мире».
16.05 «Отцы и дети».
16.35 «ЧИСТОЕ НЕБО».
18.25 «Романтика романса».
19.20 «По следам сирийских мудрецов».
20.00 «Свой среди чужих, чужой среди своих». По всем законам нашего тяжелого времени».
20.40 «СВОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ, ЧУЖОЙ СРЕДИ СВОИХ».
22.15 Концерт «Если дорог тебе твой дом...»

«НТВ»
4.35 «ОДИН В ПОЛЕ ВОИН». 12+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20, 10.20 «ПОСЛЕДНИЙ БОЙ». 16+
13.15, 16.20, 19.40 «ПРИКАЗА УМИРАТЬ НЕ БЫЛО». 16+
22.00 «Ты мой герой!» Праздничный концерт. 12+
0.00 «Когда придет весна». 16+

Шимбә

25 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Гәүһәр» балалар фестивале. 6+
15.40 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КВН РТ - 2023». 16+
23.00 «Дежа вю». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Риф Гатауллин турында телеочерк. 16+
7.00, 15.10 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Чакыра юлларым». Мурат Гайсинның иҗат кичәсе. 16+
22.00 Спектакль «Курчак туе». 16+

«ЭФИР»
5.15 «Молодая наука». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Нонна Мордюкова. Простая история». 12+
8.45 «ВТОРЫЕ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 22.30 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». КУЛОН АТЛАНТОВ». 16+
14.35 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
15.00 «Прокуроры 6. Ростовские амазонки. Двухсерийные убийцы». 16+
15.45 «БОМБА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПЯТНИЦА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
7.00 «Доброе утро. Суббота».
8.58 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
14.00 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
18.20 «Сегодня вечером». 16+
20.00, 21.35 «УЧЕНОСТИ ПЛОДЫ». 12+
21.00 «Время».
23.55 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «В ЧУЖОМ КРАЮ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВОСЬМОЙ УЧАСТОК». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.35 «СУВОРОВ».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.05 Земля людей. «Энцы. Разговор с огнем».
10.35 «ЭСКАДРОН ГУСАР ЛЕТУЧИХ».
13.15 «Закон журавля».
13.55 Международный фестиваль «Цирк будущего».
15.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.05 «Отцы и дети».
16.40 «Храм».
17.35 Московский международный Дом музыки - 20 лет. Юбилейный концерт.
19.20 «По следам сирийских мудрецов».
20.00 «Янковский».
21.15 «ВЛЮБЛЕН ПО СОБСТВЕННОМУ ЖЕЛАНИЮ».
22.40 «Посёлок Юрино. Марий Эл. Шереметевский замок».
23.10 «ЖЮЛЬ И ДЖИМ».

«НТВ»
5.10 «ЛЕЙТЕНАНТ СУВОРОВ». 12+
6.40 «Три танкиста». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «АФОНЯ».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «СВОЯ ВОЙНА. ШТОРМ В ПУСТЫНЕ». 16+
22.15 «Ты не поверишь!» 16+
23.20 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

26 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Бир кулыңны».Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Авангард».
20.00, 23.00 «Семь дней». 16+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
21.30 «Профсоюз - союз сильных». 12+
21.45 «Батырлар». 6+
22.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 0.15 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Бәхетемә юрадым». Ганс Сәйфуллин. 16+
8.00 «Татар сүзе 2022». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Моң-җырларым - ак җилкән». Ганс Сәйфуллинның юбилей кичәсе. 16+
16.20, 21.10 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
22.00 «Халкыбыз мирасы - Народное наследие». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 12+

«ЭФИР»
5.15 «Молодая наука». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «ЗГВ. Горькая дорога домой». 12+
8.45 «ВТОРЫЕ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.10 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». ВОСТОК - ДЕЛО ТОНКОЕ». 16+
14.35 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
15.00 «Рейс в один конец. Прокуроры 6». 16+
15.45 «БОМБА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛУЧШЕЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 23.30 Подкаст.лаб. 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
13.50 «Бомба. Наши в Лос-Аламосе». 16+
14.55 «МУЖИКИ!..».
16.50 «Закат американской империи». «Европа». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «КОНТЕЙНЕР». 16+

«РОССИЯ»
6.10 «ТЫ МОЙ СВЕТ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «В ЧУЖОМ КРАЮ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.35 «КУТУЗОВ».
9.20 Тайны старого чердака. «Эпоха».
9.55 Диалоги о животных.
10.35 «СВОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ, ЧУЖОЙ СРЕДИ СВОИХ».
12.10 «Свой среди чужих, чужой среди своих». По всем законам нашего тяжелого времени».
12.50 «Забытое ремесло».
13.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Володин.
13.35 «Игра в бисер» «Алексей Толстой. «Золотой ключик, или Приключения Буратино».
14.15 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БУРАТИНО».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.45 «Нам некуда бежать друг от друга...»
19.20 «По следам сирийских мудрецов».
20.00 «НЕИСПРАВИМЫЙ ЛГУН».
21.20 XVI Зимний международный фестиваль искусств.
23.25 «ГОРОДСКОЙ КОВБОЙ».

«НТВ»
4.55 «КАПИТАН ГОЛЛИВУД». 12+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.30 «Звезды сошлись». 16+

Хәмерле көнчелек фаҗигасе

Актаныш районының Пучы авылында 51 яшьлек хатын-кыз исерек ир-ат тарафыннан үтерелә. Гадәттә мондый җинаятьләр, чынлыкта, бер сәбәпсез эшләнә. Монда исә, эчкечелектән кала, фаҗигагә этәргән башка төрлерәк шартлар да булган кебек.

1972 елгы Гүзәл Талипова Пучыда гомер иткән. Ире белән күптәннән аерылышкан, ике кыз үстергән, соңгы елларда бик өлкән яшьтәге әтисен тәрбияли. 2021 елның көзендә шул авылдагы картлар һәм инвалидлар йорты ашханәсендә эшләүче ханым үз өендә үтерелә. Тикшеренү аның үткен корал белән корсак һәм күкрәгенә биш мәртәбә кадау нәтиҗәсендә үпкә, ашказаны һәм башка әгъзалары зарарлану, эчкә кан саву сәбәпле тиз арада җан бирүен күрсәтә.

14 сентябрь иртәсендә мәхшәр кылучыны ачыклап торасы булмый. Явызлыкны күреп торган шаһит та бар хәтта. Икенчедән, көтелмәгән хәл дә булмый бу. Эш шунда ки, алдагы көнне Г.Талипова Илһам Шәйхетдинов дигән күптәнге танышының пычак тотып куркытуы, үтерү белән янавы турында полициягә мөрәҗәгать иткән була. Шуннан соң ике участок инспекторы килеп гариза яздыралар, үзеннән һәм берничә хезмәттәшеннән аңлатмалар алып китәләр. Ошбу хезмәткәрләрнең әйтүенә караганда, И.Шәйхетдиновны Пучыда таба алмыйлар, күрше авылда бозау урлау очрагын тикшерергә ашыгалар. Эш узгач, Илһамны тиз эләктерәләр. Телефоны буенча шул яклардагы Иске Айманда икәнен ачыклыйлар да, урамда буталып йөргән сәрхүшне тотып алып кайталар.

Пучыда туып үскән, 1965 елгы абзый чамасыз эчкече дә түгел. Хатыны, малае белән Минзәлә каласында яши. Теш куючы техник булып эшләгән. Хәзер күбрәк умартачылык белән шөгыльләнә, әйтүенчә, Чаллыга барып һөнәре буенча да кәсеп итә икән. Кыскасы, ерак 1990 елда хулиганлык кылып, өч еллык шартлы хөкем алуын исәпләмәгәндә, тел-теш тидерерлек ир-ат түгел шикелле.

Шул елның 13 сентябрь иртәсендә пычак белән янау очрагы турындагы хәбәр, полициягә барып җиткәнче, бик күпләргә, шул исәптән, Илһамның кайбер якыннарына да билгеле була. Гүзәлнең шул авылда яшәүче абыйсы М.Закиров бу хакта белеп алгач та, авыл башлыгы Н.Нуретдинов янына бара. Аныс участковыйга шалтырата. Марсель сеңлесе йортына да килә. Ишек эчтән бикле булгач, эшкә китә, чөнки ул чакта Гүзәл эшендә була инде.

Гүзәл «ишегалдында пычак тоткан Илһам Шәйхетдинов йөри» дип, картлар йорты сакчысы Радик Мирзаяновка смс-хәбәр юллый. Радик ул чакта күрше авылдагы өендә була. Г.Талиповага шалтыратырга керешә, җавап булмагач, эштәге хезмәттәше Марсель белән сөйләшә. М.Муллаянов аның соравы буенча үз машинасында Гүзәл өенә бара. Әллә ни шикләнердәй сәбәп күрмәдем, шакый торгач, алдан Гүзәл чыкты, аның артыннан И.Шәйхетдинов күренде, ди ул. Шул рәвешле, хатын-кызны эшенә алып китә, ир-ат өйдә карт бабай янында кала. Әйтүенә караганда, юл уңаенда Гүзәл аңа да Илһамның пычак тотып куркытуын сөйләп бирә.

Картлар йортына барып җиткәч тә, бу хакта сүз чыкмый калмый. Анда сакчы Радик та килеп белешеп китә. Борчылган, дулкынланган Гүзәлгә директор кушуы буенча дару да эчерәләр. Соңгысы, үзенә туган тиешле И.Шәйхетдиновның каенсеңлесенә Гүзәлнең полициягә гариза язарга җыенуы турында хәбәр итәргә өлгерә. Башка авылда яшәүче ошбу ханым, күршесе машинасында Пучыга килеп җитә, Гүзәлнең өен табып, җизнәсен чакырып чыгара да шул авылдагы туганнарына, ягъни полициядән ераккарак илтеп куя.

Минзәләдә яшәүче гаиләле абзый Пучыдагы ханым йортында ни эшләп йөргән дигән, аяныч хәлләр башлангыч алган мөһим сәбәпләргә ачыклык кертергә мөмкинлек бирерлек сорау тумый калмый монда. Эш шунда ки, Гүзәл белән Илһам якын мөнәсәбәттә булганнар. Җинаять эшендә шаһит буларак катнашкан һәркем моны раслый. Без телгә алган каенсеңел директор ханымнан бары тик 13 сентябрьдә генә ишеттем, ник хатынына әйтмәдең дип, ризасызлык белдердем, ди. Мәрхүмәнең, Чаллыда яшәп, укытучы булып эшләүче кече кызы, каникуллар вакытында өйдә тордым дип, абзыйның күчтәнәчләр тотып килеп йөрүен әйтә. Картлар йорты сакчысы Марсель Муллаянов әле 12 сентябрьдә генә, димәк, фаҗигагә нибары ике көн кала, Илһам машинасында Гүзәлнең эш урынына килеп китүләрен искә ала. Охшаш эчтәлекле бәяннәрне күпләп китерергә мөмкин, димәк, ошбу фикер шик уятмый. Хәер, И.Шәйхетдинов үзе дә 11 ел чамасы якыннан аралашуларын яшерми.

Инде шул кадәр вакыттан соң араларыннан кара мәче узу сәбәбен ачыкларга кирәк. Мәрхүмнең бертуганы Марсель моны берничә ай элек сеңлесенең никахлы ир белән очрашырга теләми башлавыннан күрә. Аннан соң акча мәсьәләсен дә искә ала ул. Әйтүенә караганда, Гүзәл Илһамга алданрак биргән 100 мең сум акчасын кайтаруын, Илһамның тагын шул кадәр үк таләп итүен сөйләгән була. Шуннан соң Илһам белән бу хакта сөйләштек, ике көн эчендә 100 меңне кире күчерергә ышандырды, сүзендә тормады, ди М. Закиров.

Илһам Шәйхетдинов ун-унбер елдан соң читкә этәрелүен башкадан күрә, көндәшлек мәсьәләсен алгы планга куя. Бу җәһәттән сакчы Радик Мирзаянов өскә калка, чөнки абзый соңгы вакытларда Гүзәл йорты каршысында еш кына аның «Киа» машинасын күрә һәм көнләшә башлавын әйтә. Радик исә ошбу ханым белән якыннан аралашуын кире кага. Тәүлеклек төп эшеннән соң шабашкага йөрүен, кышын Гүзәл йортының кухнясын, җәй көне залын ремонтлавын белдерә. Шулай ук Илһамның, шул хакта сүз кузгатып, Гүзәл белән аралашулары хакында сорашып йөрүен дә искәртә.

И.Шәйхетдиновның шикләнүләре нигезле булган очракта да, җинаять эше өчен әллә ни әһәмияте юк, чөнки ерткычлыкны аклый да, киметә дә алмый. 12 сентябрьдә үҗәт ир Пучыга тагын килә. Күрсәтмәсенә караганда, сөйгәне аңа хатыны белән аерылышырга куша, ул баш тарткач, араны өзүе турында белдереп кырт кисә. Әлеге кискен сөйләшүдән соң ул Минзәләгә кайта да, кайгысын аракы белән юарга керешә. Бусы инде теләсә нинди мизгелдә чыгырдан чыгару куркынычы булган төп сәбәп пәйда булуны күрсәтә.

Исерек абзый икенче көнне иртүк Гүзәл өенә килә. 13 сентябрьдә пычак тотып хуҗабикәне куркытуын кире кага ул. Бикләнмәгән ишектән кердем, Гүзәл ятып ял итәргә тәкъдим итте, аны эшенә алып киттеләр. Үзем белән алып килгән аракыны эчтем дә йокларга яттым, ди. Күрәсең, мәшәкать чыгарасы килмичә, аннан каенсеңлесе алып китеп туганнарына илтеп куюын искә алмый.

Г.Талипова бу көне аннан куркып, абыйсы Марсель өендә куна. Әмма иртә белән кайтырга кирәк була, авыру атасын ашатасы бар бит. М.Закиров аны машинасы белән китереп куя, өйне, каралты-кураны тикшереп чыккач, үз юлы белән китеп бара. Гүзәл өйдә кала. Шул вакытта сакчы Радик та картлар йортына килеп хезмәттәше М.Муллаяновны алмаштыра.

Радикның күрсәтмәләренә караганда, алдагы кичтә телефоннан сөйләшкәндә, Гүзәл аңа полиция эзләп таба алмаган Илһамнан куркуын сөйли, иртәгә ул мине үтерәчәк, ди хәтта. Шуңа күрә ул аңа шалтыратырга керешә. Җавап булмагач, үз машинасында ханымның өенә китә һәм ишегалдына керү белән ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышы ишетә. Тиздән кухня бүлмәсендәге мәхшәрнең шаһите була.

Ишек бикле булганга, рәшәткә белән бер тәрәзәне каерып ача, эчкә керергә өлгерми, шул такта белән үрелеп, котырынып хатын-кызга кадаучы явызга комачауларга тырыша. Әйтүенчә, бер мәлдә пычакны бәреп тә төшерә, әмма шунда ук тегенең кулында икенчесе пәйда була. Кыскасы, Гүзәлгә исән калу мөмкинлеге калдырмый ул.

Абзый шул ук рәшәткәне эләктереп, үзен тәрәзә төбеннән этеп төшергәч, Р.Мирзаянов картлар йорты директорына, дустына шалтырата, күрше йортка йөгереп кереп, куркыныч хәбәрне ирештерә, ярдәмгә чакыра. Хуҗа аңа ияреп ишегалдына керә, әмма коты алынган хәләл җефете белән карт әнисенең үгетләүләрен тыңлап, кире борыла. Шул арада өйалды баскычында ярсу кыяфәтле И. Шәйхетдинов күренә, рәшәткә тоткан Р.Мирзаяновка читкәрәк китәргә боера да урамга чыгып китә. Радик кухняга кергәч, идәндә йөзтүбән яткан җансыз ханымны күрә.

Тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Вилсур Сәлахов шул көнне үк аңлы рәвештә кеше үтерү очрагы буенча җинаять эше кузгата. И.Шәйхетдинов моны берничек тә кире кага алмый, билгеле. Ләкин вакыйганы шомартыбрак сурәтләргә тырыша. Күрсәтмәләренә караганда, ул көнне Минзәләдә ташландык сарайда кунып, иртүк Пучыга килә, Гүзәл йортына кергәч үк, аракы эчә, шул чакта ул көндәш дип исәпләгән Радик телефоннан шалтыраткач, көнчелек хисләре уянып китү сәбәпле, низаг куба. Хуҗабикә тимер чәйнек, хәтта пычак тотып кычкыра. Хәтәр әйберне тартып алып идәнгә ташлаганда Илһамның кулы киселә, ә инде Р. Мирзаянов тәрәзәне ватарга тотынгач, кабынып китеп пычак белән чәнчергә керешә. «Ул вакытта Гүзәлнең кулында бернәрсә дә юк иде, миңа куркыныч янамады, күкрәгенә кадагач үләчәген белдем» дисә дә, «үтерергә дигән ниятем булмады, барысы да көтмәгәндә үзеннән-үзе килеп чыкты», – дип гаебен өлешчә генә тануын белдерә ул.

Моңа өстәп, аңа күпсанлы шаһитлар нигезендә, 13 сентябрь кыланмышлары өчен үтерү белән янауда рәсми гаепләү игълан ителә. Тикшерү барышында, И.Шәйхетдиновның ерткычлык кылып урамга чыккач, үзенә туган тиешлеләр ишегалдыннан велосипед эләктереп чыгуы, шуңа атланып Пучыдан качмакчы булуы ачыклана. Чынлыкта, аны юл читендә ташлап калдырып, Иске Айманга узгынчы машинага утырып китә ул. Юстиция подполковнигы В.Сәлахов ошбу очракка урлашу дигән бәя бирә. Велосипед табылып хуҗасына кайтарылса да, матди зыян 3 мең ярым сум санала. Ләкин монысы суд утырышларында зарар күрүче сүзе белән төшереп калдырыла.

Актаныш район суды И.Шәйхетдиновны аңлы рәвештә кеше үтерү һәм үтерү белән янау дигән ике җинаятьтә гаепле дип таба һәм 8 ел да 9 айга кырыс режимлы колониягә озатырга карар кыла. Әлеге хөкем, бер елга якын вакыт узып, 2022 елның августында Татарстан Югары Судында каралгач кына, үз көченә керде.

Наил ВАХИТОВ.

Милли көйләр эзеннән

Татарстанның халык рәссамы Рабис Сәлаховның «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә ачылган картиналар күргәзмәсе әнә шулай дип атала, чөнки анда байтак сурәтләр «Тәфтиләү», «Раушан йолдыз», «Казан сөлгесе», «Сибелә чәчем» һ.б. матур җырларыбыздан илһамланып иҗат ителгән.



«Казан сөлгесе» җыры буенча.

Экспозициядә картиналар белән бергә останың балчык эшләрен дә күрергә мөмкин. Р.Сәлахов үткән гасырның сиксәненче елларында ук Менделеевскида Карпов исемендәге химзаводта керамика эшләп чыгаруны торгыза, ә 1990 елларда Алабугада керамика остаханәсе оештыра һәм шәһәрнең балалар тудыру, китап йортлары, җәмигъ мәчете өчен төрле керәч сәнгать әсәрләре иҗат итә. Нәкъ шул елларда ул Алабуга тарих-архитектура музей-тыюлыгы белән хезмәттәшлек итеп, меңьяшәр каланың байтак һәйкәлләрен торгызуга үзеннән өлеш кертә. Бүген туристлар Алабугага шагыйрә М.Цветаева мемориаль комплексы, Н.Дурова музей-утарына, туган якны өйрәнү комплексы, Бехтерев исемендәге өяз медицинасы музеена күпләп агыла икән, монда интерьерларны эшләүдә арымый-талмый хезмәт куйган рәссам Рабис Сәлаховның да өлеше зур.



«Китә казлар» җыры буенча.

«Ончы Фәхри» җыры буенча.

Татар җәмәгатьчелеге Рабис әфәндене киң колачлы җәмәгать эшлеклесе дип тә белә – шул ук Алабугада ул Рәссамнар берлеге әгъзалары өчен иҗат остаханәләре булдырды, тарих-архитектура музее белән байтак Россиякүләм һәм халыкара симпозиумнар оештырды.

«Алабуга, Чаллы һәм, гомумән, Кама аръягы шәһәрләрендә яшәп иҗат итүче бер төркем рәссамнарны яңа калалар феномены дияр идем, – дип үз бәясен бирде сәнгать фәннәре докторы Р.Солтанова кылкаләм остасы Р.Сәлаховның иҗатына. – 1970 елларда алар Мәскәүдә, Санкт-Петербургта уку йортлары тәмамлап кайта. Мәсәлән, Илдар Ханов Мәскәүдә Суриков институтында төсле сурәтләр язу остасы булып җитешә, Олег Кульпин атаклы Палех миниатюрасын өйрәнә, Хәмзә Шәрипов Санкт-Петербургта Мухина исемендәге сәнгать-сәнәгать училищесында текстиль буенча белем-күнекмә ала һ.б. Татарстаныбызга әйләнеп кайткач исә, алар талантларын төрле өлкәләрдә – монументаль сәнгатьтә, графика, скульптура, төсле картиналарда ача, оештыру эшендә үзләрен күрсәтә һәм күбесе мөгаллим булып эшли. Бүген иң актив, җиң сызганып эшләүче, иҗат итүче, һәркайсы үз йөзен булдырган талантлы рәссам алар. Менделеевскида ук керамика тармагын торгызганга, ахры, Р.Сәлаховның иҗатында табигый җир төсләре күрәбез. Рабис туган җиргә мәдхия җырлый, милли җырларыбыздан илһам алып иҗат итә, татар тарихына, дастаннарыбызга әйләнеп кайта. Әмма ул картиналарын тормышта ничек бар шулай иҗат итми, аларга шигъри аһәң иңдерә, һәр сурәттән моң агыла кебек. Татар авыллары, кызарып пешкән алма кебек тулышкан, чибәр кызларыбызны, батыр егетләребезне, киң иген кырларын сурәтләсә дә, монументаль фикерләү сәләте картиналарны милли тема белән генә чикләмичә, галәм киңлегенә күтәрә. Башкортстанда туып киң иркен далаларның һавасын сулап үскәнгәдер, иҗаты шундый киң яңгырашлы. Гомумән, һәр картинада рәссамның төрки дөньяга «кендеге тоташканын» абайларга мөмкин. Күргәзмәдә аклы-каралы графикасы камиллеге белән шаккатыра. Алар гүя – агачтан ую, чүкеп ясау, гомумән, монументаль сәнгать өчен әзер эскизлар. Рабис Сәлаховны Казаныбызда керамика остаханәсе җитәкчесе итеп күрәсе килә. Һөнәри уку йортларыбыз җитәкчеләре бу остага игътибар итсен иде. Яшьләргә бирерлек белеме, күнекмәләре байтак аның...».

«Борынгы шигырь».

65 яшьлеге уңаеннан ачылган күргәзмәдә рәссамны Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, күренекле язучыбыз Ринат Мөхәммәдиев, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлекчәсе рәисе Анатолий Крылов, Алабуга тарих-архитектура музей-тыюлыгы исеменнән Валерий Зотин тәбрикләде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазадаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат житешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 17.02.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2605

16+